Безнен Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

01

гыйнвар 2020

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

ЛОТФУЛЛА ФАТТАХОВ «КИТАП ТАРАТУЧЫЛАР»

Киңәшле эш таркалмас!

2019 елның 17-20 декабрь көннәрендә Казан шәһәрендә «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» XIV форумы узды. Чарада Россия Федерациясенең 63 төбәгеннән, 29 чит илдән 600 делегат катнашты.

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
01 (313)
гыйнвар 2020

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

96

56 **ХӨСӘЕН МИРЗА.**
Фәтхи Бурнаш

82 **ХӘСӘН ТУФАН.**
Гомәр Бәширов көндәлегеннән

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Нәкый Исәнбәт**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
10 **Татар кызлары – Балкан сугышында**
12 **Истанбул хатирәләре.** *М.Рәхмәт Паташева*
19 **«Тартыш» газетасы.** *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
24 **Археографик көндәлек.** *М.Госманов*
31 **Халык белән бергә.** *А.Гафиятов*

ТАТАР ГАМЕ

36 **Һәр китапханәгә – «Безнең мирас»!**
44 **Өстәлемдәге китап – чынбарлык!** *Ф.Гайнанова*
46 **«Хәтергә уелган китап»**

ДИНИ МИРАС

48 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*
54 **2020 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр.** *А.Дубин*

ӘДӘБИ МИРАС

56 **Хөсәен Мирза.** *Ф.Бурнаш*
70 **Мөһаҗирлектәге татар китабы.** *Х.Миңнегулов*
78 **Кызыл артында – каралык.** *Ф.Хатипов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

82 **Хәсән Туфан.** *Гомәр Бәширов көндәлегеннән*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

91 **Ике министр.** *Ә.Фәйзрахманов*
94 **Истә, һаман да истә!**
96 **Милли музейда – ГАЗ-А автомобиле.** *Л.Нәгыймов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Шамил Садыйков
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Альберт Борһанов
Данил Салихов
Зиннур Мансуров
Ирек Шәрипов
Ким Миңнуллин
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Ринат Закиров
Сөмбел Таишева
Фәйзелхак Ислаев
Фәнзилә Җәүһәрова
Хатыйп Миңнегулов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

98 **Камал III.** *Ә.Зарипов*
104 **Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында**
106 **Оптимистик фикер һәм хисләр җырчысы.** *Д.Гайнетдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

111 **Туган як авазы.** *М.Мәһдиев*
115 **Йөрәк сүзем.** *Э.Шәрифуллина*

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы**. *Гыйнвар*

Заказ №О-3684. Тираж – 1300 данә. Формат 70х108 $^{1}/_{16}$.
Басарга кул куелды: 30.12.2019.
Чыгу көне: 03.01.2020.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, А Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Л.Фәттахов рәсеме ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Китап таратучылар». 1960.**
Л.Фәттахов рәсеме

Нәкый Исәнбәтнең тууына 120 ел



Нәкый Исәнбәт

(29 декабрь, 1899-12 сентябрь, 1992)

***

Теләк үлмәс җир астына кергән белән,
Орлык үлмәс җир астына күмгән белән.

***

Коймасыз йортка йозаклы капка.

***

Кунак үзе өмет иткәнне ашамас, алдына китергәнне ашар.

***

Бер хатынның хәйләсе кырык дөягә йөк була.

***

Аш-суымны эчтең, йөз суымны түктең.

***

Бер ишәк шәһәреңә шундый бер эш ясар, мең акыллы кеше хикмәтенә төшенмәс.

ТУКАЙ ОСТАЗ

Зур шагыйрьләр дөньясына күзне салганда туры,
Анда оҗмах төсле татлы көн күрүләр ялтырый.
Мин дә кермәкче буламын шул иҗат дөньясына,
Гомерың, Байроннарың йөзгән шигырь дөньясына.
Тик җыен көндәш белән тулган минем арт-алларым,
Шул теләгемнән көлә барча минем дошманнарым.
Барча азгын, барча дошман булса ни дә торса – чурт!
Зур шагыйрьләрдән Тукаев булса хәлфә, мин – шәкерт! ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

Ике япьле якорь уйлап табу диңгезчелек өлкәсендә бик зур казаныш булган. Аңарчы диңгезчеләр бау бәйләнгән авыр таштан файдаланганнар, кайберләре су төбенә таш тутырылган кәрзин төшергән. Шулай азаплана торгач, ниһаять, металлдан коелган ике япьле авыр якорь барлыкка килгән, озын сабының югары башына аркылы тимер (шток) дә ябыштырылган. Кайбер этруск шәһәр-дәүләтләре суккан акчаларның икенче ягына якорь сурәте дә төшерелгән. Бу диңгезчелек, диңгез сәүдәсе белән актив шөгыльләнүче яр буе шәһәрләренә хас гадәт булгандыр, күрәсең.



Этрускларның сәүдә корабы

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында.
*Фәнни-популяр тарихи бәян.

Этруск диңгезчеләре төрле корабларда йөзгәннәр. Без инде һәр ягында 25шәр ишкәкче утырган тиз йөрешле питеконтерларны телгә алган идек. Моннан тыш, этрусклар түгәрәк палубалы сәүдә кораблары да төзегәннәр. Андый кораблар гаскәр йөртү өчен дә файдаланылган. Шулай ук кечерәк, әмма бик хәрәкәтчән кораблары да булган. Аларны 20 ишкәкче йөрткән.

Ул заманда диңгезче халыкларда триера (яки трирема) дип аталган өч яруслы хәрби кораблар да күренә башлый. Аларның үзенчәлеге шунда – һәр ярусында ишкәкчеләр утырган һәм андый зур кораб диңгездә дәһшәтле коралга әверелгән. Әмма триреманы беренче кем уйлап табуы турында төгәл генә мәгълүмат юк. Берәүләр аны финикиялеләрнең Сидон шәһәрендә яшәүчеләр уйлап тапкан, икенчеләр грекларның Коринф каласы кешеләре төзегән, ди. Ә тарихчы Геродот исә триреманы Мисыр фиргавене Нехо төзергә боерган, дип яза. Тарихчылар фикеренчә, греклар андый төрдәге кораблардан бары тик б.э.к. VI гасырда гына файдалана башлаганнар. «Этрускларда трирема сурәте төшерелгән кабер ташлары б.э.к. V гасырга карый. Әмма Этруриядә триремалардан файдалану борынгырак дәвердә башланган булырга тиеш» (Нем., 146). Һәрхәлдә, Этрурия диңгезчеләре заман казанышларыннан артта калмаган. Трирема кебек көчле кораблар аларда да булган. Урта диңгездә греклар, Карфаген һәм этруск диңгезчеләре арасында үсә барган көндәшлек аркасында, сугышларда триремалардан файдаланганнар.

Б.э.к. VIII гасырдан башлап, Борынгы Греция дәүләтләре Урта диңгез бассейнында актив рәвештә үз колонияләрен булдырырга керешәләр. Эгей диңгезенә чыгып торган Эвбея утравындагы Халкида шәһәре греклары, беренчеләрдән булып, ерак Италиядәге Искья утравына килеп урнашалар. Искья Неополитан култыгындагы башка утраулардан зуррак була, ул Италиянең бик уңайлы җирендә урнашкан Кампанья өлкәсе каршында тора. Өстәвенә, ул актив сәүдә алып барган, шулай ук этрусклар нигез салган Кум шәһәренә дә якын торган. Халкидадан килеп төпләнгән греклар, шушы уңайлы утрауда урнашып, Урта диңгезнең көнчыгышындагы дәүләтләр белән Италия арасында барган диңгез сәүдәсен үз кулларына алганнар. Халкида сәүдәгәрләре бераздан яр кырыендагы Кум шәһәренә дә күченәләр. Халык саны арта һәм Кум көчле сәүдә үзәгенә әверелә. Грекларның бу тирәләрдә үз илләрендәге кебек җәелеп яшәве, сәүдә итүе этрускларны башта борчымый. Алар үзләре дә греклар белән сәүдә итәләр, шуннан файда күреп яшиләр. Грек колонистлары белән Этрурия арасында латиннар яшәгән Лаций өлкәсе урнашкан. Алар греклар белән чиктәш түгел, шуңа күрә борчылырлык сәбәп юк. Һәркайсы үзенчә яши: кирәк чакта очрашалар, товар алмашалар. Бу чорда алар бер-берсенә файдалы була. Әмма вакытлар үтү, заманалар үзгәрү белән, Халкида греклары белән, этрусклар арасында каршылыклар килеп чыга. Эш шунда ки, б.э.к. VI гасырда этрусклар үзләре дә илләрен киңәйтү, яңа колонияләр булдыру белән шөгыльләнергә тотыналар. Алар Этруриядән көньяктарак урнашкан Кампанья өлкәсендә үз колонияләренә нигез салалар. Этрускларга хас гадәт буенча, Кампаньядә дә уникe этруск шәһәре төзү планын тормышка ашырырга керешәләр. Ә моның өчен җәелеп яшәүче килмешәк грекларны кысрыкларга туры килә. Кече Азиянең яр буендагы Книд каласыннан һәм Родос утравыннан чыккан грек колонистлары да Италия тирәсендәге утрауларга килеп урнашалар. Болары инде Сицилия белән Италия арасындагы Липар утрауларында тормыш корып җибәрәләр. Бу хәл б.э.к. 580 еллар тирәсендә була. Италиянең көньягында грек колонияләренең артканнан-арта баруы этрускларның диңгез сәүдәсен кысылырга мәҗбүр итә, чөнки, кая карама – греклар,



Этрускларның хәрби корабы

алар инде монда үзләрен чын хуҗаларча тоталар, диңгез сәүдәсен үз кулларына алалар, җирле халыкларны кысрыклый ук башлыйлар.

Этрусклар бу хәлне тыныч күңел белән күзәтеп тора алмыйлар, алар артык әрсезләнеп киткән грекларга каршы көрәшергә тотыналар. Этрускларның флоты алар калалар төзегән Кампанья ярларында тора. Этрусклар белән греклар арасындагы диңгез сугышында өч яруслы көчле кораблар – триремалар катнаша. Зур сугыш этруск диңгезчеләре файдасына тәмамлана. Әмма бәрелешләр егерме елга сузыла һәм б.э.к. 580-560 елларда дәвам итә. Этрусклар грек колонистларын Италиянең көньягыннан кысрыклап чыгара алмасалар да, аларны төньяктарак яшәүче латиннар, сабалар, вольсклар, катнаш кабиләләрдән торган самнитлар җирләренә үткәрмиләр. Хәер, грек колонистларын Апеннин таулары итәгендә яшәгән кабиләләр бөтенләй диярлек кызыксындырмый. Алар яр буендагы җирләрне, анда урнашкан шәһәрләрне һәм Тиррен диңгезендәге утрауларны үзләштерергә, аларны диңгез сәүдәсе алып бару өчен ышанычлы базаларга әйләндерергә омтылалар.

Бу чорда, бер-берсен уздырырга тырышып, яңа җирләрдә үз колонияләрен булдырырга омтылган грек шәһәр-полислары арасында зур хәрәкәт башланып китә. Грециянең үзендә һәм Эгей диңгезенең каршы ягында, Кече Азия ярларында барлыкка килгән грек калалары активлаша һәм күбесе яңа җирләрдә үз колонияләренә нигез салырга омтыла. Кече Азиядәге Лидия патшалыгының Эгей диңгезе ярына чыккан җирендә урнашкан грек шәһәре фокеялылар шундыйларның берсе була. Фокея греклары Урта диңгезнең бик күп почмакларын йөреп чыгалар. Алар Адриатик диңгез, Италия, Иберия (Испания), аның үзәк шәһәре Тартесс белән дә таныш булалар. «Геродот язганча, Тартесска килеп чыгып, греклар бу илнең патшасы Арык Антоний белән

дуслашып киткәннәр һәм ул аларга, Иониянe калдырып, үз иленең кайсы җирендә урнашасылары килсә, шунда торып калырга тәкъдим иткән» (Нем., 151). Әмма бу хәбәргә ышануы кыен, чөнки этрусклар да металларга бай Тартессны үзләренә буйсындырырга тырышалар, аның белән актив сәүдә алып баралар. Иберияда төрки халык – иберләр яшәгән, патшаларының исеме Арык Антоний булган, имеш. Әмма ул патша түгел, ә турдетан кабиләсенең башлыгы гына.

Фокея грекларының Тиррен диңгезендә пәйда булуы этрусклар өчен зур проблемага әверелә. Алар этрускларның көчле дошманына әйләнә. Грекларның Корсика утравында Алалия дип аталган колонияләре барлыкка килә. Корсика исә Этруриягә бик якын урнашкан утрау, шуңа күрә, киләчәктә этрусклар белән Фокея греклары арасында каршылыклар килеп чыгуын көт тә тор. Ике халыкның көчле флотлары Тиррен диңгезенә сыеша алырмы? Җитмәсә, Фокея греклары Тиррен диңгезенең төньягындагы Галлия чигендә, диңгез ярында Массалия (хәзерге Марсель) дип аталган көчле һәм бай колония дә төзиләр, шул рәвешле көчәя баралар. Этрускларның көнбатышка таба салган сәүдә юлларына аркылы төшеп, аларны кызыксындырган өлкәләрдән кысып чыгарырга тырышалар.

Бу хәл этрусклар белән греклар арасында сугыш башлануга китерә. Этрусклар, Фокея грекларына каршы көрәш башлап җибәрү өчен, Төньяк Африкадагы көчле Карфаген дәүләте белән килешү төзиләр, бергәләшеп сугышырга сүз берләшәләр. Фокея грекларының Тиррен диңгезендә көчәеп китүе, колонияләр булдыруы Урта диңгезнең көнбатышына сәүдә белән йөрүче Карфаген диңгезчеләрен дә борчый. Алар әрсез көндәштән арынырга тырышалар. Бу яктан этрусклар белән карфагенлыларның максатлары туры килә.

Бер яктан этруск белән карфаген, икенче яктан Фокея греклары катнашкан зур диңгез сугышы Корсика утравындагы грекларның Алалия колониясе каршында була. Шул сәбәпле, ул тарихка Алалия сугышы дип кереп калган. Аркадашлык килешүе төзегән этрусклар белән карфагенлылар сугышта һәркайсы алтмышар кораб белән катнаша. Ә греклар бары тик алтмыш кораб кына туплый ала.

Дәһшәтле сугыш б.э.к. 535 елда була һәм Фокея грекларының җиңелүе белән тәгәлләнә. *«Фокеялылар сугышта кырык корабын югалта, калган егермесе, кораб борынына куелган ростр-тараннары эштән чыгу сәбәпле, яраксызга әверелә. Сугыштан соң Фокея грекларына Алалиягә әйләнеп кайтырга һәм, корабларына хатын-кызларын,*



Грекларның хәрби корабы

балаларын төяп, Италиянең көньягына юнәлергә туры килә. Бераздан алар анда Гиела дип аталган яңа колония төзиләр» (Нем., 152).

Фокея греклары, көч туплагач та, Алалия колониясенә кабат әйләнеп кайтмыйлар. Бу вакытта Италиянең көньягында тарихка «Бөек Греция» исеме белән кереп калган күп санлы грек колонияләре, шәһәрләр барлыкка килә. Шул шәһәрләрнең берсе – Фуриядә (икенче исеме Сибарис) күпмедер вакыт мәшһүр тарихчы Геродот та яши. Сугышта җиңелгәч, Фокея греклары үз ватандашлары арасында сыену урыны тапканнар булса кирәк.

Бу вакыйгалар барганда, Римда әле этруск патшалары хакимлек итә. Алар заманында этрусклар кул астындагы Рим кораблары да диңгезгә чыга, сәүдә белән шөгыльләнә башлый. Шулай Урта диңгездә грекларның һәм Карфагенның тагын бер көндәше барлыкка килә. Бу хәл грекларны да, Карфагенны да сагайта. Ул заманда иң зур флоты булган, Урта диңгез киңлекләрендә үзен хуҗа итеп тойган Карфаген, этрусклар идарәсендәге Римның сәүдә мөмкинлекләрен чикләү максатында, аны Килешү төзергә мәҗбүр итә. Бу Килешү буенча, Рим кораблары һәм аларның аркадашларына Карфаген янында диңгезгә мөгез сыман чыгып торган Гүзәл борыннан (Прекрасный мыс) ары Төньяк Африка ярларына таба йөзү һәм аның факторияләренә керү катгый рәвештә тыела. Икенче төрле итеп әйткәндә, римлыларга Карфагенның үзенә сәүдә итү өчен килү мөмкинлеге бирелә, тик Карфагеннан көнчыгыштагы Ливиягә таба хәрәкәт итү һәм анда сәүдә белән шөгыльләнү рөхсәт ителми. Римлыларга бары тик Сардиния утравына һәм Сицилиянең карфагенлылар буйсынуында булган көнбатыш өлешенә килү генә рөхсәт ителә. Рим диңгезчеләре Карфагенга бару өчен фәкать Сицилиянең көнбатышыннан үтәргә тиеш булганнар. Килешүдә Карфагенның хокукларын чикләгән пунктлар да бар. Мәсәлән, карфагенлыларга латиннар яшәгән Лаций өлкәсендәге кабиләләрне кыерсыту тыелган. Аларга шулай ук Лаций өлкәсендә ныгытмалар төзү дә рөхсәт ителмәгән. Карфагенлылар шәһәрләргә дә якын килмәскә тиеш булган.

Бу вакытта инде этрускларның Римда хакимлек иткән соңгы патшасы Горур Тарквинины, тәхетеннән төшереп, үз иленә кайтып китәргә мәҗбүр итәләр. Шулай Римда этруск патшалары хакимлек иткән чор тәгәлләнә, анда республика идарәсе урнаша. Бу шартларда этрускларның аркадашы булган Карфаген яңа гына аягына баскан Римга төрле кыенлыклар тудырырга, мөмкинлекләрен чикләргә тырыша.

Рим-Карфаген килешүенең датасы турында фәндә төрле фикерләр яши. Б.э.к. II гасырда яшәгән грек тарихчысы Полибий бу хакта бик төгәл итеп язып калдырган: *«Беренче килешү, патшалар хакимияте бетерелгәннән соң беренче консуллар Луций Юний Брут һәм Марк Гораций заманында төзелде <...> ягъни бу хәл Ксеркс (Персия патшасы) Элладага бәреп кергәнче 28 ел элек булды»* (Нем., 153). Бу хәл б.э.к. 509 елда була.

Шулай итеп, Рим, мөстәкыйль дәүләт буларак, беренче тапкыр чит дәүләт Карфаген белән Килешү төзи. Аның эчтәлеге Римның диңгез сәүдәсен чикләүгә юнәлтелгән булуга карамастан, шушы Килешү нәтиҗәсендә Рим тарихта беренче тапкыр мөстәкыйль дәүләт буларак танылуга ирешә. Моңарчы ул этруск патшаларына буйсынып яшәгән бер Лаций өлкәсе генә була.

Шушы хәл Этруриянең Римны югалтуына китерә. Алай гына да түгел, Карфаген-Рим килешүе этруск шәһәр-дәүләтләрендә яңа хәрби һәм сәяси мөнәсәбәтләр башлануга сәбәп була. Мондый вазгыять б.э.к. VI гасыр ахырында барлыкка килә.

Без һаман Карфагенны телгә алабыз, аның этрусклар белән килешү төзүе һәм уртак дошманнары – грекларга каршы көрәшүе турында сөйлибез. Нинди дәүләт булган соң ул Карфаген, ничек барлыкка килгән? Карфагенның ничек барлыкка килүе хакында тарихта кызыклы риваять сакланып калган.

Карфагенга Якын Көнчыгышта яшәүче диңгез сәүдәгәрләре – финикиялеләр нигез сала. Карфаген – алар телендә «яңа шәһәр» дигәнне аңлата икән. Бу кала б.э.к. 814 елда Төньяк Африканың хәзерге Тунис дәүләте ярында барлыкка килә. Ә риваятьтә болай диелә: Тир шәһәре хакиме Пигмалион Додона исемле сеңлесен яратмаган, аны гел кыерсытып яшәгән. Бу хәлгә түзә алмаган Додона кораб белән ачык диңгезгә чыгып китә һәм шулай күп йөргәннән соң, беркөнне аның корабын дулкыннар Тунис ярына китереп чыгара. Тунис шәһәре ул заманда ук булган. Борынгы карталарда аның исеме бар.

Додона андагы патшадан үзенә бераз җир бүлеп бирүен сорый, биредә йорт салмакчы була. Патша аның үтенечен кире кага. Эш болайга киткәч, Додона патшадан бер үгез тиресе капларлык кына булса да җир бирүен үтенә. Патша, бу көтелмәгән үтенечтән кызык табып, аңа рөхсәт бирә. Додона зур һәм таза үгез суйдыра да аның тиресен бик тар тасма рәвешендә кисеп чыга һәм, тасманы ялгап, шактый зур җирне урап ала. Патша үзенең отылуын күрә, әмма әйткән сүзеннән кире кайтмый. Додона шул җирдә үзенә ныгытылган корылма төзетә. Ул аны «Бирса» дип атый, бу «тире» дигәнне аңлата икән. Риваять Карфагенга нигез салыну вакыйгасын менә шулай бәян итә. Тик ул матур риваять кенә. Аның тарихи нигезе юк.

Б.э.к. IV гасырда Карфаген шактый киңәя, анда сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, җир хуҗалары туплана. Бирса янында Мегара дип аталган торак йортлар биләмәсе үсеп чыга, карфагенлылар ул заманда ук күпкатлы йортлар төзи башлыйлар. Карфагенның көчле флоты һәм гаскәре барлыкка килә. Анда гаскәр ялланган сугышчылардан гына торган. Карфагенлылар үзләре хәрби хезмәткә алынмаган. Аларның йөзләгән филләрдән торган махсус гаскәре дә була. Алар Урта диңгездә, беренчеләрдән булып, биш палубалы кораблар төзи башлыйлар. Карфагенлыларның элекке ватаннары булган Финикиянең Урта диңгезнең көнбатышында йогынтысы кими төшү белән, Карфаген әлеге колонияләрне үзләштерүгә ирешә. Б.э.к. III гасырда Карфаген Урта диңгезнең көнбатышында иң зур һәм иң көчле дәүләткә әверелә һәм Көньяк Иберияне, Төньяк Африканы, Сицилия, Сардиния, Корсика утрауларын яулап ала. Бу дәүләт шулай ук Африка белән Сицилия утравы арасындагы диңгезне дә даими үз контролендә тота һәм башка илләрнең сәүдә корабларын Көнбатышка, ягъни Иберияга (Италия), Гибралтар бугазына таба үткәрми.

Әлеге дәүләткә Мальта һәм аның янындагы ике утрау да керә. Карфаген Сицилия утравында төпләнгән греклар белән даими көрәш алып бара. Аның мондый сәясәте ныгый барган Римда да нәфрәт уята. Нәтиҗәдә, Рим аның кан дошманына әверелә. ■

«Мактанырлык татар кызлары – Балкан сугышында «Һилял әхмәр» шифаханәсендә ярдәмләшкән туташлар». «Аң» журналы. – 1913. – №16.

Татар кызлары – Балкан сугышында

1912 елның 8 ноябрендә журналист Фатих Кәрими җитәкчелегендәге бер төркем татар кызлары – Чистайдан Өммегөлсем Камалова, Петербургтан Ркоя Юнысова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Паташевалар, Одессадан пароходта кузгалып, 9 ноябрьдә Истанбулга килеп төшәләр. Петербургтагы Югары хатын-кыз медицина курсында укучы бу туташларның максаты – Балкан сугышында авыр хәлдә калган төрек кардәшләребезгә хәл кадәри ярдәм итү. Шулай итеп, алар биш ай дәвамында «Һилял әхмәр» («Кызыл ай») җәмгыяте карамагындагы хастаханәдә шәфкать туташы булып эшли, сугыш кырында яраланган төрек гаскәриләренә медицина хезмәте күрсәтә.

Яралыларны дәвалаудан кала, татар кызлары төрек хатын-кызлары хәрәкәтен оештыруда да актив катнаша. Өммегөлсем Камалова төрекләрнең иң мәртәбәле

мөгаллимәләре, әдибәләре җыелган митингта – университет залында татар кызлары исеменнән чыгыш ясый. Җыенда 6 меңнән артык хатын-кыз катнашуы билгеле.

Татар кызларының төрек кардәшләребезгә күрсәткән игелеге Госманлы империясе җитәкчеләренә дә барып ирешә. Төрек солтаны Мәхмәд Vнең аларны кул күтәреп сәламләве, садер әгъзам (баш министр) Мәхмүд Шәүкәт пашаның кызлар белән кул биреп күрешүе мәгълүм. Паша татар шәфкать туташларына: «Мөселман хатын-кызларының зур калебле, галиҗәнап икәнлеген сез гамәлдә күрсәттегез!» – дип, олы рәхмәтләр дә әйтә. Фатих Кәрими «Истанбул мәктүбләре»ндә татар кызлары турында: *«Эштә, урамда, җәмәгать оешмаларында, халыклар арасында үзләрен тота белүләре, булдыклылыклары белән алар һәр очраган кешеләрне үзләренә хөрмәт белән карарга мәҗбүр итәләр»*, – дип язып калдырган[1].

Сүз уңаеннан: Балкан сугышында катнашкан кызларның берсе – Мәрьям Якупованың (1887-1971) 1915 елда Мәскәүдә Гаяз Исхакый чыгарган «Ил» газетасында «Милли гимназия кирәк» дип исемләнгән мәкалә бастыруы билгеле. *«Минем телемнең кай җире җитмәгән? Аның нинди зур гаебе бар, нигә шулкадәр үз телемезне яхшылап өйрәнмибез? Нигә без төрле фәннәр белән үз телемез аркылы танышмыйбыз. «Китап юк», дию, миңа калса, җавап түгел, гыйлем – дөньяда бер генә. Шул бер гыйлемне төрле халык үз телендә өйрәнә. (...) Минемчә, баланы яшь чагында үз ана теле белән генә тәрбияләргә, мәктәпкә кереп укый башлагач кына, аңа рус телен кушып өйрәтә башларга кирәк. Бу вакыт инде бала үскәнрәк була һәм тәртипле укудан аңа һич зарар тими»*, – дип яза ул бу мәкаләсендә. Шактый тәҗрибә тупларга өлгергән шәфкать туташы 1922-1927 елларда Ташкент акушерлык техникумында укый. 1923 елдан Үзбәк хатын-кызлары институты укытучысы, шәһәр хастаханәсе табибәсе булып эшли.

Төркиядән кайткач, туташларның берсе Мәрьям Рәхмәт Паташева Оренбургта Фатих Кәрими мөхәррирлегендә чыга торган «Вакыт» газетасының 1913 елгы 1201, 1211, 1223, 1245 нче саннарында Балкан сугышында, хастаханәдә күргән-кичергәннәрен тәфсилле тасвирлап, «Истанбул хатирәләре» исемле күләмле мәкалә бастыра. Истәлек-мәкаләдә татар кызының, яраланган төрек ирләрен яклап, хастаханә җитәкчеләре белән каршылыкка керүен беләбез. Автор гаскәриләр кичергән газап-хәсрәтне үз йөрәге аша үткәрә, төрекләрдәге, аеруча кызлар мәгарифендәге җитешсезлекләргә сыкрана, төрки кардәшләребезнең хәлен җиңеләйтү юлларын эзли. Иң мөһиме – киләчәктә Госманлы Империясен һәлакәткә илтәчәк Балкан сугышында төрекләрнең җиңелү сәбәпләрен барлый. Төрек сәясәтчеләре милли рухлы мәктәп-мәдрәсәләрне кайгыртасы урында, милләт вә өммәтне коткару юлын читләрдән эзлиләр, тышкы сәясәт белән генә мавыгалар, ди. Мәрьям Паташева күтәргән мәсьәләләр госманлы мәмләкәтенең әчтән таркалып килүенә җан сыкравы булып яңгырый, илгә һәм милләткә сугышларсыз гына зур үзгәртеп корулар кирәклегенә ишарәле.

Текст төрек кардәшләребезгә дә адресланып язылган булса кирәк. Бу инде «Вакыт» газетасының таралу географиясе Россия белән генә чикләнмәгәнлеге турында сөйли.

Мәкалә тулысы белән диярлек хәзерге татар әдәби теленә якынайтылды. Кайбер төрекчә сүзләрнең тәрҗемәсен ачыклауда, астөшермәләрне, Төркия чыганакларыннан фотоларны барлаудагы ярдәме өчен, **Фатиһ Кутлу**га олы рәхмәтебезне һәм ихтирамыбызны белдерәбез. ■

[1] Бу турыда М.Гайнетдиннең «Татар кызларын төрек солтаны да сәламләгән» (Заман-Татарстан. – 1997. – 28 март), «Халык каһарманнары» (Сөембикә. – 1997. – №6. – Б.13-14.) исемле мәкаләләреннән, Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүбләре» хезмәтеннән тулырак укып белергә мөмкин.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

Мәрьям Рәхмәт Паташева

Истанбул хатирәләре

Кадырга хастаханәсе. Истанбул, 1915 ел

I

Италия сугышы туктар-туктамас, Төркия дәүләтенә рәхәт бирмәс өчен, Яуропа сәясәте балканлыларны Төркия өстенә җибәргән иде. Сугыш башланды. Балкан христианнарына һәр тарафтан төрле ярдәм күндерелә башлады. Әүвәлге сугышларда хәлдән тайган Төркиягә һичбер тарафтан ярдәм юк иде.

Ватан юлында, дин юлында җаннарын фида кыла килгән төрек гаскәриләренең хасталарына, яралыларына сугыш мәйданында хезмәт итәр өчен дүрт кыз, Петербургтан сәфәр итеп, Истанбулга килдек. Истанбулда Кадырга[2] исемендәге хастаханәдә биш ай хезмәт иттек.

Истанбул – тәмам дөнья җәннәтедер: вакыт кыш фасылы булса да, һәр тарафта яшеллек, күк йөзе ачык, кояш иртәдән кичкә кадәр матур җирләрне һәр тарафтан яктырта, җан бирә, һәр җирдә зур, гүзәл мәчетләр, озын, матур манаралар бөек шәһәргә зиннәт биреп торалар.

Без кайттык... Ләкин минем күңелем – һаман Истанбулда. Хасталар янында биш ай хезмәт минем күңелдә бик тирән эз калдырды. Истанбулда һаман буласым килә: дин юлында җаннарын фида иткән хасталарның тавышларын һаман ишетәсем килә; һәр җирдә, һәр нәрсәдә бар гүзәллекне күрәсем килә; төрекләрнең һәрбер эшләрендә күренеп торган аяныч ялкаулыкларына хәсрәт күзе илә карап, сүзләрем илә аларга бераз булса да җан бирәсем килә; күңелебезгә авырлык, йөзебезгә кызыллык бирә торган ялкаулыкларын әллә нинди бер куәт илә бетерәсем килә... Күңелемдә калган хатирәләремне

[2] Кадырга – бу сүз төрек теленә грек теленнән кергән (катергон). Җилкән һәм ишкәк ярдәмендә тиз йөрешле, егерме биш урынлы элеккеге сугыш көймәсенең атамасы.

Русия мөселманнарына белдерәсем килә, төрек кардәшләремә әйтәчәк сүзләремне «Вакыт» газетасы аша әйтәсем килә.

Истанбулга барудан элек тә, Истанбулга ирешүнең әүвәлге көннәрендә дә төрекләрнең чигенүләренә без ышанган идек. Ләкин, төрек хасталарының хәлләрен белә башлагач, әүвәлге иманыбыз, берничә көннән соң, янә куәтләнә башлады. Һәр тарафта төрек гаскәренең җиңелү хәбәрләре һәр көн, һәр сәгать килә башлады. Кадырга хастаханәсенең баш табибы яһүди Сухами төрек гаскәренең җиңелүләрен, качуларын һәрвакыт шатлык илә көлеп сөйли иде. Кыска буйлы, калын тәнле, зур корсаклы, исерек яһүдинең шатлыкларына протест ясаучы һич юк диярлек иде. Табиб Сухами илә бу турыда мин һәрвакыт талаша идем. Табиб Сухами, һичбервакыт үзенең шатлыкларын үзгәртмәсә дә, миңа һәрвакыт: «Мәрьям ханым, син һичбер эш аңламыйсың!» – ди торган иде.

Бәсим Гомәр Акалын

Тора-бара шатлыклар арта башлады. Яһүди Сухами, студент Жузеф, хастаханәдә мадам Дәрузман бүлмәсендә тупланып, һәр кич шәраб мәҗлесләре ясый башладылар. Мадам Дәрузманның романсларын алкышлап, төн буена кәеф-сафа кыла башладылар.

Һиндстаннан «Һилял әхмәр» җәмгыятенә күндерелгән егерме ике адәм, Кадырга хастаханәсенә урынлашып, бер ай кадәр эшсез тордылар. Көндезләрдә Истанбул тамашаларына йөреп, кичләрдә Сухами, мадам Дәрузман компаниясендә кәеф-сафа сөрәләр иде. Мадам Дәрузман зур тавыш илә романслар җырлый иде, компаниясе хастаханәне яңгыратып алкышлый иде.

Кәеф-сафа бүлмәсе безнең бүлмәбезгә якын иде. Исерек компания тавышлары бичара хасталарның рәхәтен ала иде. Бутылкалардан атылып чыккан пробка тавышларыннан җаныбыз газаплана иде. Истанбул капусы төбендә ислам каны түгелеп торган сәгатьләрдә, мескен хасталарны онытып, бер мадам гыйшкына бутылкалардан әллә нинди шәраб түгеп, кәеф-сафа кылмак безгә бик авыр, бик гаҗәп күренә иде.

Һиндстан адәмнәре Җиталҗа янына хастаханәләр ачу өчен киттеләр. Кәеф-сафа компаниясенең әгъзалары аз калды. Хастаханәдә яхшы гына әдәпле аптекарь Гасыйм бәк бар иде. Элек бик яхшы эшли иде. Мадам Дәрузман Гасыйм бәкне дә компаниясенә тартты. Бичара Гасыйм бәк тә, шәраб мәҗлесләренә ияләшеп, Сухами кеби һәрвакыт сәрхуш була башлады.

Хастаханәдә мондый әдәпсезлек без киткәнгәчә дәвам итте. Хасталар, хастаханә адәмнәре бу әдәпсезлекләргә, бәлки, разый булмаганнардыр, ләкин баш доктор Сухамига авыз ачып бер сүз әйтүче булмады. Мин ерничә кат Сухами яһүди илә шул хакта да талаштым: һичбер илтифат кылмады, һаман үз эшләрендә дәвам кыла иде.

«Һилял әхмәр» рәисе доктор Бәсим Гомәр пашага[3] без һәм дә бәгъзе адәмнәр шикаять кыла идек. Доктор Бәсим Гомәр паша әйтә торган иде: «Тыныгызны чыгармагыз! «Һилял әхмәр» намусын хурламагыз! Төркиягә рәхәтсезлек бирмәгез. Бу эшләрне мин

[3] Бәсим Гомәр Акалын (1862-1940) — төрек табибы, заманча гинекология һәм акушерлыкка нигез салучы. Бу елларда төрекләрнең Кызыл Хач җәмгыяте директоры.

үзем багармын!» Ләкин, нидәндер, һичбер вакыт бакмады. Әдәпсезлек хастаханәдә һаман дәвам итә иде. Алай гына түгел, бәлки Сухамигә: «Хастаханәне фәхешханә иттең!» – дигән доктор Әхмәд әфәндене, төрле фетнәләр кылып, Сухами сөрдерде.

Хастаханәбездә тәртип тә юк, баш доктор күбесенчә исерек була иде. Хасталарны карау сәгатьләрендә дә һаман исерек була иде. Бик күп вакыт хасталар өстенә ава иде. Хезмәт итүчеләргә дә күп әдәпсезлекләр кыла иде.

Склад хезмәткәре Хатифә ханым хасталарга да, хезмәтчеләргә дә һичбер вакыт рәхәт бирми иде. Юк-бар нәрсәләрне сылтап, бичара хезмәтчеләрнең җаннарын ала иде. Хасаталарга эчке кием йә җаймә алган сәгатьләрдә талашудан башка һичбер вакыт алып булмый иде. Хасталарның җаймә, эчке киемнәре күп вакыт пычрак кала иде.

Яралыларга операция ясаганда да хастаханәләрдә бик күп илтифатсызлык күренә иде. Кадырга хастаханәсендә операция күбрәк мадам Дәрузман кулы белән ясала иде. Мадам Дәрузман операция вакытларында да, яраларны сару вакытларында да бичара хасталарга бик зәхмәт бирә иде.

Фәкать практика өчен генә килгән немец студентлары мескен төрек гаскәрләрен хайван кеби турап-кисеп, яраларын казып, бик күп хасталарны тәҗрибә юлында фида кылганнар. Башка хастаханәләрдән Кадырга хастаханәсенә күчеп килгән яралы хасталарны күреп, аларның шикаятьләрен ишетеп, мин хәйран була идем, күңел сукрана иде. Бичара хасаталарның аяныч хәлләрен күреп, Кадырга хастаханәсендәге әрмән Җырах Ягъкубиян әфәнде илә Капамачьян әфәнде һәрвакыт шикаять кыла торганнар иде.

Мондый аяныч хәлләр бер түгел, ун түгел, бик күп иде. Яшь чактан хәтеремдә калган – әбием әйтә торган иде: «Әй, Мәрьям, күргәнең бер тугыз, күрмәгәнең унтугыз!» Мәрхүм әбиемнең шул хикмәтле сүзе Кадырга хастаханәсендә һәрвакыт хәтеремә килеп, бичара төрек гаскәренең авыр хәлләренә күңелем яна, газаплана, баш ватыла, йөз кызара иде.

Бу хәлләр бер миңа гына түгел, бәлки, хөкүмәт адәмнәренә дә, төрекләрнең үзләренә дә, хастаханә табибларына да, әлбәттә, мәгълүм иде.

Балаларын, ата-аналарын ачлыкта ташлап, бичара гаскәри сугышка китә. Дин юлында, ватан юлында ун көн, унбиш көн ач-ялангач йөреп, сугыш мәйданнарында шәһид була, әгъзасы сына, җәрәхәтләнә, хасталана. Кыш көннәрендә кырда кала. Салкынлыктан, ачлыктан, сусызлыктан, ялангачлыктан, дәһшәтле газап күрүдән үлә. Меңнән bере үзенең көче илә, кесәсендә бар акчасы илә миллион зәхмәт күреп, көчкә генә Истанбул хастаханәләренә үзе килеп җитә. Җәрәхәтле булса, әгъзасы сынган булса, бичара хаста мадам Дәрузманнарның «мәрхәмәтләренә», алман студентларының кулларына тапшырыла да, зәхмәт, мәшәкать күреп, күбрәк вакытта теге дөньяга китә. Сугышта ач-ялангач йөргән бичара гаскәри хастаханәдә һаман ач тора. Һаман түбәнсетелә, һаман зәхмәтләнә. Суда пешерелгән аз гына дөге бирәләр. Бичара гаскәри икмәк өчен дә талаша. Илтифат юк. Арттыру, туйдыру юк. Ачлыктан йөдәгән бичара хаста тапса – урлый, тапмаса – һаман ач кала, акчасы булса, сатып ала.

Мондый хәлләрне белә, күрә торып, хөкүмәт адәмнәренең разый булуларына, мөселман төрекләренең тик торуларына мин бик гаҗәпләнә идем. Алман студентларына айга йөзәр лира биреп тә, мөселман гаскәриләренең хасталарын ач-ялангач тоту, мадам Дәрузманнарның гыйшкына чамасыз хөрмәт күрсәтеп тә, мөселман гаскәриләрен хур кылу бөтенебезгә гаять уңайсыз күренә, гакылдан шаштыра иде. Шикаять кыла идек, ләкин файдасы юк иде. «Тынычызны чыгармагыз! «Һилял әхмәр» намусын пычратмагыз!» – диюдән башка бер җавап юк иде.

Мин моңа бик аптырап кала идем. Тын чыгармау ни өчен иде? Хыянәтләргә, хурлыкларга разый булуның сәбәпләре ни иде? Хөкүмәт нигә болай булган? Төрек халкы ник

бу хәлләргә калган? Мондый сораулар күңелемә килә башлады. Шуңа күрә төрекләрнең һәрбер эшенә, хасталарның хәлләренә, сүзләренә хәсрәт күзе илә, игътибар күзе илә карый башладым.

Биш ай эчендә вак-төяк байтак хәлләр күрдем, гаҗәп нәрсәләр ишеттем.

II

Бөтенләй һәлакәт булмаса да, бөтен Төркиянең бу кеби хурлык астында калып, зур фаҗигаләргә төшүенең сәбәпләре нидә?

Моның сәбәпләре бик күптер. Аларны тикшерү вазыйфам булмаса да, шул дәһшәтле тарихи вакыйгалар вакытында Төркиядә булганлыгымнан, кайберләре хакында аңлаган кадәр язуны тиешле күрәмен. Төркияне бу кеби бәхетсезлекләргә китергән сәбәпләрнең кайсылары шул вакыйгалар вакытында мәйданга килгән булып, кайсылары исә электән киләләр. Бу сәбәпләрнең бере – Төркиядә гаилә мәсьәләсе, дип беләм. Чөнки бу мәсьәлә аларда хәзергә кадәр хәл ителмәгән. Моннан ничә йөз еллар элек ничек булган булса, хәзер дә шул көйдәдер.

«Бала вакытта ватаннан аерылган рух, зурайгач та ватанга якын булмый»

Гаиләдә ниндидер бер уңайсызлык бар: ир илә хатын тормышы бер түгел. Ире – бер дөньяда, хатыны икенче дөньяда тора. Берсе икенчесен аңламый һәм аңларга да теләми. Шулай итеп, гаиләдә иң кыйммәтле булган мәгънәви бәйләнеш югалган һәм гаилә үзенең төсен җуйган. Шул сәбәптән булса кирәк, балалар тәрбиясе дә уңайсыз бер хәлгә килгән: ата булган кеше балалар тәрбиясе хакында уйламый, бәлки, бала тәрбиясе илә мәшгуль булырга вакыты да юктыр. Чөнки ул иртә белән йокыдан торгач та каһвәсен эчә, бала-чагасын күрмичә чыгып китә. Көндез илә аш вакытында өенә кайтып, хатын, бала-чагасы илә сөйләшеп, рәхәт-рәхәт ашап ял итәсе җирдә, берәр ашханәгә кереп тамагын туйдыргач, эше булса, эшенә китә, булмаса, тулып яткан каһвәханәләрнең беренә кереп, уймак кадәр бер чынаяк каһвә илә сәгатьләрчә гомер үткәрергә һич авырсынмый, иренеп кенә сугыш мәйданында булган уңыш яки уңышсызлыклар хакында сөйләшә яки аны да бик авыр эш санаган шикелле, һичбер нәрсә сөйләмәстән, наргилә *(кальян)* тартып яртылаш йоклап, үзенчә рәхәт итәдер. Шулай итеп, ата балалар тәрбиясенә һич катышмый, бәлки, көн буена балаларын исенә төшергәне дә беленмидер.

Аналары да бала тәрбиясенә зур әһәмият бирмәгән шикелле күренә. Бала кечкенә икән, аны ашатып-эчертеп тамагын туйдыру тәрбия саналып, бала зурая төшкәч, мәктәпкә җибәрәләр. Шуның илә эш тәмам була. Бала ничек укый, әхлагы ничек – бу хакта һич уйламаган төсле күренә.

Гомумән, төрек хатыннары ялкау. Дүрт-биш көнлек ашны берьюлы пешереп (һәркөн аш пешереп үзен рәхәтсезләтми), шуны һәр көн җылытып кына ашыйлар. Шуннан башка эше юк. Шуңа күрә тик утыра, эче пошса, тәмәке тарта, каһвә эчә, баерак гаилә булса, пианино уйный, чит телдән тәрҗемә ителгән юк-бар мәгънәсез романнар укый, шулай итеп көнне үткәрә.

Төрек хатыннары урамда йөргәндә дә ялкаулыкларын ташлый алмыйлар. Берничәсе бергә урам буенча акрын-акрын йөри. Читтән караган кешегә боларның бер дә эшләре юк төсле күренә. Йөзләре капланган булса да, үткән-барган кешеләрне дикъкать илә карап калалар.

Гомумән, төрекләр үзләре һәм хатыннары акрын йөрергә яраталар. Ашыкмыйлар, ашыгып-ашыгып, эшемнән калмыйм, тиз генә җитешим, дип йөргән бер төрекне күрергә

«Вәфа Идадиси» мәктәбе

никадәр теләсәм дә, һич күрә алмадым. Кыскасы, төрекләрдә иҗтиһад юк, бөтен милләтне ниндидер куркыныч ялкаулык, эшсезлек, хәтта өметсезлек чолгап алган.

Төрекләр, шулкадәр ялкау булган хәлдә, тышкы якны матурлауга иренмиләр. Хатыннарның да һәм ирләрнең дә тышкы яклары кирәгеннән артык тәртипле: чәчләре гаять яхшы таралган булып, һичбер чәч чыгып тормас, киеме яңа гына тегүчедән алынган шикелле таза, бөкләнгән-җыерылган җире юк, ботинкалары иң соңгы модада ясалган – һичбер сүз әйтерлек түгел. Ике кулын кесәләренә тыгып тик йөри – киемем бозылыр, дип, утырырга да курыккан шикелле күренәдер. Мондый кешеләр тәмам ясап куйган матур, ләкин җансыз курчак кеби күренеп, карауга да бик аянычтыр.

Кешеләр тәртипсез, пычрак йөрергә тиешледер, дип әйтмим. Әлбәттә, һәркем үзен ару йөртергә тиеш. Ләкин төрекләр бигрәк тә артык кыланалар. Карт кына ирләр, башка эш беткән шикелле, үтеп барган хатын-кызның киеменә дикъкать итеп: «Бу хатынның киеме тар, моныкы киң, килешсез...», – шикелле мәгънәсез сүзләр сөйләп торудан тартынмыйлар. Хәтта минем иске зур якалы туным да аларның дикъкатеннән котыла алмады, аны да сөйләп калганнарын ишетергә туры килә иде. Болай әйткәнче, бу әфәнделәр кирәкле бер эш илә мәшгуль булса иделәр! Эш юкмы? Эш күп, эшләүче юк... Аеруча Ватан шундый хәлдә булып, һәр угылыннан ярдәм көткән бер вакытта төрекләрнең болай эшсез, һичнәрсә уйламый йөрүләре кешеләргә бик авыр буладыр.

Бу – тыштан күренеш, тышкы тараф, әмма мәгънәви тормыш төрекләрдә күренмидер. Гаиләдә ирлек юк. Ире, хатыны бөтенләй башка, һәркайсы үз дөньясында тора, ире хатынына тәмам хуҗа, хатыны иренә тәмам кол шикелледер: ире ни әйтмәсен, ни кушмасын, хакы бер ахмаклык булса да, хатын, һичбер сүз әйтмәстән, шуны эшләргә мәҗбүрдер. «Бездә хатыннар ирләренең гакылга сыймастай әмерләренә итагать кылмыйлар», – дисәк, төрекләр бик тә гаҗәпләнәләр. Хатын иренең әмеренә буйсынмауны төрекләр аңлый алмыйлар, чөнки, алар фикеренчә, хатын – бөтенләй ихтыярсыз бер колдыр.

Гаилә хәле, югарыда әйтелгәнчә, уңайсыз бер рәвештә булудан, һәммәсеннән бигрәк, мескен балалар зарар күрәләр. Ата-анасы яхшы тәрбия итә алмый, яхшы тәрбия бирерлек мәктәпләре дә юк диярлек. Аеруча кызлар өчен яхшы мәктәп бик сирәк. Мондый мәктәптән әдибә Халидә ханым[4] мәктәбе иң яхшылардан саналырга тиеш. Бинасы зур булмаса да, якты, һәр җирдә чисталык, парталар, уку әсбаплары да бик яхшы, барып кергәч тә кешегә яхшы тәэсир итә, күңелгә шатлык бирәдер. Бу мәктәптә кызлар да

[4] **Халидә Әдип Адывар** (1882-1964) — төрек сәясәтчесе һәм җәмәгать эшлеклесе, романнар авторы, Ататөрекнең якын дусты һәм көрәштәше.

яхшы, гакыллылар, үзләрен хөр генә тоталар, куркып-өркеп тормыйлар, хәтта бөтен Төркиядә беренче булган хатыннар җәмгыятендә шул мәктәп шәкертләреннән нотык сөйләгәннәре дә булды. Мөгаллимә илә шәкертләрнең мөгамәләсе иптәш мөгамәләсе шикелле. Белмәгәннәрен, шәкертләр һич тартынып тормый, сөекле мөгаллимәләреннән килеп сорыйлар. Алар да аналары шикелле бик якты йөз белән генә аңлатып, аларның тәрәккыйсенә ярдәм итәләр. Бу мәктәпкә әйтәсе бер сүз юк, фәкать, кызганыч ки, мондый мәктәпләр бик аз. Мондыйлар күбрәк булса иделәр!

Халидә Әдип Адывар

Башка мәктәпләргә кереп, карап йөрергә туры килмәсә дә, тыштан караганда, бик начар күренәләр: тәрәзәләре аз, кечкенәләр, ишекләре дә кечкенә, зуррак балаларга баш иеп керергә туры килә, коридоры пычрак... Шуларны күргәндә бик уңайсыз була, өмет өзү дәрәҗәсенә киләсең. Тышы болай булгач, мәктәпнең эче дә тәртипсездер, дигән уй килә...

Айя-Суфия мәчете яныннан үткән вакытта урамның икенче ягында ике яки өч катлы бер йорт күрдем. Бинасы – таш, сөйкемсез, тәрәзәләре кечкенә генә, пыялалары ватык... Ватык тәрәзәләренең берендә үсеп утырган матур кызыл чәчкә күренмәсә, бу йортны тәмам хәбесханә *(төрмә)*, дип уйланырлык иде. Әмма бу хәбесханә түгел, бәлки, киләчәктә Төркияне коткарачак, Төркиянең өмете булган балалар мәктәбе, имеш... Соңыннан мондый хәбесханә шикелле мәктәпләрне күп күрдем, болар аз түгел, әмма «Мәктәбе Солтани», «Вәфа Идадиси» кеби күңелгә шатлык, өмет бирә торган мәктәпләр бик аз.

Диңгез бугазы эчендә бик яхшы мәктәпләр күрдем. Бинаалары зур, тәрәзәләре дә зур, якты, диңгез янында гына, манзаралары да бик матур, һава яхшы, тирә-ягында җәннәт кебек зур-зур бакчалар. Бу мәктәпләр Төркиядә, әмма төрекләрнеке түгел, чит милләтләр мәктәбе. Боларның шәкертләре сәламәт, тазалар, шатлар. Югарыда сөйләгән төрек мәктәпләренең шәкертләре арык, йөзләре сары, күңелләре төшкән булып, араларында аерма бик зурдыр. Тышларында аерма булган шикелле, боларның рухларында да аерма булачагына шөбһә юктыр.

Үзләрендә шундый яхшы мәктәп булмаганлыктан, төрекләрнең зурлары балаларын чит милләт мәктәпләренә бирергә мәҗбүрләр. Фән өйрәнү өчен бу мәктәпләр бик яхшы булса да, төрек балаларының мәгънәви тәрбияләрендә зарарлы булачагы шөбһәсез. Бу мәктәпләрдә ватан, ислам тәмам бетерелә, балалар Төркияне сөймәс дәрәҗәгә киләләр. Бала вакытта ватаннан аерылган рух зурайгач та ватанга якын булмый. Шул юл белән төрекләр үзләреннән-үзләре, һич сизмәстән, төреклекне һәм Төркияне бетерүгә ярдәм итәләр.

Хәтеремдә калды: дәүләт әгъзаларыннан беренең балалары француз мәктәбендә укый иде. Балаларның аналарына: «Чит ил мәктәпләрендәге тәрбия төрек балаларындагы ватан вә ислам мәхәббәтенә күп зарар китерә, бәлки, ул мөкатдәс хисләрне

Солтан мәктәбе

бөтенләй бетерә», – дип, сүз арасында әйтүемдә, ханым-әфәнде: «Юк, алай булмас! Мин үзем аларны тәрбия кылам, ватанга мәхәббәтләрен арттырырга тырышам», – диде. Бу сүзләргә бөтенләй ышанып бетмәгәнлектән, ханым-әфәнденең кәефе китә төште. Кайсыбызның фикере тугры икәнен ачык хәл итү өчен, ханымның иң кечкенә кызын чакырып, сөйләшергә уйладым. Бу кыз чакта чит ил мәктәпләрендә тәрбияләнгән балаларның берсе иде. Кызчык килгәч: «Төркиянеме, Франциянеме күбрәк сөясең?» – дип, төрекчә соравыма, бала, һич уйламастан: «Әлбәттә, Франциячне күбрәк сөям!» – дип, французча җавап бирде. Мескен бала, төрекчә сөйли белсә дә, ана телендә сөйләмәскә тырыша. Ханым-әфәнде аптырап калды, ни әйтергә белмәде, ниһаять, бик төшенке тавыш белән: «Үзебездә яхшы мәктәпләр юк, балаларыбызны шулай тәрбия итәргә мәҗбүрбез инде», – диюдән башка бер сүз тапмады. «Сез үзегез яхшы мәгълүматлы бер ханым. Сезнең кеби башка ханымнар да юк түгел. Җыелышып берәр милли мәктәп ачсагыз, шул мәгъсум төрек балаларын төреклек вә ислам рухында тәрбия итү шикелле мөкатдәс бер эш башласагыз, киләчәктә Төркия читләр йогынтысыннан котылып, сезгә милләт тә, тарих та рәхмәтләр укырлар иде...» – дидем. Ханым-әфәнде бик уңайсызланды, бер сүз әйтмәсә дә, йөзендә күренгән яшь галәмәте бу эшләрнең булуына ышанмаганлыкны күрсәтә иде.

Ахыры бар

*Кереш мәкалә һәм текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Татар матбугаты тарихы

«ТАРТЫШ» ГАЗЕТАСЫ

Газета 1918 елның апрель башыннан Әстерханда чыга башлый. Матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев «Тартыш» турында: «Эчтәлеге ягыннан гәзиткә сүз тиереп булмый, тик техникада гына аксады. Һәрхәлдә үзенең губерна гәзите булучылык вазыйфасын кирәк кадәренчә үтәп бара иде. «Нәшрият» типографиясендә басылган. Барысы 9 ай чыгып, шул ук елның декабрендә тукталган», – дип яза.

«Тартыш» газетасы.
1918 ел

استرخان ولایت مسلمان کامیساریاتی ناشر افکاری بولغان صول ساتسیالیستلر غزیته‌سی.

газета „ТАРТЫШЪ“
Выходитъ въ недѣлю два раза, лево-соціолистическаго напровленія. органъ Астраханскаго Комиссаріатапо Мусульманскимъ дѣламъ при губернскомъ исполнительномъ комитетѣ совѣтовъ.

ПОДПИСНАЯ ЦѢНА
на 12 мѣс. 20 руб.
» 6 « 12 «
« 3 « 7 «

ОТДѢЛЬНЫЕ №№ 35 К.

адресъ; Астрахань на Канавѣ домъ Мирманова редакція газ. «ТАРТЫШЪ»

№ 21 — 1918 يل

Т. И. ЗАКСЪ
Женщина - Врачъ

Зубной Врачъ
БУРАОВА

Докторъ
К. Л. Клашанцъ

газета
„ТАРТЫШ“
Выходит два раза в неделю, орган Комис. по Мусульм. делам Астраханскаго Края.

ПОДПИСНАЯ ЦѢНА
на 12 мѣс. 20 руб.
» 6 « 12 «
« 3 « 7 «

ОТДѢЛЬНЫЕ №№ 35 К.

адресъ; Астрахань на Канавѣ домъ Мирманова редакція газ. «ТАРТЫШЪ»

№ 53 — 1918 يل

№ 3

Знамя труда

КАЗАНЬ
уг. Сенной и Тихвинской ул. д. ...
бр. Каримовых, в мусульманское
БИБЛИОТЕКА



Касыйм Шаһиҗиһан улы Туйбактин (1888-1918) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, нәшир. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. Әстерханда Г.Тукай белән очрашуы мәгълүм. Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша, Георгий тәресе белән бүләкләнә. 1918 елда Урта Идел буендагы җирсез крестьяннарны күчереп, Әстерхан шәһәре янындагы Яңа Болгар авылын оештыруда башлап йөри. Шул ук елда Әстерхан Мөселман эшләре комиссариаты рәисе итеп сайлана. Татар, казакъ, азәрбайҗан халкы арасында мәдәни-агарту эшләре алып бара, китапханәләр, курслар ача. 1918 елның 15 августында Әстерханда инкыйлабка каршы фетнә вакытында һәлак була.

Басманың үзендә: «Әстерхан вилаяте мөселман комиссариаты нәшер әфкяре булган сул социалистлар гәзитәсе. Атнага ике мәртәбә чыга. Басылды – Әстерханда, «Тартыш» матбагасында», – дип әйтелә.

Әстерхан губернасы мөселман эшләре комиссариаты 1918 ел башында, Әстерханда совет хакимияте урнашканнан соң оеша. Шул елның августында акгвардиячеләр фетнәсе вакытында комиссариат җитәкчесе Касыйм Туйбактин үтерелә, кайбер кешеләр җәрәхәтләнә. Мөселман комиссариатының иң төп бүлекләреннән берсе хәрби вә сәяси эшләр комиссариаты була. Гаскәри комиссар итеп Әхмәд Гомәров тәгаенләнә. Ул мөселманнарны хәрби яктан оештыру, халыкны хәрби укыту, татар-мөселман полкларына, аеруча Кызыл Армиянең мөселман бүлекләренә һәм Туйбактин исемендәге 1 нче мөселман җәяүле полкына гаскәриләр туплау белән шөгыльләнә, контрреволюция белән көрәшә. Әстерхан губернасы мөселманнарының хәрби һәм сәяси эшләре комиссариаты хозурында агитация һәм белем тарату бүлеге дә була. Моннан тыш, Әстерхан шәһәрендәге һәм губерна авылларындагы бөтен мәктәпләр дә мөселман мәгариф комиссариатына кертелә. Аның рәисе итеп Шәриф Саттаров билгеләнә. Комиссариатның мәктәптән тыш мәгариф, театр һәм сәнгать бүлекләре дә булган. Шәһәрдә Мөселман социалистик клубы да ачыла, анда татар китапханәсе эшли башлый. 1918 елда Туйбактин исемендәге беренче мөселман җәяүле полкындагы көтебханәне дә шунда күчерергә карар кылалар.Финанс, тәэминат, санитар бүлекләре дә булган Әстерхан мөселман эшләре комиссариаты эшчәнлеге 1922 елда туктатыла.

Мөселман комиссариаты карамагында чыккан «Тартыш» газетасының да максаты шәһәр һәм авыл мөселманнары арасында иҗтимагый, сәяси, революцион аң-фикер тарату була. Газетада совет хакимиятенең декретлары, приказлары, большевиклар сәясәтенең программалары, «кызыл» мәкаләләр, шулай ук Әстерхан мөселман комиссариатының игълан-фәрманнары, яңалыклары, «волость шуралары һәм ярлы авыл халкы комитетлары» карарлары, чит ил, мәмләкәт һәм төбәк хәбәрләре басылган. Фронттан килгән хәбәрләргә, милли мәгариф яңалыкларына аеруча зур игътибар бирелгән. Актив авторлар арасында Ә.Гомәров, В.Салихҗанов, Х.Сәйфи, Г.Бәхтиев, Ш.Таҗетдинов, К.Габидуллин исемнәре бар. Газета 1919 елның гыйнварыннан «Көч» исеме белән чыга башлый.

Касыйм Туйбактин исемендәге полкка мөселман егетләре җыю турында игълан. 1918 ел

برلەشگز بوتون دنیا اشچیلەری !

فەقیر اشچی هەم آول خلقی باللارینە !

روسیە قوشما شورالار جمهوریەتی.

ایبدەشلەر !

سزنی، حوریەت دشمانلاری بلەن کورەشوچی، کاپیتالیستلار طرفندان ایزلگەن، جەبرلەنگەن اوز قزل کجل الەن کن کوروچی اشچی هم آول خلقی‌نڭ یاقتی کون کورولەری هم اینقیلابی ریڤولوتسیەنی بوتون مەعەنەسی بلەن خلق آراسینە کرتو، نغتو اوچون، قەدرلی جانلارون یامیچە قەهەرمانلارچە ریڤولوتسیە دشمانلاری بلەن صوغشوچی بەهادر ایبدەشلەرگز - قزل آرمیا عەسکەرلەری اوزلەرینڭ صافلارینە تزلورگە چاقرالار.

کاپیتالیست هەم ایمپریالیستلار قول آستندا ایزلگەن فەقیر اشچی هەم آول خلقلاری !!!

بر مینوت وقت کیچکدرمیچە اینقیلابی، ریڤولوتسیەنڭ صاقچیسی بولوب، قولگزغە اشتیك طوتوب. اوزگزنڭ موقەددەس وظیفەگز بولغان؛ آچ سکینلەرنڭ حالن یاخشرتو اوچون بوتون کاپیتالیست، ایمپیریالیست، اسپیکولەنت، پامیشچیك، آول قولاقلاری، کاپیتال یالچیسی آفیتسەر، یونکیر، امچیلی قازاقلارینە قارشی صوغشقە حاضرلەنگز !!!

تاتار-باشقرد شورالار جمهوریەتینڭ چیکلەرون صاقلاو، باطر یورەکلی فەقیر تاتار ییگتلەرینڭ اوستلەرینە توشکەن بورچ. بز، تاتار باللاری اوچون قەدرلی بولغان ایدل-اورال بویلارون کاپیتالیستلارنڭ یالچیلاری چیخ-اسلاواکلار، یاوز قازاقلار طرفندان تاپتالووینە کوڭلی رەنجوگەن تاتار یگتلەری مطلق قزل آرمیا فیرقەلەرینە یازلورغە تیوشلەر !!!

آشغگز ایبدەشلەر !!

تزلوگز ایزگو صەفقە !!

موقەددەس صوغشقە !!!

بوتون مەظلوملارنڭ حقی اوچون !!

وەحشیانە صورەتدە تاتار بورژویلاری طرفندان اوترلگەن قەدرلو ایبدەشمز قاسم طویباقتین اسینە توزلگەن پولکغە یازلورغە آشغگز !!!

1-й Мусульманский Советский пехотный полк, имени ТУЙБАКТИНА.

یازلورغە تلەگەن ایبدەشلەر آستراخان موسولمان عەسکەری کامیساریاتینڭ «قزل آرمییستلارنی قەبول ایتو شعبەسی» نە مورەجەعەت ایتسونلەر. هر تورلی اسپرافکالار، یازلو تەرتیبلەری شوندا کورسەتولەچەك.

Агитационно-Вербовочный отдел, Астраханскаго Мусульманскаго Военнаго Комиссариата, набереж-канава д. Сафарова.

آستراخان ولایتی‌نڭ عەسکەری کامیساری: احمد عمرف.

آگیتاشیرو - ڤیربوڤوچنی شعبە مودیری: ا. رامیەف.

اش باشقاروچی: آقچورین.

Игътибарыгызга Әстерхан губернасы мөселман эшләре комиссариаты эшчәнлеген чагылдырган кайбер хәбәрләрне тәкъдим итәбез.

БОЕРЫК №5

Бөтен мөселман волость һәм авыл советларына боералар: мөселман Кызыл Армиянең сафларын тутыру өчен, тизлек белән саф, гаярь, революцион фикердә булган иптәшләрдән һәр авылдан 18дән 45 яшькә кадәр 20шәр кеше китерсеннәр.

Гали хәрби-инкыйлаби совет әгъзасы: Антонов.

Әстерхан вилаять хәрби комиссары: Аристов.

Әстерхан вилаять мөселман хәрби вә сәяси эшләре комиссары: Гомәров.

Тартыш. – 1918. – 23 июль.

ФӘКЫЙРЬ ЭШЧЕ ҺӘМ АВЫЛ ХАЛКЫ БАЛАЛАРЫНА!

Татар-башкорт шуралар җөмһүриятенең чикләрен саклау – батыр йөрәкле фәкыйрь татар егетләренең өсләренә төшкән бурыч. Без, татар балалары өчен кадерле булган Идел-Урал буйларын капиталистларның ялчылары – чехословаклар, явыз казаклар тарафыннан тапталуына күңеле рәнҗегән татар егетләре, мотлак *(һичшиксез)* Кызыл Армия фиркаләренә язылырга тиешле. Ашыгыгыз, иптәшләр! Тезелеңез изге сафка! Бөтен мазлумнарның *(изелгәннәрнең)* хакы өчен! Вәхшиянә сурәттә татар буржуйлары тарафыннан үтерелгән кадерле иптәшемез Касыйм Туйбактин исеменә төзелгән полкка язылырга ашыгыңыз!

1-й Мусульманский Советский пехотный полк имени Туйбактина.

Язылырга теләгән иптәшләр Әстерхан мөселман гаскәри комиссариатының «Кызылармеецларны кабул итү шәгъбәсе»нә мөрәҗәгать итсеннәр.

Агитационно-вербовочный отдел Астраханского Мусульманского Военного комиссариата. Набереж.-канава. д. Сафарова

Әстерхан вилаятенең гаскәри комиссары: Әхмәд Гомәров

Аңлаштыру-вербовочный шәгъбә мөдире: Ә.Рәмиев

Эш башкаручы: Акчурин.

Тартыш. – 1918. – 8 октябрь.

МӨСЕЛМАН УКЫТУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН КЕЧКЕНӘ КУРСЛАР

Яңача 26 октябрьдә мөселман укытучылары өчен кечкенә курслар ачылды. Укытучыларымызның күбрәге укыту эшләрендә аз белемлекле икәнчелекләрен игътибарга алып, төрле мөтәхассыйслар *(белгечләр)* хәзерләү нияте белән укытучылар өчен курслар ачарга карар кылынды. Вә бу курслар 1919 елның беренче августына кадәр дәвам итәр, дип тәхмин ителә *(уйланыла)*.

Курсларның әүвәлге 3-4 аенда һәммә фән бергә укылыр. Соңра төрле фәннәрдә тәхассыс *(белгечлек)* табуга хәзерлек өчен аерым сыйныфларга бүленер. Дәрес вакытлары: кичен сәгать 6дан 9га кадәр булып, атнада 18 сәгать булыр.

Курсларда түбәндәге фәннәр укылыр: риязият *(математика)*, җәгърафия *(география)*, табигыять, рус һәм татар теле, рус һәм татар әдәбияты, тарих, рәсем, фән тәрбиянең тарихы, көтебханә эшләре, зурлар берлә шөгыльләнүнең ысулы.

Курсларда укулар рус телендә булачак. Рус телен аңлап үзләштерер өчен вә тәҗрибә хасил итү өчен, курсларның тыңлаучылары, лекцияләрдән соң, дәресләрне татарчага тәрҗемә кылырлар. Курсларга мөселман укытучылары кабул ителә, шулай ук киләчәк уку елларында укытучы булырга теләүчеләр дә кабул ителә.

Укытучылар курсына язылырга теләүчеләр 2 нче Ак мәсҗед йортында, 20 нче номерлы Муса Мөхәммәдев йортында, Вилаять мөселман мәгариф шәгъбәсендә *(бүлегендә)* кабул ителәләр.

Мәктәптән тыш мәгариф мөдире: Ф.Габдулла

Тартыш. – 1918. – 29 октябрь.

ӘСТЕРХАН СӘХНӘСЕНДӘ

25 октябрь, җомга көн Зимний театрда мөселман мәгариф шәгъбәсенең театр вә сәнгать бүлеге тарафыннан беренче мәртәбә театр уйналып, тамашага Ф.Әмирханның «Тигезсезләр» дигән әсәре куелды.

Кичә матур һәм тәртипле генә булып, халык та аз түгел иде. Артистлар да үз рольләрен шома вә матур гына чыгардылар. Тик сабыр, мөлаем вә салкынрак канлы Сәлимә ролендәге Мәрзия ханым бераз кайнар канлык белән ашыгып, кычкырыбрак уйнаган кебек булды, ләкин зарарсыз иде.

«Тигезсезләр» Әстерхан сәхнәсендә берничә мәртәбә куелды вә һәр куелуында халык күп булып килә. Ләкин халыкның күп килүен «Тигезсезләр»нең яхшы бер әсәр вә аны яратуларыннандыр диеп булмыйча, бәлки, халкымызның театрга мохтаҗ, үз сәхнәсен вә үз сәхнәсендә үз тормышын күрәсе килгәнлегеннәндер, диясе килә.

Бу әсәр – милли бер мөхәррир тарафыннан ялкынлы милли рухта язылган әсәрдер. Моның «милләт», «татар теле», «татар сәүдәсе» диеп җан ата торган милли каһарманнары, милләтне бик тар мәгънәдә алып, аны кәләпүшле татарларның ак яка, кыйммәтле кием киеп, галстук бәйләгән, алтын-көмеш белән зиннәтләнеп,

Биредә татар спектакльләре дә куелган

энҗе-мәрҗәннәргә чумган вә берничә йөз кешене үз корсагы өчен эшләтә алып, шулар җилкәсендә «баһадир», «каһарман», «җөрәкле», тагы әллә нинди «татар» була ала торган бер сыйныфка гына хаслап, каһарманнарның агызларыннан чыга торган ялкынлы «милләт» дигән сүзгә югарыдагыларны гына кертеп, шул ук кәләпүш вә калфаклыларның куллары сөялле, кәләпүш вә алъяпкычлары майлы, аяклары чабаталы «мужик» дигәннәрен моның тышында калдырып, алар өчен артык аһ та ормыйлар, җан да атмыйлар.

Тартыш. – 1918. – 29 октябрь.

ИГЪЛАН

Мин 25 нче октябрьдән үземне мөселман сул эсерлар оешмасыннан чыккан хисаплыйм. Мөселман сул эсерларның соңгы вакытта тоткан юллары – үз кардәшләре уң эсерлар кебек булуы, икенчедән, Русиядәге сул эсерларның өчкә бүленеп тә, соңгы вакытта тәмам аптырашта булуы. Аеруча сул эсерларның Петроград вә Мәскәүдәге Шуралар хөкүмәтенә каршы булган кузгалышлары мине тәмам ул партиядән чыгарга мәҗбүр итте. Әстерхан мөселман сул эсерлары оешмасына шуны белдерәмен: мине бу көннән үзләренең әгъзалары итеп танымасыннар. Ул сул эсер иптәшләрдән хаклык намына үтенер идем: үзләренең чын маскаларын ачып, эшче вә крестьян халкын алдамауларын.

Габдулла Галиәкбәров (Камал I).
Тартыш. – 1918. – 7 ноябрь.

ШӘҺӘРЕМЕЗДӘ

Җомга көн 29 нчы ноябрьдә пленнан кайткан иптәшләрнең гаиләләре файдасына татарча спектакль куеладыр. «Җиңел хезмәттә», драма 4 пәрдәдә, Л.Мостафа тәрҗемәсе. Антракт вакытларында оркестр уйнап торачактыр. Пленнан кайткан иптәшләрнең гаиләләре файдасына иганә кылучылар булса, шул көнне театрның үзендә мәгалмәмнүниять *(шатланып)* кабул ителер.

Театр вә санаигы нәфисә бүлеге.
Тартыш. – 1918. – 29 ноябрь.

Кереш мәкалә һәм текстларны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■



АРХЕОГРАФИК КӨНДӘЛЕК*

Миркасыйм Госманов

III сәфәр
Горький өлкәсе, Сергач районы
20 октябрь-2 ноябрь 1964 ел

Бу Миркасыйм Госманов катнашында – өченче һәм аның җитәкчелегендәге беренче экспедиция. 1964 елда оештырылган икенче гыйльми сәфәрдә КДУ аспиранты М.Госманов һәм Фәнни китапханәнең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре Альберт Фәтхи белән бергә, студентлар да катнаша. Киләчәктә студентлар экспедицияләрнең төп составын тәшкил итә башлый.

Көндәлек ике вариантта саклана: беренчесе, шактый искәрмәләр һәм өстәмәләр белән, экспедиция вакытында язылган. 1966 елда галим 1963-1966 еллардагы көндәлекләрне стилистик төзәтмәләр белән, ләкин кайбер фактик мәгълүматны төшереп калдырып, яңадан күчереп яза.

Игътибарыгызга көндәлекнең нәкъ менә шушы нөсхәсен, ягъни 1966 елда М.Госманов редакцияләгән вариантын тәкъдим итәбез. Беренче нөсхәдән күчерелми калган, әмма безнең карашка шактый әһәмиятле дип саналган мәгълүматлар астөшермәләрдә бирелде.

1963 һәм 1964 (июнь-июль) еллардагы экспедицияләр көндәлекләре белән «Безнең мирас»ның 2014 елгы 5-6 һәм 2019 елгы 9-10 саннарыннан таныша аласыз.

Диләрә Госманова

Бу сәфәрне Горький өлкәсенең Сергач районында яшәүче мишәрләргә оештырдык. Максатыбыз иске. Экспедиция отряды дүрт кешедән тора: мин, Альберт Фәтхиев[1] һәм ике студент: Камил Дәүләтшин[2], Тәүфикъ Камалиев[3].

20.10.64.

Кич белән дүртәүләп вокзалга төштек. Мәскәүгә китә торган поездларның берсенә көч-хәл белән утырып «тәгәрәп» киттек. 5-6 сәгать кенә барасы бугай...

21.10.64.

Иртәнге 6да Сергачта төшеп калдык. Караңгы, юеш. Көн башлаганчы, вокзалда утырдык. Ашханәгә кереп, тамак ялгап чыктык.

Райисполком, газета редакцияләренә кереп чыктык. Зампредның надан кеше булуы мине шаккатырды. Ләкин үзе кып-кызыл. Һәр ике сүзенең берсе: «Мы вас поняли!»

Ә газета редакциясендә тагы да сәеррәк типлар белән очраштык. Гаҗәп тар карашлы, надан кешеләр. Бөтен эшләре русча материалларны чиле-пешле итеп татарлаштырудан гыйбарәт (чөнки «Ленин байрагы» дублет булып чыга). [Алардан күргән] файдабыз берничә адрес алу булды[4].

Төштән соң Уразовка авылында идек. Ике бүлмәлек мосафирханәсе бар икән. (Элек район үзәге булган бит...)

Урта мәктәп бар икән. Килеп, директоры белән (Мансур Зәкиевич Хафизов) таныштык. Шома гына кеше, күп ярдәмнәр вәгъдә итә.

22.10.64.

Колхоз рәисе белән Беляевка бардык, озак гына әңгәмәләшеп, төрле авыллар, аларның халкы турында мәгълүматлар алдык. Авыллар бик күп (Актияровка, Краснояр, Кузьменко, Овечий овраг – Куй суы, Актуково, Ключище, Сабачай – Красная Горка, Пашат һ.б.). Кемнәргә мөрәҗәгать итү турында да киңәшләр бирде.

Төш вакытында мәктәпкә барып, укучылар алдында экспедиция турында чыгыш ясадык[5]. Камил белән Тәүфикъ, әлбәттә, үз шигырьләрен укыдылар. Мәктәп балалары артистларга караган кебек карыйлар... Тере «шагыйрьләр» күреп, исләре китте...

Төштән соң Актияровка киттек. Уразовкадан ерак түгел. Җәяүләп кенә. Мәфтуха әбигә кердек. Мулла хатыны, аңлы гына, ләкин бик куркак. Көчкә генә бер төргәк кульъязмаларын чыгарды. Менә «Җөмҗөмә дастаны»! Әһә, тулы текст! XIX гасыр башы күчермәсе... Менә тагын бер поэтик әсәр...

---

[1] **Альберт Сәет улы Фәтхиев** (1937-1992) – археограф, 1959-1992 елларда Казан дәүләт университеты китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар фондындагы Шәрык бүлеге мөдире, татар әдипләренең һәм галимнәренең кульязма мирасларын өйрәнүгә багышланган тасвирламалар (1960, 1962, 1968, 1986) авторы.

[2] **Камил Дәүләтшин** (1935-2013) – татар әдәбияты белгече, профессор, Башкортстан Республикасының мәгариф отличнигы, атказанган фән эшлеклесе. «XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый» дип исемләнгән җыентык авторы.

[3] **Тәүфикъ Камалиев** (1940-1980) – шагыйрь, мөхәррир, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Ромашкалар эзлим», «Яшьлеккә кайту», «Ак өметләр» һ.б. шигырь китаплары авторы.

[4] Бу нөсхәдә мондый абзац төшеп калган: «Шактый вакыт сөйләшеп утырдык. Өркетеп-күпертеп, дигәндәй, безнең материаллардан бер полоса оештырып бастырырга булдык. Мин кечкенә генә бер пропагандик нәмәстә язып бирдем».

[5] Беренче нөсхәдә болай язылган: «Төш вакытында мәктәпкә барып, укучылар алдында археографик экспедициянең максаты һәм аның фән өлкәсендәге әһәмияте турында бер бәләкәй лекция укып алдым. Зур клуб туп-тулы иде... Бик нәсыйхәтле итеп сөйләргә тырышып карадым. Ярдәме булыр микән?.. Очраган һәр кеше белән сөйләшеп карыйбыз...»

Ә әбиебез фамилиясен әйтергә теләми – мескен 30-40 нчы еллардан бик өркеп калган: «Балакайларым, берәр зыяны төшмәсме?» – ди. Их!..

Уразовкага кайтып киттек. Юл нибары 1,5-2 чакрым.

23.10.64.

Иртән тагы Актияровкага киттек. Нәгыйм абзый Ганиевка кердек. Яшь кенә кеше. Мулла булырга тырыша. Ярар. Безгә ике кулъязма бирде. Берсе – «Гөлестан» күчермәсе. Тагын берничә әбидән, өшкереп-төшкереп, алты-җиде әйбер алдык. Сеткабыз тулы.

Уразовкага кайткач, Сабачай (Красная Горка) авылына җыена башладык. Анда без Камил белән икәү китәчәкбез. Ә теге икесе шушында калып, башка авылларны «актарып» йөриячәк.

Сабачайда Ибәтуллин Абдулла (колхоз рәисе) һәм Хәбибуллин Габделбәр дигән кешеләрне күрергә кирәк. Колхоз машинасына утырып, Сабачайга килдек. Юлда Рыбушкино (Вербище), Мунчалы, Петряксы дигән авыллар аша уздык. Бу авыллар бик бай. Зур-зур агач йортлар. Бигрәк тә Вербище. Яшелле-кызыллы буяуларга буялган зур агач мәчет! Шоферның сүзенә караганда, аны салуга Мәскәү мишәрләре дә күп акча биргән...

Сабачай[6] да бик зур авыл икән: 700-800 йорт. Ике колхоз. Элек анда 8 мәчет, 8 мәдрәсә булган. Хөсәен Фәезханов менә шушы авылдан чыккан! Шунда үлгән[7].

Кызык: халык бик сузып, көйләп сөйләшә, нәкъ иркәләнгән назлы кызлар кебек. Җырлап сөйлиләрмени!

Фатирга Газизә әбигә[8] төштек. Тере карчык, бик сүзчән...

24.10.64.

Колхоз рәисе Абдулла абзый Ибәтуллинга килдек. Бик ачык, шул ук вакытта акыллы һәм төпле кеше. Озак-озак иҗтимагый-сәяси хәлләр турында әңгәмәләштек. Гаҗәп: Татарстанда бөтен сыерларны, сарыкларны кырып бетергәндә, бу өлкәдә колхозчылардан бер бозауны да алмаганнар. Анда барлык терлек кырылып беткән, ә монда һәр йорт саен 3-4 эре, 20-30 вак терлек! Хрущев турында гайбәт сатып алдык.

Рәиснең шоферы машина белән Хәбибуллин Габделбәргә китте. Абдулла абзый безгә авыллар турында тагы да тулырак мәгълүмат бирә (ул шәп белә, чөнки элек район башкарма [комитеты] рәисе һәм МВДның район бүлеге начальнигы булып эшләгән...). [Абдулла абзый] зур авыллардан түбәндәгеләрне саный: Кочки-Пожар (300 йорт), Шубино (350), Камка (Камкино – 250 йорт), Яндовище (400), Карга (400), Чүмбәли (400), Куй суы (Овечий овраг – 150-200), Петряксы (600), Сабачай (800), Красный Остров (400) һ.б.

Менә Габделбәр абзый Хәбибуллин да килде. Олы яшьтә булуына карамастан, бик шәп сакланган бабай. Күп йөргән, күп күргән. Озак еллар урта мәктәпләрдә, техникумнарда укыткан[9]. Тукай, Әмирхан, Кәбир Бәкер, Вафа Бәхтияров, Г.Камал, Ф.Агиев, Г.Кариевларны күргән-белгән кеше булып сөйләшә. Босяк булып, җил куып йөргән

---

[6] Беренче нөсхәдә өстәмә китерелә: «Сабачай сүзе «Сафа җай» (яхшы урын) дигән сүздән чыккан, имеш...»

[7] Бу нөсхәдә мондый абзац төшеп калган: «Казандагы Фазылҗан Хәмидуллин шушы авылныкы. Хөсәен Фәезханов кабере монда. Өстендә таш-фәләне юк, имеш...»

[8] Газизә әби – Фазылҗан Хәмидуллинның туганы.

[9] Хәбибулла хәзрәт нәселеннән 42 укытучы чыккан. Кара: Сенюткин С.Б., Идрисов У.Ю., Сенюткина О.Н., Гусева Ю.Н. История исламских общин Нижегородской области: Монография. – Нижний Новгород, 1998. 194 б.

булуы да сизелеп тора. Әлбәттә, бизәп тә җибәрә. Ләкин кайбер фактлар [чынга] бик туры килә[10].

Габделбәр абзый исеме безгә шактый еш очраган Мөхиссин хәзрәт[11] дигән укымышлы бер кешенең улы Габделхәй абзый дигән кешегә алып китте. Ул да Хәбибуллин. Аның атасыннан сакланып калган китапханә кисәгеннән 6-7 кулъязма алдык. Аларның да күбесе Урта Азиядән «килгән». Мөхиссин хәзрәтнең үз әйбере дә бар... Әллә ни кызыклы әйберләр юк сыман[12].

Төштән соң Габделбәр абзыйларның үз өйләренә кердек. Үзе карт булса да, хатыны бик яшь – 29 яшьтә (ә үзенә 70тән артык!). Хуҗа бик канәгать, ә хатынының күзе – яшьләрдә. Урлап-урлап кына карап ала...

Габделбәр абзыйның хәзинәсен актара башладык. Төрле документлар. Әһә! Хөсәен Фәезханов хаты! Галим аны Габделбәрнең этисе Хәбибуллага язган. Бохарага. Хәбибулла Фәезханның шәкерте булган! Хәбибулла, Бохарадан кайткач, ишан булып торган... Аның үз язмалары да бик әһәмиятле. Барсын да «эләктердек».

Өйгә бик соң кайттык. Арылган. Аның каравы, табышлар да шәп! Х.Фәезханов хаты гына ни тора!

25.10.64.

Безнең янга Габделбәр абзый килде. Аның белән бергә Беляев дигән укытучыга кереп утырдык (хатыны җилле генә икән – элек колхоз рәисе дә булып торган бу тәтәй!).

Габделхәй Хөсәенов дигән кешегә бардык. Авылның икенче башында. Яхшылап кунак кылгач кына, чормадан китапларны алып төште. Менә бу ярыйсы әйбер, бик борынгы «Тәгъбирнамә»[13]. Китап Тәгъбир. Тарих мең дә йөз икедә шәгъбан унынчы көн. Актуган Хафиз углы Бикмөхәммәд хафыз итдем.

1102 ел, ягъни безнеңчә 1691 елны күчергән нөсхә! Нинди генә төшләр, нинди генә сораулар юк.[14] Бик шәп табыш!

Фатирга бик соң кайттык. Газизә апага «Тәгъбир»дән укый башлаган идем: «Башыма ком төямә!» – дип көлде. Шәп тәгъбир! Теле шәп бу карчыкның..

---

[10] Беренче нөсхәдә болай язылган: «Галиәскәр Камаллар белән таныш булган. «Әл-Ислах» газетасын чыгаруда сотрудник-хәбәрче булып эшләшкән. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Кәбир Бәкер, Вафа Бәхтияров, Г.Камал, Фәхрелислам Агиев, Г.Кариев һ.б.га якын мөнәсәбәттә була. Тукайның «Гөнаһ» шигыренә рецензия язган. Ул бер заман университеттан куыла һәм бөтен дөнья буйлап сәяхәт итәр өчен чыгып китә. Владивостокка хәтле бара, төрмәгә эләгә һәм кача, кире Уралга кайта, Петербургка бара, аннары Финляндиягә чыга, шуннан чит илгә китәргә була, Варшава, аннары Кырымга, аннары Урта Азиягә, аннан Казанга, шуннан, Галиәскәр Камал ярдәмендә, Әстерханга кача, аннан ялган паспорт белән Себергә бара, революцион хәрәкәткә кушыла һ.б., һ.б. Гаҗәп күп материаллар саклана бу картта».

[11] Мөхсин хәзрәт Хәбибуллин (1871-1937) – Хәбибулла хәзрәтнең дүрт улының (Габделбәр, Мөхсин=Мөхлиссин, Нәҗип, Малик) берсе, XX гасырның башларында авылда имамлык вазыйфасын башкарган, җәдитче-мөдәррис тә булган. Хәбибулла хәзрәт – ишан, Бохарада укыган, XIX гасырның урталарында авылда мәктәп нигезләгән, Хөсәен Фәезханов белән элемтәдә торган. Тулырак мәгълүмат өчен кара: Сенюткин С.Б., Идрисов У.Ю., Сенюткина О.Н., Гусева Ю.Н. История исламских общин Нижегородской области: Монография. Нижний Новгород, 1998. 190-194, 203-205 б.

[12] Беренче нөсхәдә болай язылган: «Мөхлиссин хәзрәт Хәбибуллинның тузган көтепханәсеннән 6-7 кулъязма алдык. Кайберләре урында язылган, икенчеләре Урта Азиядән китерелгәннәр. Бик әһәмиятле әйбер булмаса да, алырга булдык. Бәлки, без билгели алмаган берәр нәрсә чыгып куяр. Әлеге авылда консерватив фикерле кешеләргә «кара колак» дип әйтәләр икән. Бу тирәләрдә бары бер Сафаҗайда гына мәдрәсә булган, калган авылларда исә мәхәллә мәктәпләре генә».

[13] Төшлек, төш юрау китабы.

[14] Беренче нөсхәдә: «Кичен «Тәгъбир» китабын карап утырдым. Нинди генә төшләр, нинди генә сораулар юк, хәтта Ходай, пәйгамбәр, фәрештәләрне күрсәң, нәрсә булачагы язылган. Ләкин Ходайның, фәрештәләрнең кыяфәтләре ничек буласы турында бернәрсә дә әйтелмәгән. Шулай ук Ходайны, гомумән, күрү мөмкинме? Теле бик госманлыча, димәк, бу китап госманлычадан «җиңеләйтелеп» күчерелгән яисә авторы бик нык госманлы тәэсирендә булган. Һәрхәлдә, 10-15 минут карап кына бер китапка нигезле бер фикер әйтеп булмас кебек шул. Тагын җиде-сигез кызыклы гына манускрипт бар...» – дип язылган.

26.10.64.

Колхоз рәисенә килеп, Уразовкага [барып] кайту турында сүз чыгардык, ягъни машина сорыйбыз. Машина төш вакытында булачак.

Абдулла абзый[15] белән хорафат турында сөйләшәбез. Ул бик күп фактлар белә. Мәктәп балалары арасында ураза тоту, дисеңме, Куй суы авылындагы «изге» хатыннар, дисеңме. (Аларга халык «хаҗ» ясый икән, корбаннар чалып...[16])

Саубуллашып, Сабачайдан киттек. Рәиснең «газиг»ында юлдан «изгеләр» каберен карадык. Тау башында өч кабер. Ташы-фәләне юк. Ул Мунчалей авылы янында. «Әүлиялар кабере» дип атала.

Уразовкага кайттык. Альберт белән Тәүфикъ та азмы-күпме кульязмалар җыеп куйганнар. Тик бик күбесе ертык-пыртык кәгазь кисәкләре. Аннары Альберт[17] үзенә шәхси көтепханә туплау өчен күбрәк тырышкан. Хәттә «Һәфтияк» кисәкләрен дә җыя барган. Имеш, студентларга дәрес үрнәкләре өчен кирәк... Бераз кызышып алдык. Нәтиҗәдә, аның утиленең бер өлеше мичкә керде. Гаҗәп бу Альберт!

27.10.64.

Төшкә хәтле ял иттек. Арылган икән. Көн дә бик әшәке иде. Болыт. Салкын. Аратирә пыскак яңгыр.

Йөк машинасына утырып, Куй суы авылына килдек. Мәктәп. Сорашабыз. Барлыгы 180 йорт. Халыкның күпчелеге Мәскәүдә тора.

Кичен берничә өйгә кереп чыккаладык. Ибраһим абзый Закиров дигән кешеләргә фатирга тукталдык (Куй суына без Камил белән икәү килдек, тегеләр калдылар). Озак кына сөйләшеп утырдык. Күпне күргән «жулик» карт. Авыл мулласы сыман икән... Теге «изге» Мөршидә турында сөйләшәбез. Бая мәктәптәгеләрнең шул «изге»дән нигә куркуларын аңлыйбыз: авыл халкы өчен Мөршидә бик зур авторитет – «аның каргавы бар!» Әмма карт үзе бер дә шүрләми сыман: иртәгә безне үз җитәкчелегендә алып барырга булды. Кызыклы гына фактлар сөйли: «Изге»дән фатиха сорап, татарлар гына түгел, чуашлар да киләләр икән. Әлбәттә, тавык-казларын алып, сарыкларын җитәкләп. Бер Урта Азия мишәре үгез корбан чалып киткән. Мөршидә бигрәк тә Мәскәү мишәрләре каршында абруйлы икән.

28.10.64.

Ибраһим абзый белән Мөршидәләргә килдек. Бездән бик шүрләделәр, бугай, авыруга сабышып, «кабул итмичә» маташтылар. Бары Ибраһим абзыйның тырышлыгы аркасында гына көч-хәл белән кердек. Озак көттереп, «ишан»нары Мөршидә «абыстай» да чыкты.

Изгелеге шөбһәле, гариплеге – хак. Надан гына бер карт кыз. Ике күзе дә кылый. Бер аягы аксак (аны Горький шәһәрендә трамвай өзгән!). Әмма өйләре җиһазлы – бай! Әйе, бөтен Сергач мишәрләре ташып торгач... Бик озак сәүдәләшә торгач, сандыкларын ачып, кульязмаларын чыгарттык. Гадәти кульязмалар – «Гөлестан», «Бостан»... Артык әйбер юк.[18]

Чәйләп тә алдык. Кыстатып кына. Ләкин атмосфера бик авыр иде.

---

[15] Ягъни Габделбәр ага.

[16] Беренче нөсхәдә болай язылган: «Куй суы»нда корбан чалып йөрүчеләр бик күп, алар, нигездә, читтә торучы сәүдәгәрләр. Яңәшә хәрам эшләре өчен нәзер әйтеп, шуны җиренә җиткерер өчен, монда килеп тәваф итәләр. Алар бик бай торганнар. Колхоз ярлы вакытларда алардан 10-15 мең сум бурычка да алып торганнар».

[17] Биредә өстәмә язылган: «...ул үзен быел Абдулла дип йөрткән».

[18] Беренче нөсхәдә: «6 китап алдык. Төрки, фарсы һәм гарәби», – дип язылган.

Алардан чыккач, Алимова Сания дигән бер әбигә кереп, бик җиңел сөйләшеп, көлә-көлә әңгәмәләшеп, 10-11 кулъязма алдык. Һәй, «Лөгате Нигъмәтулла» монда ничек эләккән?[19] Башкалары гарәпчә. Менә «Китабы Мәлкәнә» дигән әйбер, кызык!

Төштән соң Уразовкага кайттык. Нигәдер, яңа дөньяга кайткан кебек булдык.

29.10.64.

Камка (Камкино) дигән авылга киттек. Сергач аша. Поездда барачакбыз. Юлда Альбертны бер этлеге өчен «кыздырып» алдым – кызганып та куйдым; гаҗәп кире кеше...

Сергачта газета редакторы Владимир Гаврилович Страхов дигән бәндә белән бераз кан бозып алдык – ну ахмак... җитмәсә, демагог, имештер, халык арасында дин көчле, дип, без исә дөньяга кара күзлек аша карыйбыз... Кысрыклый торгач, егетең чигенергә мәҗбүр булды. Ярар, төкердек.

Камкига төнге 9да җиттек. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Шактый эзләнеп йөргәч, фатирга Хөсәен абзый Башкировларга туктадык. Карт укытучы. Пенсионер. Күп сөйли, ләкин файдага.

30.10.64.

Хөсәен абзый колхоз тарихын яза икән. Төшкә хәтле шуны укып, Газизә апа әйтмешли, «башка ком төяп» утырды. Әйбәт урыннары да бар.

Колхоз рәисенә барып, ике егетне Грабань ягына җибәрүе хакында сөйләштек (икебез Камкада калачакбыз). Алар киттеләр. Ә без ял итәбез. Тик тәмәке беткән. Хөсәен абзый белән тәмәке сабагы турыйбыз.

Ул Дүртөйле дигән авыл хакында бер легенда сөйли – мәгълүм Шүрәле әкиятенең җирле варианты... Шүрәле (абзардагы...) каргап, авыл шулай бәләкәй булып калган...[20]

Хөсәен абзый Горький өлкәсенең Муром янындагы авыллары турында кызыклы мәгълүматлар бирә (Мельтевасова, Бутакова, Княжика һ.б.).

Кострома татарлары турында шуны сөйли: аларның махсус бер бистәләре булган, үзләре гел извозщик булып эшләгәннәр. Миллилектән бигрәк, динилекне саклаганнар, телләрен югалтканнар, күбесенчә «куда мулла, туда и мы» принцибы белән эш иткәннәр.

31.10.64.

Берничә әбигә кереп чыктык.

Кулъязмалар элек бик күп булган, ләкин тетелеп, тузып беткәннәр. Бик күп әйберләрне утка якканнар, җиргә күмгәннәр. Ә без күргәннәре исә, очырмада ятып, череп таркалганнар.

Уйламаган җирдән бер шәп нәрсә эләкте: «Сәкам кыйссасы»! Шәп табыш! Бик

---

[19] Беренче нөсхәдә: «Бу китаплар аңарга каенатасы Галим бабайдан калган бугай», – дип язылган.

[20] Беренче нөсхәдә әлеге риваять киңрәк тәсвирланган: «...имештер, моннан күп заманалар элек бу авылда бер кешенең бик йөгерек аты булган. Әмма бер заманны аның аты һәр төнне чирләп чыга торган булган. Бу адәм атын кем чирләтүен тикшерергә була һәм атның сыртына сумала ягып куя. Шулай эшли дә ятып йоклый бу. Төнлә ифрат ачы тавыш ишетелә: әллә нинди чинау яңгырап китә. Әлеге кеше таяк күтәреп йөгереп чыга да абзарга керә; ни күрсен, ат өстендә кеше сыман, мәгәр өсте-башын йон каплаган бер кемсә атланып утырган була. Аның ботларында, арт санындагы йоннары ат сыртына ябышып калган икән. Бу кеше ат өстендәге куркыныч җен иясен кыйный башлый. И кыйный, и кыйный, әлеге дә баягы, чинатып-чинатып кыйный. Берара йонлы адәм сыман нәрсә ычкынып кача. Авылдан чыгып урман читенә баруга ул, әлеге кыйнаучы кешегә карап, аны: – «Авылың дүрт өйдән артмасын!» – дип кычкырып каргый. Шуннан менә бу авыл Дүртөйле дип атала. Һәм андагы йорт саны бик күп еллар артмый тора. Хәзер дә авылда 15-20дән артык йорт юк!

Бу легенда, күр әле, безнең Казан якларында да бар бит (Шүрәле!). Димәк, бу миф бик борынгы. Ә авылның ничек үсмәве исә, аның сусызрак җирдә торуында. Икенчедән, ул авыл халкы элекке вакытларда күбрәк разбой белән шөгыльләнгән... Ә күрше-тирә авыллар исә, яхшырак җирләргә җайлашканнар...

сирәк әйбер. Бөтен кич буе шуны карап утырдым. XVI гасырдан элек язылган. Идел буе. Ләкин авторы билгесез...

Бер карт шуны сөйләде: 1930 нчы елларны Камка янындагы Погореловка дигән рус авылындагы чиркәүне япкан вакытта анның идән астыннан бер сандык мөселманча китаплар, кулъязмалар чыккан. Аларның аннан соңгы язмышлары мәгълүм түгел... Нәрсә булды икән ул?..[21]

1.11.64.

Бүген нибары «Йосыф китабы»ның бер тулы гына нөсхәсен таптык. Бер бәетләр китабы да бар. Грибан авылыннан кичкә егетләр кайттылар. Нәтиҗә шәп түгел. Кичәге көнне игътибарга алмасаң, бүген безнең дә табышлар чамалы. Шулай да «Сәкам» бар!..[22]

2.11.64.

Тәртәләрне Казан ягына борабыз, ягъни бүген төштән соң китәбез. Кичен Казанда булырбыз. Хөсәен абзыйның әңгәмәсен тыңлый-тыңлый, экспедиция эшләренең «йомгагын» көндәлеккә язам:

1.Безнең Татарстанга караганда, халык баерак яши. Сәүдәгәрлек ярдәм итә, күрәсең. Экономик политика да үзгәргән сыман. Татарстандагы кебек «тәҗрибәләр» биредә булмаган... Халыкның бер өлеше спекуляция белән шөгыльләнә. Кыскасы, халык бай яши.

2. Археография материаллары, гомумән алганда, бик яхшы диярлек. Ләкин җирле иҗат түгел. Тик сакланышы бик начар... Күп кенә авылларга бара алмадык. Шуңа күрә киләчәктә бу экспедицияне тагын бер кабатлап алсак, начар булмас иде... Бәлки, киләсе елны.

3. Халыкның гомум культура дәрәҗәсе шәптән түгел[23]. Моңарчы халык арасында дини фанатизм шулхәтле көчле, дип уйламый идем. Куй суы үзе генә ни тора! Ә мәктәпләрдә укучы балаларның ураза тотулары? Тәрбия юк, тиешле пропаганда юк. Милли кадрлар, татарча әдәбият җитми. Русларның исе дә китми... Татарстаныңда шулай ук (чит өлкә бит!..)

4. Хрущевның «тәгәрәвенә» халык төкереп тә бирми. Көләләр генә.

5. Җыеп алганда, экспедиция төрле яктан да уңышлы һәм гыйбрәтле булды.

Көндәлекне басмага тарих фәннәре докторы
***Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

[21] Бу җөмләдән соң беренче нөсхәдә китерелгән абзац төшеп калган: «Мәктәп директоры Хәернисә Аблязова дигән апага кердек. Кулдан язган бер китап парчаларын алдык. Төштән соң Мангушев Җәмалга кердек. Берничә кызык кына кулъязма алдык. Аннары Каюм Кәримовка бардык, анда да берничә әйбер бар. Әле «алтын» фондка керә алмадык».

[22] Беренче нөсхәдәге абзац төшеп калган: «Төштән соң берничә йортка кереп чыктык, әмма җүнле әйбер юк. Бик күпләрендәге кешеләр «әлиф»не таяк дип тә белмиләр. Күрәсең, бу авылда наданы күбрәк. Гомумән, тел байлыгы да бик чамалы. Хөсәен абзыйның әйтүенчә: «монда сауат-белем бик сай булган...»

[23] Беренче нөсхәдә бу җөмләдән соң мондый фикер әйтелгән: «Бигрәк тә идеологик яктан. Мәсәлән, дини җәһәттән халык бик хорафый. Дин көчле. Хәттә мәктәп балалары да «бер читеннән генә» ураза тоталар. Шулай ук Куй суы (Овечий Овраг) авылында әллә нинди «изгеләр» дә пәйда булган: төрле районнардан, хәттә Мәскәү-Ташкентлардан килеп, изгеләр каберен тәваф кылучылар була икән (каз-тавыгын, акчалата сәдакасын китереп һәм туй итеп китәләр икән)... Боларның барысы да иске культураның яңара алмый калуыннан килеп чыккан милли трагедия булырга тиеш, ягъни болар арасында яңа эчтәлекле татар культурасы үсмичә, иске йолалар гына хөкем сөреп калган. Искелеккә каршы милли формалы яңа эчтәлекле идеалларның куелышы җитеп бетми. Мәсәлән, ул районда атеистик пропаганда христианлыкка каршы чыгышлар белән генә чикләнә икән, димәк, ислам бер читтә кала биргән һәм ул, эчтән бозылып, пыскып, череп, ислам эчендә мәзһәп-секта сыманрак бер нәмәстә барлыкка килгән».

Халык белән бергә

2020 елның 22 гыйнварында «Татарстан яшьләре» газетасының чыга башлавына 100 ел тулды. Быел, белгәнебезчә, республикабыз оешуга да бер гасыр. Менә шушы ике дата ниндидер символик мәгънәгә ия сыман. Ни генә булмасын, шушы бер гасыр вакыт эчендә газета халкыбыз тормышында (республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребез өчен дә) искиткеч зур роль уйнады, дип әйтә алабыз.

Газетаның чыга башлау датасына гына игътибар итик. 1920 елның башы. Илдә Гражданнар сугышы бара, тиздән Идел буена меңнәрчә корбаннар китерәчәк ачлык башланырга тора. Менә шушы чорда да хөкүмәт татар телендә яшьләр газетасы чыгара

Газетаның 75 еллык юбилеенда. Элек һәм шул чорда эшләүчеләр. 1995 ел

„КЫЗЫЛ ЯШЬЛӘР"

Орган Татобкома В. Л. К. С. М.

Газета раб. Крес. Молодеж

№ 1 (285).

1928

35 ЯШЬТӘГЕЛӘРДӘН ЕРАК ЙӨРЕГЕЗ

СПИДка каршы көрәш фәнни-методик үзәк җитәкчесе Вадим Покровский сүзләренә караганда, Русиядә вичлы кешеләрнең нибары өчтән берс генә заманча терапия белән дәвалану ала икән. Барысы да алсын өчен бу тармакны финанслауны өч тапкырга арттырырга — елына 100 миллиард сумга җиткерергә кирәк ди ул.

"Бүген илдә СПИД йоктырган 1,5 миллион чамасы кеше бар дип фаразлыйбыз, ләкин аларның шактые медицина учреждениеләренә килмәде, анализлар бирмәде әле, шунлыктан алар үзләренең чирле икәнен дә белми йөриләр. Белүчеләр дә, кешегә ишетелер дип куркып, врачларга күренмиләр. Өстәвенә, вич-инфекция шулкадәр еракка яшеренә, ул үзен 20 ел буе да күрсәтмәскә мөмкин", — ди эксперт. Вич таралу буенча безнең илдә лидерлар Урал һәм Себер икән. Бу, беренче чиратта, әлеге төбәкләрдә наркомания киң колач җәю белән бәйле. В.Покровский мәгълүматлары буенча, бер кешене дәвалау бәясе аның нинди препаратлар эчүенә бәйле. Әгәр арзанлыны икән, бу кеше РФ Сәламәтлек министрлыгына елына 12 мең сумга төшә. Югары нәтиҗә бирә һәм бүтән органнарга зыяны аз булган заманча препаратлар исә 200-300 мең сум тора. Бүген Русиядә мондый дәва өч йөзләп кешегә генә күрсәтелә диләр.

"Бүген шундый тенденция урнашты: вичлылар бигрәк тә 35-40 яшьлек ир-атларда күп ачыклана. Алар яшьләргә караганда тәртипсезрәк тормыш алып бара дигән сүз түгел бу. Эш шунда: вичны йоктыру өчен күпмедер тормыш циклын узарга кирәк: үзенә җенси партнер табарга, аны берничә тапкыр алыштырырга. Еллар узган саен инфекция йоктыру куркынычы арта бара. 35 яшькә илдәге ир-атларның 3-4 процентында бу чир була инде, ә бу гаилә корып яши, җенси тормыш алып бара торган чор. Әлеге группа ир-атлары хатын-кызларны да җәлеп итә, шул исәптән, яшь кызларны да", — ди эксперт.

Врач — авыруга:
— Әйтегез әле, сездә СПИД бармы?
Моңарчы бу сүзне ишеткәне булмаган авыру уйлый башлый: юк дисәм, врач мине саран дип уйлаячак, бар дисәм, сорый башлар инде ди.
— Бар, ләкин бик-бик аз күләмдә.

ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ

* 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА * № 23 (12421) Бәясе килешү буенча

5 декабрь 2019 ел ПӘНҖЕШӘМБЕ

Мактанырлык түгел

Татарстан хезмәт хакы күләме буенча Русия төбәкләре рейтингында нибары 39нчы урынны гына алган. Әлеге тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, безнең республика халкының 2,7 проценты аена 100 мең сумнан артык акча ала, ә 12,2 процентының айлык хезмәт хакы 15 мең сумнан да ким. Республиканың ярты халкының акчасы 20 мең сумнан 42 мең сумга кадәр тәшкил итә. Татарстанда гомуми уртача хезмәт хакы 29 мең 500 сум килеп чыккан.

Русиядә иң югары хезмәт хакын Чукоткада (49 меңнән 132 мең сумга кадәр) һәм Ямал-Ненец автоном округында (48 меңнән 133 мең сумга кадәр), шулай ук Мәскәүдә (38 меңнән 116 мең сумга кадәр) алалар икән. Иң аз акча — Дагыстанда (11 меңнән 28 мең сумга кадәр).

КЫСКАЧА

• Республиканың төп Яңа ел чыршысы бәйрәме өчен 36 миллион сум акча бүленәчәк. ТР Яшьләр эшләре министрлыгы тендер игълан итте. Тендерда җиңүче шушы акчага 8400 тамашачыга исәпләнгән спорт-тамаша корылмасы табарга, 9500 бүләк әзерләргә, концерт программасы оештырырга тиеш була. Җиңүче бүген ачыкланачак.

• "Ак барс" хоккей командасында алты сезон уйнаган капкачы Эмиль Гарипов карьерасын "Авангард" командасында дәвам итәчәк.

• Казанга "Сити-Стар" дигән өч яңа трамвай кайтты. Тәбәнәк идәнле әлеге транспортның төп өстенлеге — ул тавышсыз йөри һәм аның салоны киң.

• Казанда 15 декабрьдә "Мисс Татарстан" конкурсының сайлап алу туры үтәчәк. Оештыручылар бу турга 14-23 яшьлек кызларның килүен көтә.

• 9 декабрьдә Казан белән Уфа арасында поезд йөри башлаячак. Сүз әлеге ике башкала аша узучы башка пассажир поездларга "Уфа-Казан" дигән вагоннар тагу турында бара.

• Кичә Казанда Тинчурин театрының йөзе — РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Исламия Мәхмутова белән хушлаштылар. Каты авырудан соң 76 яшендә бакыйлыкка күчкән артистка Самосырово зиратында — ире Хәлил Мәхмүтов янәшәсендә җирләнде.

Безнекеләр турында фильм

Федор Бондарчукның "Арт Пикчерз" дигән кинокомпаниясе Татарстанда "КАМАЗ-Мастер" командасы турында сериал төшерәчәк. Бу хакта ТР спорт министры Владимир Леонов хәбәр итте. Әлеге эш 2020 елның гыйнварында башланачак икән. Сериалны ТАССР оешуга 100 ел тулу һәм "КАМАЗ"ның 50 еллык юбилее уңаеннан төшерергә булганнар. **Белешмә өчен.** "КАМАЗ-Мастер" командасы 16 мәртәбә "Ралли Дакар"да җиңде. Ул спорт йөк автомобильләре классында дөнья автоспортындагы иң көчле команда дип танылды.

Җылы декабрь

Декабрь аенда Русиянең шактый өлешендә, шул исәптән, Казанда аномаль җылы һава булачак. Бу хакта илнең Гидрометүзәге башлыгы Роман Вильфанд хәбәр итте. "Декабрьгә фаразлар бик гади. Илнең 40 процент территориясендә — Төньяк-Көнбатыш федераль округта, Идел буе федераль округында, Үзәк округның көнбатыш өлешендә, Көнбатыш Себердә температура гадәттәгедән югары булыр дип көтелә", — диде ул. Илнең баш синоптигы җылы һава көтеләчәк шәһәрләрне төгәлрәк тә атады. Болар — Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Тверь, Вологда, Псков, Самара, Пермь, Екатеринбург, Чиләбе, Омск, Томск, Новосибирск, Барнаул.

"Температура нормадан югары көтелә дип әйтүем ул әле ай буе өзлексез җылы һава торышы була дигән сүз түгел. Бу айда җылытачак та, шулай ук нык салкын көннәр дә күзәтеләчәк. Бары тик уртача температура гына югары булачак", — диде Р. Вильфанд.

АБАУ!

Үткән җомгада Саба районы, Шәмәрдән поселогында коточкыч фаҗига була — ирле-хатынлы пенсионерлар Рита һәм Илдар Шириевларның пычак белән чәнчеп үтерелгән гәүдәләре табыла. 62 яшьлек хатын һәм 66 яшьлек ир төштән соң һава сулап йөреп кайтырга дип урамга чыккан җирләреннән югалалар. Өйгә дә кайтмагач, телефоннарына да җавап бирмәгәч, балалары аларны эзләргә чыгалар һәм таң атканда поселокка терәлеп урнашкан урманда, зират янында канга баткан гәүдәләренә юлыгалар. Беркемгә дә зыяннары тимәгән гади гаилә кешеләренең канын кем һәм ни өчен койганы турында әлегә берни дә билгеле түгел. Тикшерү, җинаятьчене эзләү дәвам итә.

* * *

Менделеевск шәһәрендә берничә мәртәбә төрмәдә утырып чыккан исерек ир-ат хатынын, ике яшьлек улын һәм 19 яшьлек үги улын чәнчеп үтергән. 12 яшьлек тагын бер үги улын яралаган.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Республиканың барлык почта бүлекчәләрендә 12 декабрьгә кадәр «Абунәчеләр ункөнлеге» бара, шуңа күрә бу көннәрдә 2020 елның беренче яртыеллыгы өчен «Татарстан яшьләре»нә арзанрак бәягә — 756 сум 18 тиенгә язылып калырга ашыгыгыз. 13 декабрьдән язылу бәясе 810 сум 60 тиен булачак. Газетаның язылу индексы — П2289.

«Новая волна» — Казанда

Данлыклы "Новая волна" музыка фестивале 2020 елда Казанда үтәчәк. Композитор Игорь Крутой шулай дип белдерде. Аның сүзләренә караганда, инде өч ел элек үк — фестиваль Юрмаладан Сочига күчкәндә бу чараны Татарстан башкаласында уздыру турында тәкъдим нәр кергән булган. Казанда Игорь Крутой белән берничә уртак проект үткәргәннән соң, ниһаять, композитор киләсе елга Казанны сайлаган. Шул рәвешле, "Новая волна" ТАССРның бер гасырлык юбилей елында, август аенда Татарстан башкаласында узачак. Дөрес, кайсы бинада икәне әлегә билгеле түгел, бу хакта сөйләшүләр генә башланган. Ләкин шунысы анык — "Новая волна-2020"дә бер меңнән артык артист катнашачак.

Газетаның 1928 елда гарәп имлясында чыккан саны

башларга карар кыла. Ул, нигездә, яшьләргә багышланганлыктан, РКСМның, ягъни комсомолның Казан губерна башкарма комитеты органы буларак нәшер ителә башлый һәм «Кызыл яшьләр» дип атала. Газетаның тәүге санында ук урын алган татар яшьләренә мөрәҗәгатьтә мондый юллар бар: *«Хөрмәтле Кызыл яшьләр! Без, бүгеннән башлап, үзебезнең газетабызны чыгара башлыйбыз. Аның максатлары һәм бурычлары исемендә үк күренә. Безнең газета яшьләр өчен, димәк, ул яшьләр исеменнән сөйләячәк, алар турында кайгыртачак...»*

Чыннан да, шул елларның рухын белергә теләсәң, газета төпләмәләрен генә актарырга кирәк. Аларда без гражданнар сугышында яшь сугышчыларның батырлыгын да, колхозлашу чорын да, беренче бишьеллыкларны да, наданлыкка каршы көрәшне дә, комсомол яшьләр тормышын да бик ачык күрәбез. Утызынчы еллар уртасыннан башлап, илгә зур дәһшәт киләчәген сизгәндәй, хәрби-патриотик тәрбиягә дә зур игътибар

Коллектив белән агач утырту. 2004 ел

бирелә башлый. Бу чорда редакциядә танылган әдипләр Һади Такташ, Фатих Кәрим, Габдрахман Минский эшли. Фатих Хөсни, Гадел Кутуй, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Шәрәф Мөдәррис кебек яшь язучыларның беренче әсәрләре нәкъ менә шушы газета битләрендә дөнья күрә.

Газета тормышы ил тормышыннан аерылгысыз булган, дип юкка гына әйтмәдек. Утызынчы еллар ахырындагы сәяси репрессияләр бередә эшләүчеләргә дә кагыла. Әйтик, кайбер редакторлар нибары ике-өч ай гына эшләп калганнар, елына дүртәр-бишәр редактор алышынган.

Бөек Ватан сугышы башлангач, мәгълүм сәбәпләр аркасында, газета чыгудан туктый.

Редакция хезмәткәрләренең һәм актив авторларның күбесе сугышка китеп, фронт газеталарында эшлиләр. Һәм яшьләр газетасы 1949 елда гына, «Яшь сталинчы» исеме астында, яңадан чыгуын дәвам иттерә. Бу чорда аның битләрендә яшьләрнең һәм комсомолларның сугыштан соң халык хуҗалыгын торгызуда актив катнашулары, беренче комсомол-яшьләр бригадалары хакындагы язмаларны укый алабыз. Газета битләренә, әкренләп, нефтьчеләр тормышы, соңрак КамАЗ, Түбән Кама нефть химиясе комбинаты төзелешләре килеп керә, яшьләрнең һәм язучы-шагыйрьләрнең иҗаты киң яктыртыла.

1956 елдан бирле, басма «Татарстан яшьләре» исеме белән чыга. Нәкъ менә шушы исем белән нәшер ителә башлагач, газетаның тиражы да нык артты, ул, яшьләрнең генә түгел, урта буынның да, өлкәннәрнең дә яраткан газетасына әйләнде. Моның сәбәпләре байтак. Кайберләрен генә санап китик.

Әйтик, газетабыз, чыга башлавының беренче елларыннан ук, әдәбият-сәнгатькә зур игътибар биргән, язучыларны актив пропагандалаган. Нәкъ менә 60-80 нче елларда газета редакциясе каршында әдәби берләшмә эшләп килгән һәм анда бүгенге күп кенә халык язучылары да чыныгу алган.

Газетаның 85 еллык юбилеенда. 2005 ел

«Газета, коллектив агитатор һәм пропагандист кына түгел, ә коллектив оештыручы да», – дигән гыйбарә бар. «Татарстан яшьләре»нең тиражы 80-90 нчы елларда 200 мең данәгә җитүдә нәкъ менә ул оештырган «Каз өмәләре», «Озын толым», җыр конкурсларының да тәэсире зур булгандыр. Бүген инде андый чаралар оештыру шактый авырлашты, әмма берсен – милли көрәш буенча «Татарстан яшьләре» призларына 16-18 яшьлек үсмерләр арасында республика турниры» үткәрүне аерым әйтеп китәргә кирәктер. 1973 елдан бирле узучы әлеге бәйге бик күп яшьләргә зур спортка юл ачты, байтак егетләргә соңрак тормышта да югары үрләр яуларга булышты.

Заманалар ничек кенә авыр булмасын, газета редакциясе бүген дә җиңүчеләргә үз бүләкләрен, футболка, календарь тапшыра, алар хакында газета битләрендә язып чыга. Чыннан да, көрәшчеләр арасында да, тамашачылар арасында да бу турнирның абруе зур.

Әгәр язмамда газетаның баш мөхәррирләре хакында әйтмәсәм, гөнаһ булыр иде. Чыннан да, барысы да илгә-көнгә билгеле шәхесләр. Алданрак билгеләп үткәнемчә, дәһшәтле 30 нчы еллар ахырында аларның кайберләре редактор булып 2-3 ай гына эшләп калган, әмма без андыйларны да онытырга тиеш түгел. Әйтик, 1959 елда, газета редакторы булып, аннары танылган дәүләт эшлеклесе – ТАССР Министрлар Советы рәисе урынбасары, соңрак ТР Фәннәр академиясе президенты вазыйфасын башкарган Мансур Хәсән улы Хәсәнов эшләп алган. Бездә нибары 8 ай эшләп, аннан соң фән юлына кереп киткән, зур постлар биләгән, әмма газета тормышында барыбер якты эз калдырган. Кырыктан артык редактор арасында Ибраһим Гази, Гали Хуҗи, Ислам Беляев, Барлас Камалов кебек әдипләр дә бар. Янәдән иң зур тираж җыйган сиксәненче елларга кайтсак, ул чорда биредә Харрас Әюп, Рәфыйкъ Юныс, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Вәлиев, Госман Гомәр, Рашат Низами, Газинур Морат кебек язучы-шагыйрьләр хезмәт куйган.

Шулай да тагын бер мөхәрриребезне – Исмәгыйль Сәлман улы Шәрәфиевне аерып әйтәсе килә. Искиткеч кешелекле, талантлы, зур оештыру сәләтенә ия шәхес иде ул (урыны җәннәттә булсын!). Аның редакциядә азмы-күпме эшләгән һәр хезмәткәрне

Редакция коллективы. 2010 ел

фатирлы итү өчен күпме тырышканын үзе генә белгәндер. Бүген матбугат чаралары да, редакторлар да бик күп, әмма андыен табып булмастыр, мөгаен.

Газета-журналлар күп, дигәннән, бүгенге мөхәррирләрнең байтагы – нәкъ менә «Татарстан яшьләре»ндә канат ныгытып киткән кешеләр. Болай дигәндә мин «Ватаным Татарстан»ны 16 ел җитәкләгән Миңназыйм Сәфәровны, басманың бүгенге җитәкчесе Гөлнара Сабированы, «Ирек мәйданы» гәҗитенең баш мөхәррире Раиф Усмановны, ГТРК «Татарстан» җитәкчесе Фирдүс Гыймалтдиновны, «Сиражи сүзе»н оештыручы Искәндәр Сиражины, бүгенге көндә берүзе 2-3 исемдәге гәҗит чыгаручы Лилия Сөнгатуллинаны һәм башкаларны күздә тотам. Чөнки «Татарстан яшьләре» гомер-гомергә яшь журналистлар өчен өйрәнү мәктәбе булды һәм хәзер дә шулай булып кала бирә.

Газетаның рубрикаларына гына игътибар итсәк тә, тематиканың бик киң икәнлеген күрербез. «Җиде көн», «Юмор-сатира», «Хәтер-хатирә», «Яшәеш», «Көн кадагы», «Атнакич кунагы», «Сердәш», «Тормыш дулкыннары», «Бакчачы почмагы» – һәр рубрика үзе хакында үзе сөйли. Тагын шунысы да бар: газетаның даими язышып торучы авторлары бар. Күп кенә басмалар, бигрәк тә район газеталары авторларның күзгә күренеп кимүе хакында зарланганда, бездә, киресенчә, аларның саны даими арта бара. Иң кызыгы шунда: араларында элеккеге журналистлар һәм укытучылар гына түгел, ә төрле һөнәр ияләре, хәтта академиклар, Россия Дәүләт Думасы депутатлары булуы да куандыра. Әгәр бүген кемдер – тарихчымы ул, язучымы, студентмы – республика, ил тарихын ныклап өйрәнергә теләсә, «Татарстан яшьләре» төпләмәләренә генә мөрәҗәгать итсен. Алардан, кызыклы һәм гыйбрәтле язмалар аша, безгә тарих үзе бага.

Атлас Гафиятов,
«Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире,
Татарстанның атказанган матбугат хезмәткәре ■

ҺӘР КИТАПХАНӘГӘ – «БЕЗНЕҢ МИРАС»!

Узган елның 24 декабрендә «Безнең мирас» журналханәсе редколлегия утырышы уздырды. Утырышта катнашучылар, туган телебез, милләтебез өчен тирәнтен борчылган хәлдә, бүген көн үзәгендә торган бик җитди мәсьәләләр хакында, аерым алганда, татар матбугаты һәм татар китабының бүгенге хәле, киләчәге турында сөйләште.

Ләбиб ЛЕРОН,
«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире:

– Ел ахырында без, гадәттә, эшләгән эшләргә йомгак ясыйбыз, нәтиҗәләр чыгарабыз, уңышларыбызны барлап сөенәбез, чишелеп бетмәгән мәсьәләләрнең сәбәпләрен ачыкларга тырышабыз, киләчәккә планнар корабыз. Сүз дә юк, көенечләребез-борчуларыбыз белән бергә, телгә алып сөйләрдәй хезмәтләребез дә, кылган эшгамәлләребез дә, шатлык-куанычларыбыз да бар. Әмма ил-көндәге бүгенге вазгыять, ягъни милләтебезнең хәле бер дә мактанырлык түгел. Карагруһчылар туган телебезгә каршы максатчан көрәш алып бара, милләтебез баш калкытмасын өчен, төрле яман ысуллар куллана.

Үзләренең Россия Конституциясенә каршы килгән эшләрен тормышка ашыруда алар, бигрәк тә, матбугат, интернет, радио һәм телевидениедән оста файдалана. Без дә, үз чиратыбызда, шушы ук чаралар ярдәмендә, аларга кискен җавапларыбызны бирергә, алай гына да түгел, болай ул, дип, хакыйкатьне, чынбарлыкны халыкка җиткерергә тиешбез. Безнең дә матбугатыбыз бар. Әмма ул тулы куәтенә эшлиме соң? Без чыгарган газета-журналлар һәм китаплар халкыбызның төрле катлам вәкилләренә барып җитәме? Алар халыкка барып ирешсен өчен, тагын нәрсәләр эшләргә кирәк? Без бүген шул хакта сөйләшергә җыелдык.

Шамил САДЫЙКОВ,
«ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры:

– Шагыйрь һәм укытучы гаиләсендә туганга, балачагым китап-журнал арасында узды. Кечкенәдән милли, мәдәни мирасны аңлап-тоеп үстем. Татар мәктәбендә белем алып, КДУның татар журналистикасы бүлеген тәмамладым. Мәрхүм Флорид абый Әгъзамов безнең остазыбыз иде. Озак еллар татар мохитендә, татар журналистикасында эшләдем. Татарлык даирәсе тарая барса да, без өметне һич кенә дә өзәргә тиеш түгел! Басма сүзнең «тере» укучылары булу – безнең өчен олы ышаныч. Төп бурыч – укучылар белән якыннан аралашып, аларның мәнфәгать-ихтыяҗларын тоя белү. Аларга ни кирәк? Нинди тәкъдимнәр бар? Шуларны ачыклыйсы иде.

Икенчедән – тәрбия мәсьәләсе. Укучы теләге белән генә дә яшәп булмый. Аны тәрбияләү, зәвыгын формалаштыру, иҗтимагый-тарихи белемен арттыру да – безнең зур миссиябез. Әмма изге бурычыбыз – милли-мәдәни мирасны таныту, аны халыкка җиткерү. Китап нәшрияты белән дә тыгыз элемтә булырга тиеш, дип саныйм. Совет чорында китапларда басылып, хәзер онытылып барган затлы мирасыбыз да «Безнең мирас» сәхифәләрендә яңа буын укучыларын тапсын иде. Нәкый Исәнбәт белән бәйле вазгыять, көтмәгәндә, совет чоры, олуг әдип һәм замандашларының мирасы белән зур кызыксыну тудырды. Укучыларыбызны уятып җибәрде...

«Безнең мирас» журналы – милли-мәдәни мирасыбызны пропагандалауда республикабызның төп инструменты. Журнал укучылар өчен кызыклы булырга тиеш! Зифа Кадыйрованы күпләр тәнкыйтьли, әмма аның укучылары күп. Ни өчен күп? Нигә аның белән кызыксыналар? Нигә аны халык яратып укый? Бу хакта да уйларга кирәк!

Китапханәләргә килүчеләр журнал белән кызыксынамы? Анда йөрүчеләрнең фикерләре ничек? Гомумән, укучылар белән тыгыз элемтә бармы? Журналны халык күп укысын өчен, без нәрсәне эшләп бетермибез? Шуны ачыкласак иде.

Ләбиб Лерон:

– Сөргеннән кайткан Хәсән Туфанга: «Сез югында татар әдәбиятын уртакул әсәрләр басты, Сезнең кебек, Галимҗан Ибраһимов кебек олы әдипләр булмады», – дип зарланганнар. Мондый сүз әйтүчеләргә шагыйрь: «Без югында телебезне менә шул уртакул әсәрләр саклап калды да инде!» – дип җавап биргән. Дөрестән дә, 1950-1960 нчы елларда телебезне хәзер инде исемнәре онытылган язучылар саклап калган. Бүгенге эстраданы сүгәргә яратабыз, әмма алар да телебезне саклау һәм пропагандалауга өлеш кертә. Шулай да безгә саннан сыйфатка күчәргә вакыт. Халыкны затлы әдәбият укырга өйрәтергә кирәк.

«Безнең мирас» журналы да китап укучы белән халык арасында арадашчы булырга тиеш! Җиде томлы татар тарихын гади укучылар аңлап бетермәскә дә мөмкин. Шуңа күрә, журналда тарихыбызны һәр укучы да аңларлык фәнни-популяр телдә яктыртырга тырышабыз. Чөнки безнең максат – җиңел һәм халыкчан тел белән тарихыбызны, гаҗәеп бай мирасыбызны пропагандалау, укучыларыбызны катлаулы тарихи һәм фәнни язмалар укырга әзерләү.

Очрашулар вакытында китапханәчеләребезнең күбесе: «Китапханәдә бүгенге әдипләребезнең китаплары юк!» – диләр. Безнең китапларыбыз, журналларыбыз мәктәп һәм авыл китапханәләренә барып ирешми.

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстанның халык шагыйре:

– Мәгариф министрлыгы белән бу мәсьәләдә уртак тел таба алганыбыз юк. Нигәдер алар, Президентка безнең белән барып, бу мәсьәләне хәл итүне кирәк дип тапмады. Югыйсә, 1500 китапханә – Мәдәният министрлыгыныкы, шул ук чамадагы мәктәп китапханәсе Мәгариф министрлыгы карамагында. Әгәр дә республикабызның һәр китапханәсенә 1 генә данә журнал барып ирешсә дә, кимендә 3000 данә журнал булыр иде. Китапханәдә булган басманы дистәләгән кеше укый ала. Бу эшне урындагы җитәкчеләр һәм китапханәчеләр белән бергәләп эшләргә кирәк.

Зиннур МАНСУРОВ,
Татарстанның халык шагыйре:

– Республикабызның Мәдәният һәм Мәгариф министрлыкларына Татарстан бюджетының иң зур өлеше бүлеп бирелә. Теләк булса, һәр китапханәгә берәр журнал яздырырга мөмкин. Совет чорында һәр китапханәгә җөмһүриятебездә чыга торган барлык газета-журналлар килә иде. Бу чорда безнең республика баерак идеме? Монда, минемчә, министрлар белән «ТАТМЕДИА» җитәкчеләренең, сөйләшеп, уртак тел табуы кирәк.

Илдар СӘГЪДӘТШИН,
Татарстан китап нәшриятының генераль директоры:

– Мәсьәләнең социаль ягын да уйларга кирәк. Әгәр дә без берәр китапны яки басманы, китапханәләргә, дип, 3 мең данә бастырабыз икән, гади халыкка бәяне киметүне типография чыгымнары белән генә дә капларга була. Бөтен чыгымнарны шушы 3 мең тираж эченә кертеп бетерергә мөмкин. Халыкка кәгазь һәм почта бәясе генә калырга тиеш.

Бездә болай да чыккан, күп хезмәт куелып басылган китап һәм журналларның тиражын арттыру әллә ни проблема түгел һәм бу зур сумма да сорамаячак.

Ләбиб Лерон: «Безгә саннан сыйфатка күчәргә вакыт».

Ләбиб Лерон:

– Бәлки безгә, әгәр бу эш яхшы куелган икән, Башкортстаннан һәм башка төрки республикалардан, шулай ук Казакъстан кебек илләрдән дә үрнәк алырга кирәктер!

Гәрәй РӘХИМ,
Татарстанның халык язучысы:

– Татар газета-журналларының республикабызда таралуына тагын бер киртә бар. Ул да булса – газета-журналларның укучыга вакытында барып җитмәве. Татарстан авылларындагы күп язылучылар көндәлек матбугатны үз өйләренә атна-ун көн соңлап алалар. Моны без республика почта бүлекләренең кыскартылуына сылтыйбыз. Ә нигә без почта бүлекләренең кыскартылмавы, киресенчә, көндәлек матбугатның искермичә көнендә үк килеп җитәргә тиешлеге турында республика күләмендә чаң какмыйбыз? Әлбәттә, әгәр кичә яңа булган хәбәрләр өеңә бер атнадан соң гына барып ирешсә, нигә ул газетага язылып торырга? Аның бит исеме дә – «көндәлек матбугат»! Авыл кешеләре язылган газета-журналларның үз вакытында килүен тәэмин итү Элемтә министрлыгының турыдан-туры вазыйфасы икәнен без республика җитәкчеләре колагына чаң кагып әйтергә тиеш!

Аннан соң матбугатта басылып чыккан әсәрләрнең әдәби-сәнгати сыйфаты турында да уйланырга кирәк. Чын иҗтимагый әһәмияткә ия булган әсәрләр һәм урыслар «желтая пресса» дип бәяләгән язмалар бар. Мәсәлән, мин Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәрен «желтая пресса»га кертер идем. Әйе, аны күп кеше укый, дип, без бу әсәрне күп тиражлар белән бастырабыз, кино төшерәбез. «Ә ни өчен күп кеше укый?» – дигән сорауга җавап бирмибез. Күп укылуга Россиядә милли мөнәсәбәтләрнең катлаулана баруы да тәэсир итә, әмма барыбызга да билгеле, «желтая пресса»ны гади укучы бик күпләп укый. Ләкин без, әдәбиятчылар һәм наширләр, гади укучының бүгенге зәвыгы,

бүгенге дәрәҗәсенә ияреп, аны кабатлап баручылар түгел. Әдәбият-сәнгатьнең беренче максаты – укучы зәвыгын югары дәрәҗәгә күтәрергә тырышу. Бүгенге профессиональ язучы һәм нашир, укучы зәвыгын мөмкин кадәр югарырак дәрәҗәгә күтәрергә тырышып, әсәрләрен дөньяга чыгарырга тиеш, ә «желтая пресса»га ияреп барырга, аның мәнфәгатьләрен генә кабатларга тиеш түгел!

Кызганыч, бу мәсьәләдә әле без азрак уйлыйбыз.

Фәйзелхак ИСЛАЕВ,
профессор:

– Хәзерге буын яшьләре мәгълүматны күбрәк интернеттан алырга күнеккән. Әмма социаль челтәрләрдә таралган информация күп очракта дәлилләнмәгән яки бик өстән генә язылган була. Шуңа күрә, тарихи материаллар, интернетта таралганчы, төпле, дәлилләнгән һәм яшьләргә аңлаешлы телдә журнал сәхифәләрендә басылып чыксын һәм укучыларга таралсын иде.

Данил САЛИХОВ,
ТР Язучылар берлеге рәисе:

– Хәзерге көндә Татарстан Язучылар берлегендә 300дән артык каләм әһеле бар. Үзен язучы, шагыйрь дип санаган һәр кеше әүвәлгеләр язганнарга, остазларының иҗатына битараф булмаска һәм мәшһүрләребез мирасын даими яктыртып килгән «Безнең мирас» журналын, һичшиксез, укырга тиеш.

Газинур МОРАТ,
шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе:

– Интернет, смартфон, телевизор заманында туып үсмәгәнлектән, балачакта безнең төп ике шөгыль бар иде: ул да булса – күмәкләп төрле уеннар уйнау һәм ялгыз калып китап уку. Шул ук вакытта балалар матбугаты, аларда даими басылып торган әдәби әсәрләр дә безнең якын сердәшебез, киңәшчебез, тәрбиячебез булды. Ни гаҗәп, соңгы елларда балалар өчен нәшер ителә торган басмалардан әдәби әсәрләр бөтенләй юкка чыкты. Чаллыда чыга торган «Көмеш кыңгырау» гәзите генә нәфис әдәбиятка хәерхаһ булып калды. Ә инде үз ана телендә әдәбият укып үсмәгән баланың төзек итеп сөйләшә, яза белүенә дә, образлы фикер йөртә алуына да исәп тотып булмый торгандыр.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
КФУ профессоры:

– Мин, элекке «Мирас» һәм аның эшчәнлеген яңа өслүбтә дәвам иткән «Безнең мирас» журналына чирек гасырдан артык катнашкан авторларның берсе буларак, шуны әйтә алам: ул хәзерге шартларда да үзенә төшкән бурыч-вазыйфаларны

уңышлы башкарып килә. Материалларның төрлелеге, мәгънәви эчтәлеге, иллюстрацияләренең байлыгы белән укучыларын сөендереп тора. Мәсәлән, Габдерәшит Ибраһимовның «Ислам дөньясы» дигән әсәре, бер яктан, милләтебезнең тарихын, халыкара бәйләнешләрен яктырта, икенче яктан, әдипнең дөнья күләмендә танылган олуг шәхес икәнен дә күрсәтә. Гомумән алганда, мин журналның юнәлешенә, басылган саннарына уңай бәя бирәм. Моның өчен аның хезмәткәрләренә, авторларына ихлас рәхмәтемне юллыйм. Алга таба да шундый нәтиҗәле эшчәнлек дәвам итсен иде!

Разил Вәлиев:

– Иң беренче чиратта, журнал укучыны җәлеп итәргә, сыйфатлы булырга тиеш. «Безнең мирас» һич кенә дә тел-теш тидерерлек басма түгел, әмма кайбер материаллар кыска кебек. Укый гына башлыйм – бетә дә китә... Редакция әлегәчә безнең колак ишетмәгән бик күп авторларыбызны, аларның иҗатын дөньяга чыгарды һәм чыгарып килә.

2020 елда илкүләм халык санын алачакбыз. Бу – гаять мөһим мәсьәлә. Шуңа күрә, халык санын алуга бәйле язмалар да «Безнең мирас» журналында яктыртылсын иде. Башкортстан татарлары тарихына бәйле язмаларны күбрәк биреп, журналны әлеге республикада да күпләп таратырга кирәк.

«Безнең мирас»та затлы хезмәтләр басылып килә. Ел азагында, шулардан иң-иңнәрен генә җыеп, китап итеп бастырып булмыймы?!

Зиннур Мансуров:

– Россия күләмендә үткәрелә торган җанисәп җәһәтеннән шуны күрсенеп искәртәсе килә: татар халкы үзенең төгәл санын бүгенге көнгә кадәр ачык белми. Без үзебезнең исәпне ахирәттә, ягъни Хөкем мәйданында гына тәгаенләргә тиеш түгел ләбаса! Чын хакыйкать озак еллар дәвамында яшереп тотыла. Бу уңайдан журналның һәр санында аңлату-төшендерү кимәлендәге мәкаләләр бирелеп барырга тиеш.

Илдар Сәгъдәтшин: «Мәсьәләнең социаль ягын да уйларга кирәк».

Гәрәй Рәхим: «Әдәбият-сәнгатьнең беренче максаты – укучы зәвыгын югары дәрәҗәгә күтәрергә тырышу».

Югыйсә, бердәнбер милләтне янәдән әллә ничә төркемгә бүлеп бетерү куркынычы яный. Инде хәзер үзен 2-3 милләт вәкиле итеп санаучылар да ишәя башлады. Кызганыч, ирексездән «сорт»ларга бүлгәләнү зыялыларыбыз арасында да күзәтелә. Безнең халыкны шул рәвешле таркату артык кыен түгел. Үзәктәге кемсәләр шушы форсаттан бик оста файдаланалар. Бездән уяулык сорала! Халык санын алучылар тәкъдим иткән анкетада үзебезне бердәнбер сүз белән «татар» дип яздыру фарыз. Ә бит өйдән-өйгә йөрүче хезмәткәрләр безне куркытмый да, төрлечә үгетләми дә, башыбызга пистолет та терәми. Бөтенесе дә үзебездән тора.

Ләбиб Лерон:

– Китап итеп бастыру, дигәннән, Йосыф Баласагунның «Котадгу белек» әсәре инде басмага әзер. Ул безнең журналыбызда берничә ел дәвамында дөнья күреп килде. Хәзер аны китап итеп бастырып чыгару актуаль. Дәүләт җитәкчеләре чит илләргә барганда яки күренекле кешеләр белән очрашканда бүләк итеп бирелә торган затлы басма булсын иде ул. Чыннан да, китап әзерләү эше дә без тоткан юнәлешләрнең берсе булырга тиеш.

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА,
галимә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

– «Сезнең мәктәбегезгә татар телендә газета-журналлар һәм китаплар ничәнче елдан килүдән туктады?» – дип, мин үземә таныш булган мәктәп директорларыннан бүген үк сораячакмын.

Белгәнебезчә, почта хезмәткәрләре кыскартылды. Кайбер авылларда хатларны, газета-журналларны кибеткә генә китерәләр. Авыл халкы үзенең гәҗитләрен хәзер шуннан эзләргә мәҗбүр. Тираж белән бергә, матбугатны тарату мәсьәләсе дә бик актуаль бүген.

2020 ел – Халык иҗаты елы. «Идегәй» дастаны 1940 елда басмага әзерләнеп, 1941 елда үзгәреп чыга – аннан Алтын Урда өлеше төшереп калдырыла. Бу әсәрнең тулы варианты, галимнәрнең кереш сүзе белән, «Безнең мирас»та басылып чыксын иде.

«Мәгариф» журналы баш мөхәррире С.Таишева (сулда), галим Ф.Ислаев һәм ТР Язучылар берлеге рәисе Д.Салихов

Нәкый ага Исәнбәтнең юбилеен да һәм сугыш алды елындагы мәдәни вазгыятьне дә онытырга ярамый.

1926 елда Антон Эйхенвальд, халык әсәрләреннән партитуралар әзерләп, ике атна дәвамында Париж, Лион шәһәрләрендә, шәрык музыкасы, дип, татар концертлары бирә. Бу шәһәрләрдә дөнья күргән француз газеталарында татар музыкасы турындагы мәкаләләр бар. Французлар татар концертларына йөргән! ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан журналда шундыйрак материаллар да басылсын иде. Хәзерге вакытта Александр Сладковский оркестры, Опера һәм балет театры Татарстаннан Европага рус һәм халыкара музыка белән чыкса, 1920 нче елларда Антон Эйхенвальд Парижда татар көен яңгыраткан! Ни өчен ул вакыттагы француз татар музыкасын мөкиббән китеп тыңлый да, хәзерге заманда татар моңы чит илдә яңгырамый?!

Зиннур Мансуров:

– Газета һәм журналлар таратуның начар куелуы, тулаем караганда, Россия почтасының көндәлек эшчәнлегенә турыдан-туры бәйле. Белгәнебезчә, әлеге тармакка дәүләт тарафыннан тиешенчә дотация бирелми. Почта хезмәткәрләренең кыскартылуы да, почтальоннарга түбән хезмәт хакы бирелү дә, нигездә, шуның белән аңлатыла. Әмма безгә кул кушырып утырырга ярамый. Көндәлек матбугат басмаларының авылларга начар таратылуын республика газеталарындагы журналистлар да урынга барып тикшерергә бурычлы. ТНВ каналында хезмәт куючы коллегаларыбыз да матбугат сүзенең халыкка барып җитмәвен аерым сюжетларда күрсәтергә тиеш. Менә шулай бергәләп тотынган очракта әлеге вазгыятьне беркадәр яхшыртырга мөмкин, дип саныйм.

Ләбиб Лерон:

– Әйе, матбугатны, татар басма сүзен, милли сәнгатебезне халыкка тарату өлкәсендә зур эшләр башкарасы бар. Моңа һәрберебез үз өлешен кертсә иде.

Редакциядән: «Безнең мирас» журналы редакциясе матбугат, тел һәм милләт язмышы турында мөрәҗәгать кабул итте. Аны журналның киләсе саныннан укырсыз. ■

ТАССР *Татарстан китап нәшриятына – 100 ел!*

Өстәлемдәге китап – чынбарлык!

Бу китапның һәр җөмләсе үзе бер мәгънә. Китапны кулыма алгач, әбекәй-бабакайның безгә биргән тәрбиясе, әти-әнинең үгет-нәсыйхәте, якын кешеләремнең киңәше искә төшә. «Таш белән атканга аш белән ат!», «Сабыр бул!», «Гаепсезләрне, гаделлекне яклаячакмын!» – болар минем тормыш девизым! Шушы девизымның бөтен нечкәлекләрен, аңа ирешү юлларын бары тик «Илбашы» дигән әдәби-документаль әсәрдән генә таба алам.

Бу китап искерә торган түгел, ул – чынбарлык! Аның төп герое – Актанышыбызның горурлыгы булган, беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Китапта кечкенә Минтимернең балачагыннан хәзерге тормышына кадәрге вакыйгалар хикәяләү рәвешендә бирелә. Аның һәр хикәясе бер кеше тормышына тиң! Рабит Батулланың «Илбашы» китабы бездән соң килгән буыннарны тәрбияли торган менә дигән дәреслек булачагына ихластан ышанам. Бу әсәр һәрвакыт минем өстәлемдә. Мин аны бик кәефсез чакларымда да, җитмеш төрле уй белән баш катырып йөргәндә дә яисә уңышка ирешеп очына-очына йөргән вакытларымда да, тормышымда җиде юл чатында калганда да кулыма алам һәм искиткеч мәгънәле тормыш серләренә кереп чумам. Китапханәче буларак, төрле чаралар уздырганда да еш мөрәҗәгать итәм мин аңа. «Йола» хикәясендәге «Гаилә йоласы нык булса, тышкы мохит, урам, яман төркем берни дә эшли алмый» җөмләсен гаиләмдә бервакытта да истән чыгармыйм. Улым белән сөйләшкәндә дә, аралашкан дус-ишләремә дә бу сүзләрне еш кабатлыйм.

Аллага шөкер, безнең буынның балачагы тыныч тормышта узды. Рәхәтләнеп уйнап, экологик яктан чиста ризыклар ашап үстек. Әсәрнең герое татыган сугыш михнәтләре, ачлы-туклы замана, рәхимсез балачак язмышы – тетрәндергеч. Әсәрдәге «Гармун», «Кәҗә сөте», «Аш белән ат», «Мәргән», «Тургай», «Абага чәчәге» хикәяләрен тыныч күңел белән укып булмый. Әнә бит, ачлык хисен басар өчен, ай буе кәҗә сөтен савып эчәргә йөргәннәр. Бу эшне аналары белеп алып: «Әнә, атагызның камчысы! – дип кисәтә. «Үскәч, Минтимер аңлар: анасы, балалары каршысында иренең абруен күтәрер өчен шулай куркыткан, аталарыннан шүрләп торсыннар, янәсе». Менә бит нинди тәрбия! Безнең буыннар өчен тәрбия бирүнең, гаиләдә әти кешенең ролен күтәрүнең сокландыргыч юлы.

Белгечлегем буенча мин – укытучы. Бәлки, шуңадыр да, бу һөнәр ияләренең хезмәтенә сокланам, алар алдында баш иям. «Илбашы»ндагы «Хәдичә апа» бүлегендә укытучыга дан җырлана, әлеге һөнәрнең үлчәнми торган хезмәт икәнлеге ассызыклана. Китапны кулыма алган саен, искиткеч тирән мәгънәгә ия булган «Минтимер Шәрип углы Шәймиев гомере буе беренче укытучысы Хәдичә апа Әхмәдуллина турында уйланыр, аңа сокланыр, аңа чиксез рәхмәтләр укыр» җөмләсен кабат-кабат укыйм. Бары үзе мәгънәле тормыш юлы узган, кешелекнең матур сыйфатларына ия булган шәхесләр генә укытучы хезмәтен хөрмәт итәләр, аның нәрсәгәдер тиңләп булмый торган һөнәр икәнен аңлыйлар.

Мин үзем гаделлекне яратам. Хәрәмләшкән, әләкләшкән, ялагайланганнардан ераграк йөрергә тырышам. Рәнҗетелгәннәрне, яклаучысы булмаганнарны якларга, аларга психологик яктан булса да терәк булырга, ярдәм итәргә омтылам. Тормышта гаделлек

кайчан да булса җиңәчәген белеп эш итәм. Шуңа күрә «Ике капчык тары», «Мин гадел хөкемдар булчакмын!» хикәяләре күңелемә бигрәк тә якын. Әсәрнең герое хокук сакчысы булу хыялы белән яши. «Бу теләк атасы белән булган, чак кына фаҗигагә китермәгән вакыйгадан соң тагын да көчәйде», – диелә автор тарафыннан. Әтисе Шаһишәрип абзый аңа: «Син Кәтиев булырсың!» – дип, дөрес юнәлеш бирә. «Аның кулында – халыкның өмете... Икмәк булса, бар да була», – ди ул. Автор җирен, үз халкын яраткан кеше генә әхлаклы, әдәпле була алганын укучыга җиткерергә тели. Туган илеңнең патриоты булырга чакыра ул безне. Әлеге сүзләр илаһи көчкә ия! Әдәп, әхлак төшенчәләре юкка чыга барган безнең заманда өлге итеп куярдай менә дигән әсәр бу! Китапханәмдәге әдәп-әхлак дәресләрендә, аралашу сәгатьләрендә, «Өмет» хәрби-патриотик кызыксыну клубында да мин әлеге хикәяләрне мисал итеп китерәм.



Беренче мәхәббәт, ярату, яратылу төшенчәләре һәркемгә якын. Бу – мәңгелек тема. Яшьлегендә беренче мәхәббәт утында янмаган кеше бармы икән?! Мөгаен, юктыр. Адәм баласы, яше җиткәч, гаилә корырдай парын эзли. Гомерлек ярны дөрес итеп сайлыйсың икән, димәк, син – бәхетле! «Бөек бәхет бит ул – эзләгәнеңне табу!» – диелә әсәрдә. Бүгенге көндә тиз генә язылышып, шулай ук тиз аерылышкан парларга ул мондый киңәш бирә кебек: гаилә корганда әти-әни киңәшеннән чыкмаска, ә бергә тора башлагач, ир хакын хакларга, аңа терәк булырга кирәк. Хикәядә яшьләргә, яшь гаиләләргә өлге итеп алырдай мондый тирән мәгънәле фикерләр бихисап. «Юк, Минтимер мөкәммәл хатын эзләми иде, чөнки андый хатыннар булмый, алар дөньяда юк, ул хыялыйлар яки шагыйрьләр уйлап чыгарган бер гүзәл шәкел генә... Минтимер җир кызын эзли иде», «Сәкинәнең сизгер күңеле сизә, егет аны бик тә ярата, ләкин эчке сиземләве кисәтә дә: ашыкма, кызый, кайдарланма, бу әле синең парың түгел». Әлеге җөмләләр яшь егет һәм кызның акыл белән эш итә торган, тәрбияле, иманлы гаиләдән чыккан яшьләр икәнлеген күрсәтә. Яшьләргә ашыкмаска-кабаланмаска, уйлап эш итәргә кирәклегенә басым ясый. Ул вакытларда «кызлар басынкы, тыйнак, гүзәл» булганнар. Эх, кайтарырга иде хәзерге заман яшь-җилкенчәкләргә ул вакытлардагы тыйнаклыкны! «Улым, әллә кая каранма!.. үзебезгә килен таптым...», «Анаңнан алда сүз йөртмә, апаем...» – бу сүзләр яшь буынны олы кешене хөрмәт итәргә, әти-әни сүзенә колак салырга чакыра. «Күрдең дә шуңа өйләндем яисә кияүгә чыктым түгел», «Күз карашыннан аңлашып яшәү», «Бер-береңне хөрмәт итү», «Ярашып яшәү ул – олы мәхәббәт», – диелә хикәядә.

«Илбашы»нда – матурлык! Монда – КЕШЕ күңеленең матурлыгы, сафлыгы, ихласлыгы! Иле, халкы өчен җан атып, зур дан-дәрәҗәгә ирешеп тә, кече булып кала белгән милли җанлы Олы шәхескә мәдхия булып кабул ителә әлеге китап!..

Фәндия Гайнанова,
Актаныш районының Актаныш авылы ■

«ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП»

24 декабрь көнне «Хәтергә уелган китап» бәйгесенә йомгак ясалды.

1 нче урын – шагыйрь **Газинур Морат**ка,

2 нче урын – шагыйрь **Гәрәй Рәхим** һәм язучы **Хәбир Ибраһим**га,

3 нче урын – **Нәкыя Гыйләҗева**га (Казан), **Халидә Габидуллина**га (Арча) һәм **Фәндия Гайнанова**га (Актаныш) бирелде.

Кызыксындыру бүләкләренә **Хәләф Хәлилов, Таһир Шәмсуаров, Гөлнара Гатауллина, Миләүшә Шәйхулова, Сиринә Галиева һәм Фирая Мингалиева** ия булды.

Шагыйрь Г.Морат

Л.Лерон Ф.Мингалиеваны (Мамадыш) котлый

Р.Фәйзуллин Х.Ибраһимовны котлый

Д.Салихов Н.Гыйләҗевага бүләк тапшыра

Х.Габидуллина (Арча)

Тулырак мәгълүмат – beznenmiras.ru һәм tatar-inform.tatar сайтларында.

Р.Фәйзуллин Г.Рәхимгә диплом тапшыра

Солтан Исхаков (tatar-inform) һәм Ленар Гобәйдуллин фотолары

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Мийато сүзен дәвам итте:

– Безнең японнарда, элек-электән, сугыш вакытында ике якның да бердәнбер максаты – дошманын тар-мар итү булган. Сугыш вакытында сугышчының уе шуннан башкада булмаган, күзенә дә башка нәрсә күренмәгән. Безнең элекке гореф-гадәтләребез буенча, үзебезнең якта яки дошман ягында сугышкан бер кешенең үлгәнен күрсәк, беренче вазыйфабыз – аның кем икәнен, ягъни исемен, яшәгән җирен белергә тырышу, аннан соң янында акча һәм башка төрле әманәтләре булса, аларны саклап, якыннарына тапшыру була иде. Бу юлы да ул гадәтләребезне үзебезнең үлеләребезгә карата нәкъ элеккечә кимчелексез җиренә җиткердек, тик, ни кызганыч, русларга карата моны башкара алмадык, күп кенә рус кешесенең әманәтен үз дәүләтебезнең казнасына тапшырырга мәҗбүр булдык. Адреслары табылып, әманәтләре Русия Хәрбия Нәзарәтенә тапшырылганнар бик сирәк булды.

Тик русларда бу гадәт бөтенләй юк, хәтта һәлак булган сугышчыларының янында булган бөтен нәрсәләрен иптәшләре ала икән. Моннан тыш, бөтен офицерлар һәм азык-төлек өчен җаваплы кешеләр гел дәүләт казнасына ябырылалар, аны туздыралар. Миндә бу фикер Йало янындагы сугыш вакытында туган

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

иде. Ә инде соңрак, Мукден сугышында, моның чынлап та шулай икәненә үз күзләрем белән күреп ышандым.

Мукденда безнең бөтен теләгебез Куропаткинны яки Линевичны[1] кулга төшерү иде. Мукден янындагы югалтуларыбызның барысы да, минем уйлавымча, шул сәбәпле булды. Югыйсә, Мукденда зур югалтуларның һич кирәге юк иде. Ахрысы, безнекеләр дә анда артык ачкүзлелек күрсәттеләр. Ләкин руслар да йоклап калмады, Мукденны мөмкин кадәр тизрәк калдырып чыгып киттеләр.

Билгеле бит инде! Җиңелүгә дучар ителгән гаскәр бер җирне ташлап киткәндә, күп вакытта анда шактый мал-мөлкәт тә кала, чөнки кешеләр арасында шактый байлар очрый. Менә шулвакыт, тар-мар ителгән гаскәр чигенергә дә өлгерми, җиңгән тараф килергә өлгергәнче, ул җирләрне хунхузлар[2] талап китә. Бу хәл бөтен җирдә дә кабатлана килде, безнекеләр моны булдырмый калырга теләсәләр дә, уңышка ирешә алмадылар. Мукденда да нәкъ шулай булды. Без килгәндә, хунхузлар алданрак килеп өлгергәннәр, йортларны, кибетләрне басканнар, бөтен җирне талаганнар иде инде.

Мукденны алганда, мин, вазыйфам кушуы буенча, гаскәрнең беренче бүлекләре белән үк шәһәргә кергән идем. Без килүгә, әлбәттә, хунхузлар да качып киткән иде инде. Шунда ук бөтен җиргә каравыл урыннары билгеләп, сакчылар куеп, шәһәрне сак астына алдык. Кибетләрнең күбесе ачык, малы таланган, шактый кеше үтерелгән, кая карама, мәет ята иде. Барыннан да элек, сәүдә үзәкләренә каравылчылар куйдык, гаскәрнең урнашу тәртибен тикшереп чыкканнан соң, базар җиренә киттек. Анда бөтен кибетләрнең ишекләре кайсы ачык, кайсы ватык, рәт буенча тикшерә-тикшерә барабыз. Бер кибет янына килеп туктадык. Карыйбыз: кибетнең ишеге бикле генә түгел, мөһер сугып ябыштырылган. Ишек төбендә бер рус гаскәрие – иңбашына асылган мылтыгы да бар – сакчы кебек басып тора.

Безнекеләрнең «бирел!» әмерен ишетүгә, рус гаскәрие мылтыгын җиргә ташлады, гаскәри киемен салып атты, гади киемнән безнең офицерларның каршысына килеп тә басты. Беренчедән, үзенең рус түгел, ә грузин икәнлеген, икенчедән, гаскәри түгел, ә сәүдәгәр икәнлеген әйтте һәм болай дип өстәде: «Бу кибет – минем малым. Рус гаскәрләре качып киткәннән соң, хунхузлар килеп таларга керешкәндә, мин тиз генә кибетне бикләдем, мөһерләдем, хунхуз талавыннан саклар өчен, качып барганда ташлап калдырылган шинель табып өстемә кидем, ташлап калдырылган мылтык та күп иде, берсен алып иңбашыма астым, үземә солдат кыяфәте биреп: «Бу кибеттә булган бар нәрсә – дәүләт малы, японнарга тапшырыр өчен, мине җаваплы итеп калдырдылар», – дидем. Шул рәвешле, малымны саклап кала алдым. «Инде хәзер сез хәл кылыгыз: менә – мин, менә – малым», – дип, бик кайгылы тавыш белән сүзен тәмамлады, күзләрен сөртте, кибет ачкычы белән мөһерен безнең офицерларга тапшырды.

Кибетне ачканчы, без бу кешедән эчтә булган малларның исемлеген, нинди үзенчәлекле нәрсәләр барлыгы белдерелгән аңлатма язуы яздырып алдык. Язуга имзасын куйдырдык, аннары кибетне ачтык. Кибетнең бу кешенеке булуы расланды.

---

[1] Алексей Николаевич Куропаткин (1848-1925) – рус хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал, рус-япон сугышында башкомандующий булган. Николай Петрович Линевич (1839-1908) – рус хәрби эшлеклесе, генерал, рус-япон сугышы герое (тәрҗ. иск.).

[2] Әсәрдә бераз алдарак та очраган бу атаманы без хонхоз рәвешендә язып, аңлатма бирергә тырышкан идек. Ләкин алга табарак шул аңлашылды: XIX гасыр ахыры-XX гасыр башларында Маньчжуриядә, Кытайның төньягында, Кореядә һәм Уссури өлкәсендә кулланылган бу атама хунхуз дип укылырга тиеш. Ул вакытларда әлеге исем белән төрмәдән качкан яки сөргенгә сөрелгән кытай кешеләреннән оешкан юлбасар төркемнәрен атаганнар. Чыганакларда бу сүзнең «кызыл сакаллылар» дигән мәгънәсе булуы да белдерелә (тәрҗ. иск.).



Ул арада безнең гаскәрләр Мукден шәһәрен тулысынча алдылар.

Безнең баш командир килде, грузин кешесенә: «Теләсәң, кибетеңне ач, сәүдә итә башла. Ләкин, менә бу – күрсәтмә, болары – бәяләр. Малыңны 20 процент табыш алырлык итеп сатачаксың. Юк, дисәң, хәзер үк машиналар килер, малыңны төярсең. Иртән бездән кире алырсың, рус гаскәренә барып кушылырсың», – диде.

Моны тыңлап торган безнең грузин «кунагыбыз» баш командир билгеләгән процентка риза булмады һәм: «Мин рус гаскәренә 100не 300гә исәбе белән сата идем. Мөмкин булса, рөхсәт итегез дә Куаньзенцы дигән җиргә китим», – диде.

Безнең командир шунда ук машиналар китертте, грузинның малларын төятте. Аңа, рус гаскәренә барып кушылыр өчен, Мукденнан чыгып китәргә рөхсәт бирелде. Безнең гаскәриләр чик буена кадәр озата киттеләр.

Менә шул вакыйга вакытында, мин ул грузин кешесенә 100не 300гә исәбе белән ничек сата алуы турында сорау бирдем. Ул шул рәвешле җавап бирде: «Без бары тик ашамлыкларны – икмәк, йомырка, май һәм башка шундыйларны – 100не 300гә сатсак – гаскәр командирының рөхсәте белән бу кадәр арзан сатабыз. Эчемлек-шәраб һәм кәеф бирә торган башка нәрсәләргә килсәк, бер шешә шампан шәрабын 200 сумга саткан чакларыбыз да була, офицерлар бик теләп алалар һәм эчәләр иде. Мәсәлән, 10 тиенлек тәмәкене 1 сумга сатканда, безнең шуңа канәгать булуыбызга хәйран калалар иде».

Күргән-белгәнен шул рәвешле сөйләп биргәч, карт өстәп тагын шуны да әйтте:

– Бу ишеткән сүзләребезгә ышануы кыен иде, шакката идек. Алга таба мондый хәлләрне күп күрдек, күп ишеттек. Рус гаскәрендә мондый канунсыз эшләр, кешелек кагыйдәләре белән исәпләшмәүләр бик еш була икән.

«Менә, минем кебек карт авыл кешесеннән сугыш турында кыска гына бер хикәя, шуның белән кыйммәтле вакытыгызны алдым, кичерә күрегез», – кебегрәк сүзләр белән, кече күңеллелек күрсәтеп, карт миннән гафу үтенде. Дөресен әйтим, Мийато бабайның бу җанлы хикәясе миңа бик нык тәэсир итте, аннан ишеткәннәремне кыскача гына булса да теркәп куйдым.

АВЫЛЛАРДА ЙӨРИМ

Алып барган сүзебезгә кире кайтыйк. Японнарда тормышның, нигездә, гаять гади һәм бизәксез-чуксыз булуы турында әйткән идем инде. Ә авылларда ул, әлбәттә, тагын да гадирәк һәм бизәксезрәк. Бигрәк тә ризыклары – әйтеп кеше ышанмаслык гади, безнең сүз белән әйткәндә, ыбыр-чыбырдан гыйбарәт. Иң беренче итеп телгә алынырга тиешле ризыклары, ризык итеп ашала ала торганнары: майсыз, тозсыз, итсез, яшелчәсез пешерелгән дөге; диңгез тереклек ияләренең һәр очраган төре, әгәр булса, балыкның иң гади төре, берсеннән-берсе үзгә агач тамырлары. Боларның көн дә бер яки ике тапкыр ашалуын да истән чыгармаска кирәк. Иртән, бар нәрсәдән дә элек, ягъни иртәнге аш урынына – газета.

Иң ярлы йортта да һәр иртә иң беренче булып кулга алына торган нәрсә – газета. Таң беленүгә, урамнардан газетачыларның автомобильләре үтә башлый.

Кайчак шундый авыллар очрый: авыл да димәссең, ике-өч, иң күбе – биш йорт. Болар шактый. Андый авыллар күбесенчә олы юлдан читтә, шактый еракта була, газета ташучы машиналар анда кереп тормый. Ләкин аларга дигән газеталарны бу авылларга бара торган юл читенә куеп китәләр.

Газета өләшүчеләр үтеп китүгә, өйләрдән йөгереп диярлек газета алырга чыгалар. Кайбер көннәрне газетачылар ярты сәгатькә соңга калсалар, инде һәр йорттан бер кеше чыгып, урамда газета көтеп тора. Юлдан күзләрен алмыйча көтәләр.

Ирме, хатынмы – авылларда беркем дә эшсез утырмый. Көн буе, тәгаен, ни белән булса да шөгыльләнәләр. Хатыннарның вазыйфалары – күбесенчә арулыкка хезмәт итү, бөтен шөгыльләре шуннан гыйбарәт. Дөресен генә әйткәндә, бу авыл кешеләренең тормышлары уенчык белән уйнауга охшаш, бигрәк тә әлеге дә баягы шул ризыкларын чыбык-таяклар белән ашауларын игътибарга алсак, чынлап та уенчык инде.

Авылларда хәтта хайваннар да юк, башка илләрдә-җирләрдә хайваннар ярдәме белән башкарыла торган бөтен эшне кешеләр үзләре эшли. Бик авыр, тиргә, кергә батыра торган эшләр эшлиләр, шуңа күрә мунчага булган ихтыяҗлары бик зур.

АВЫЛЛАРДА МУНЧА

Мунча керү – авыл кешеләренең иң яраткан шөгыльләре. Мунчалары исә кайнар судан гыйбарәт. Һәр авылда берничә мунча, моннан тыш, өйләрдә дә юыну бүлмәләре бар. Тик бу мунча дигән җирләре дә бик гади, ирләр белән хатыннар бер үк мунчада юыналар, араларында чаршау гына эленеп тора. Японнарда «гаурәт» һәм «сәтр-и гаурәт»[3] төшенчәсе юк дәрәҗәсендә, дисәм дә, ялган булмас.

АВЫЛЛАРДА ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ СӘҮДӘ

Япон авылларында җитештерү бик алга киткән. Һәр авылда кечерәк кенә җитештерү урыннары, фабрикалар бар. Бигрәк тә таштеки (фарфор, кафель) җитештерү бик киң таралган, авыл саен бар, дисәм дә, дөреслеккә туры килер. Авылларның күбесендә эш электр көче белән башкарыла, электр уты кергән авыллар аз түгел. Кыш көннәрендә авыл кешесе, күбесенчә, балта остасы эшен башкара.

Яр буйларына якын авылларда исә балык тоту, аның маен әзерләү, балык тозлау, киптерү, уылдык әзерләү белән шөгыльләнәләр. Балык ыслап, җәйгә ризык туплыйлар. Аврупага, Америкага җибәрелә торган балык ризыкларын эшкәртү дә авыл кешеләренең җитештерү өлкәсенә карый.

Мин боларны авылларда бик аптырап карап йөри идем. Әйләнеп йөри-йөри идем дә, кабат шәһәргә, ягъни Токиога кайтып китә идем.

Токиода да тик утырмыйм: кайчак газеталарга мәкаләләр язам, кайчак

[3] Гаурәт – Ислам дине өйрәтүе буенча, гәүдәнең чит күздән яшерелеп, каплап йөртелергә тиешле өлеше, дигән сүз. Сәтр-и гаурәт исә – гәүдәнең бу өлешләрен каплап йөрүне аңлата.

Мунча. XX гасыр башы.

җәмәгать урыннарына барам. Бер тапкыр Конт Маҗора җәнаплары белән күрешергә бардым. Бу шәхес һәм аның тоткан урыны турында сезгә сөйләп аңлатыр алдыннан, иң башта, Япониядәге контларның кемнәр икәнлеген әйтеп үтәсем килә.

ЯПОНИЯДӘ КОНТЛАР

Моннан 45 ел элек, Япониядә дәүләт идарәсе 300ләп алпавытның кулы астында булган. Һәрберсенең идарә чикләре мәгълүм, ә үз өлкәләре эчендә болар тулысынча мөстәкыйль булганнар. Берсе икенчесенә каршы хәтта сугыш игълан итә, берсе икенчесе белән бәйләнешне бөтенләй өзә алган. Берсе җиңгән, икенчесе җиңелгән, ләкин, гомумән алып караганда, «бердәм команда» ысулында эш алып барылган. Киото шәһәрен уртак башкалалары итеп санаганнар, уртак һәм иң югары мәрҗи, ягъни инстанция – Микадолар гаиләсенә «тиански сама» – «изге, мөкатдәс», дип мөрәҗәгать итә торган булганнар. Бу гаилә чит илләр белән мөнәсәбәтләрдә Япониянең императоры булып танылган, эш аңлашылмаучылыклары килеп чыкканда, хөкем карары чыгару, солых имзалау эшләрендә хөкемдар сыйфатына ия булган. Моннан 45-50 ел элек алпавытлыкларның иң зуры булып, идарә үзәге Токиода урнашкан һәм башында Токо Гавакики торган алпавытлык саналган. Бу Токо Гавакики моннан 44 ел элек Моҗохито Микадоның атасы [бүгенге императорның атасы булган элекке император] вафат булганда 15 яшьлек Микадоның императорлыгын танырга теләми һәм араларында сугыш чыга. Шактый озакка сузылган бу сугышта Токо Гавакики өстен чыга һәм Микадоның императорлыгын таный, раслый, ләкин түбәндәге ике шарт белән:

1) Киото шәһәрендә яшәгән император гаиләсе Токио шәһәренә күченәчәк һәм шул көн Моҗохито Микадо императорлыгы төзелгән һәм бу тарихның башланган көне булып саналачак;

2) Бөтен алпавытлыклар бетерелеп, уртак мәмләкәт булып берләшәчәкләр һәм, нәтиҗәдә, императорлык төзеләчәк, ә ул вакытка кадәр алпавытлыклар белән идарә иткән шәхесләргә «контлык» бүләк ителәчәк.

Менә шул рәвешле, бүгенге көндә Япониядә никадәр конт булса, болар барысы да әлеге вакыйгадан соң «контлык» алган шәхесләр. Минем дустым Маҗора җәнаплары да – боларның берсе һәм бүгенге Япониядә булган контларның иң дәрәҗәлесе.

Алда Маҗора җәнаплары белән беренче тапкыр күрешүем һәм Япониядәге затлы нәселләр белән бәйле күргән-белгәннәремне язачакмын.

Иң беренче, Маҗораның моннан 500 ел элек төзелгән йорты һәм бакчасы турында сөйләп китәсем килә.

Бакчаның уртасында бик зур күлчек (бассейн) бар һәм ул борынгы бианлар белән әйләндереп алынган. Конт Маҗора белән күрешергә килгәндә, Конт җәнапларының улы мине ишектә каршы алды, кунак каршылау бүлмәсендә

Мукден шәһәрендәге урам

миңа урын күрсәтте. Бераздан, японнар үзләре һәрвакыт бик яратып эчә торган чәй әзерләп китерделәр. Тәрҗемәчем Накаяма ярдәме белән, үземнең кем икәнемне таныттып, Конт җәнаплары белән күрешергә теләвем турында улына белдердем. (Конт җәнапларының улы университет тәмамлаган, гаять тәрбияле яшь егет икән.)

Берничә минут утырып торганнан соң, Контның улы хәбәр бирергә китте. Кире килгәч, Контның: «Бер ярты сәгать көтсеннәр, бик мәшгульмен, ял бүлмәсенә рәхим итсеннәр», – дигән җавабын тапшырды. Улы килеп, нәзакәтле итеп гафу үтенеп, безгә бу сүзләрне тапшырды да ял бүлмәсенә чакырды, без аңа ияреп киттек.

Биш минут та үтмәгәндер, бүлмәгә бер ханым керде, безгә сәҗдә кылган кебек иелеп сәлам биргәннән соң, шунда торган мангалны һәм кечерәк савытларны караштыра башлады. Мин бик игътибар белән күзәтәм: бу гаять итагатьле, гаять гүзәл ханым бер яшь кыз булып чыкты, безгә чәй әзерләргә килгән. Кыз шунда ук гаҗәеп бер ысул белән чәй әзерләргә тотынды. Шул минуттан тирә-юньгә искиткеч хуш ис тарала башлады. Минем бу рәвешле чәй әзерләүне моңарчы һич күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Ун минут үттеме-юкмы, чәй әзер булды. Кыз бик нәзакәтле итеп тезләре өстендә хәрәкәтләнеп безгә таба килде һәм чәй тәкъдим итте. (Хатын-кызлар ирләр каршысында аягөсте тормыйлар икән.) Чәй салынган кечкенә савытны кулыма алдым, бөтен тирә-юнь хуш ис белән тулды, гаҗәпләнүемнең чиге-чамасы юк иде.

– Никадәр генә гаеп булса да, сорамый кала алмыйм, гафу итәрсез. – Әлеге кечкенә савытны күрсәтеп: – Бу нәрсә? Моны безгә тәкъдим иткән кыз кем? – дидем.

– Бу чәйне тәкъдим итүче, сезгә хезмәт күрсәтүдән горурлык тоючы кыз – Конт Маҗораның кызы. Чәй исә бары тик сарай кешеләренә генә әзерләнә торган чәй. Аны әзерләү тәртибен, ысулын сарайда махсус тәрбияләнгән кызлардан башка берәү дә белми. Конт Маҗораның гаиләсендәге кешеләр сарай әгъзалары булып санала, – диделәр.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

2020 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1441-1442 ҺИЖРИ ЕЛЛАР

25 февраль – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең, Гайсә (г.с.) пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хаҗы кылына.

25 февраль – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

20-21 март – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете (көрсие) янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

7 апрель – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышларын билгели.

24 апрель – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе.

21 май – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

24, 25, 26 май – Гайдел-фитыр, Ураза бәйрәме.

30 июль – Гарәфә көне.

Мөбарәк вә фазыйләтле 10 кичәнең ахыргы кичәсе.

Гарәфә кыяме яки хаҗиларның Гарәфә тавы тирә-юнендә торып гамәл-гыйбадәт башкару көне. Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ.

31 июль – Мөбарәк Гыйд әл-Әзъхә яки Корбан гаете.

Җөмлә әһле Исламга мөбарәк, Гает корбанлыклары кабул булсын! Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ. 30, 31 июль, 1, 2, 3 август – Тәшрикъ көннәре.

20 август – Һиҗри Яңа ел. 1442 Һиҗри елның вә Мөхәррәм әл-Хәрам аеның беренче көне.

Яңа елыбызда дөнья вә ахыйрәт бәхет-сәгадәтенә алып бара, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кылырга насыйп булсын! Бу көнне Аллаһының ризалыгы өчен догалар, изге эш-гамәлләр кылып, хәер-садака биреп үткәрергә кирәк.

28 август – мөбарәк Гашура кичәсе.

29 август – мөбарәк Гашура кичәсе көне. Мөхәррәм әл-Хәрам аеның 10 нчы көнендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Бу көннең фазыйләтләре һәм хикмәтләре бихисап. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: «Ибраһим галәйһис-сәлам Гашура көнендә тугандыр. Аллаһы Тәгалә аны Нәмрудның утыннан Гашура көнне коткаргандыр, юлның тугрысын да Гашура көнендә күрсәткәндер».

14 октябрь – һиҗри тәкъвим буенча елның икенче ае яки Сәфәр әл-Хәер ае башлана. Изге вә бәрәкәтле ай булуын Аллаһы Тәгалә насыйп итсен!

27 октябрь – Мәүлед-шәриф кичәсе.

28 октябрь – Мәүлед бәйрәме – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган көн. Ул мөселман дөньясында зурлап билгеләп үтелә.

Төзүче-мөхәррир –
хаҗи ***Абдулла Дубин***

Фәтхи Бурнаш (1898-1942)

ХӨСӘЕН МИРЗА

Борынгы татар тормышыннан трагедия

Фәтхи Бурнаш

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урман эче. Киселгән агачлар. Уртада начар гына шалаш корылган. Шалаш алдында учак, өчаяк белән чиләк асылган.

Пәрдә күтәрелгәндә Муса арлы-бирле йөри. Бикморза уң кулда түмгәк өстенә утырган. Икесе дә мылтык, кылыч белән коралланганнар. Шалаш эчендә төрле киемнәр, кораллар тузып ята.

Муса, Бикморза

Муса. Рәхмәт, Бикморза ага! Мин сине бик көттем. Әгәр дә берәр бәхетсезлеккә очрап, бүген дә урман авызыннан күренмәсәң, мин үзем артыңнан эзләп китәчәк идем.

Бикморза. Син Бикморзаны аз беләсең әле, энем. Миңа һәр почмакта – түрем, һәрбер намуслы крестьян – дустым, шуңа күрә мин бик ипле йөреп килдем.

Муса. Сине берәү дә сизмәдеме?

Бикморза. Алардан – берәү дә. Югыйсә, Хөсәен мирза йорт саен үзенең шымчыларын куйган. Чак кына бернәрсә сизелде исә, казаклар өйләрне җир белән тигезлиләр, балаларга кадәр тоткар итәләр.

Муса. Шулай булгач, син тиешле кешеләрнең барын да күрә алмагансыңдыр.

Бикморза. Мин, Шәйдулладан кала, аларның барын да күрдем.

Муса. Бик һәйбәт, бик һәйбәт, җә...

Бикморза. Халыкны бик каты кыссалар да, күңелләре төшенке түгел әле. Иргали казакларга ярдәмгә егетләрдән бер генә таяк та җыйный алмаган.

Муса. Ул бәндә һаман җилкенәме әле?

Бикморза. Бу эшләрдә Хөсәен бер мирза булса, Иргали биш мирзаның урынын тота. Мирзаның күзе җитмәгән, акылы ирешмәгән, кулы тимәгән кабахәтлекләрнең барысы да аның кулы белән эшләнә.

Муса. Болар аның үз башына җитәчәк...

Бикморза. Тизме, озакмы, моның җитәчәген ул үзе дә бик яхшы сизә. Шуңа күрә, безнең эзгә төшәр өчен, ул мирзадан битәр тырыша.

Муса. Үлем исереклегендә тырнашалармы?..

Бикморза. Ләкин Иргалинең эшләре болай да бозылырга тора шикелле. Халык телендә Хөсәен мирзаның югалган баласы исән булуы турында хәбәрләр йөри.

Муса. Шулаймы? Моның өстенә тагын бер аждаһа туарга тора, дисең алайса.

Бикморза. Шулай итеп, Иргалинең мирза нигезенә хуҗа булу нияте куркыныч астында кала.

Муса. Ярый. Бер этне икенчесе белән алмаштыру эшне үзгәртмәс. Без аларның чын варислары белән дә, ялган варислары белән дә хисаплаша белербез әле. Тик халык безнең белән булсын.

Бикморза. Халыкның безгә ышанычы ныгыганнан-ныгый бара. Хөсәен мирза ике

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

йөз казак арттырса, без шул арада гына һәрберсе ун казакка торган йөзләп егет арттырдык. Минем белән килгән ун егеттән соң авылда картлар белән балалар гына калды.

Муса. Борисовка эшләре турында тагын берәр нәрсә белмәдеңме?

Бикморза. Чистяков бояр утарын ташлап качкан. Хатыны белән улын крестьяннар, таш бәйләп, суга ташлаганнар. Исправникны ат койрыгына тагып урам буе йөрткәннәр, үләксәсен чиркәү башына асып куйганнар.

Муса. Эх! Шундый хәбәрләр ешрак килсен иде дә, безнең көч йөз меңнәрчә көчләр җыйнасын иде. Без аннан соң губернаторларның үзләрен дә суга бәйләп ташлар идек.

Бикморза. Аларның авылын да хәзер казаклар чолгап алган.

Муса. Безгә бүгеннән үк шул якларга иң ышанычлы егетләрнең берничәсен җибәрергә кирәк. Әгәр алар да безгә кушылсалар, без шундый эшләр эшләрбез, безнең эшләр алдында якты көннең дә йөзләре чагылыр.

Бикморза. Дөрес, Муса. Аларның кояшлары байый, ә безнең таңыбыз ата...

Муса. Син ял ит, Бикморза ага, аргансың. Ә мин егетләр янына барыйм. Хәзер өзелгән чакта аларның күңелләренә җан өсти торырга кирәк.

Бикморза. Подгорный урыслары киләсе якшәмбегә кадәр утыз йөк әйбер китерерләр. Без аның белән шактый хәл алырбыз.

Муса. Син әле миңа Гөлниса апаның хәлен сөйләмәдең...

Бикморза. Тәрәзәдән мине күргә, карчыкның хушы китә язды *(көлеп)*, ул әйтә, синең йөзеңә карагач, әкияттәге тылсымлы картлар исемә төште, ди.

Муса. Ярый... вакыты килер – без әле яшь кияүләр кебек спайланып та кайта белербез. *(Шакир йөгереп керә.)*

Шакир, Муса, Бикморза

Шакир. Муса абзый, Бикморза ага!

Муса. Нәрсә булды?

Шакир. Зинһар, сез безне коткарыгыз!

Бикморза. Син ни турында сөйлисең?

Шакир. Мин көч-хәл белән сезнең яныгызга йөгереп җиттем.

Муса. Сөйлә, нинди эш бар анда!

Шакир. Җаннарым! Без харап булабыз.

Бикморза. Тукта, син безгә рәтләп кенә сөйлә!

Шакир. Мин төн буе йокламыйча газапланып чыктым.

Муса. Тизрәк әйт! Югыйсә, безнең арттан җиттеләрме?

Шакир. Юк. Ләкин алар тиздән җитәрләр...

Муса. Ах, нәрсә мыгырдадың инде?

Шакир. Муса абзый! Алар Әхмәтне җибәрделәр.

Муса. Кемнәр, кая җибәрделәр?

Шакир. Кәримнәр, Җаббарлар... һәммәсе дә... Каршы булучыларны үлем белән куркытып көчләделәр. Әхмәтне Хөсәен мирзага җибәрделәр...

Муса. А!.. Хөсәен мирзага?..

Шакир. Әйе. Кичә җыйнадылар барыбызны да... Үз ихтыярлары белән бирелергә булдылар.

Муса. Син чынлап әйтәсеңме?

Шакир. Чынлап шул, шайтан алгыры...

Муса. Кичә, дисеңме?

Шакир. Кичә... Юк, бу турыда алар күптән пышын-пышын сөйләшеп йөрделәр, ахрысы... Ә кичә җибәрделәр...

Муса. Бикморза ага! Хәзер чиктән тыш авырлыклар каршына басарга туры килә. Хәзер безнең өчен йә җан, йә иман. Мин барысына да әзер, Бикморза ага!

Бикморза. Юк! Иң элек менә ак сакаллы бабаларының күкрәгеннән үтсеннәр дә, аннан соң сиңа кулларын салсыннар... Ир бул бу юлы да, балам!

Шакир. Әнә, алар монда киләләр. Ах, без харап булабыз, харап булабыз...

Бикморза. Син алай борчылма, бала. Бар, кит, без үзебез карарбыз. *(Халык шаулашып керә, кайсы мылтык, кайсы сәнәк, балта тоткан. Шакир читкәрәк борыла да халык арасына ук керә.)*

Халык, Муса, Бикморза

Муса. Әйдәгез, картлар, егетләр! Бикморза аганың сау йөреп кайтуын котларга килерсез, дип, мин сезне күптән көткән идем.

Җаббар. Юк, без аның өчен килмәдек...

Муса. Алайса, йомышларыгызны йомышлагыз да, безгә юл куегыз. Иртәгәдән башлап безнең алда тагы да зуррак эшләр тора.

Җаббар. Без сезгә юл куярбыз. Ләкин аңа кадәр, җәмәгатьнең әйтә торган сүзләре бар.

Муса. Сөйләгез – мин тыңлыйм. *(Төпчек өстенә утыра.)*

Җаббар. Озын сүзгә урын юк. Сез мондагы җәмәгатьнең, авылдагы картлар, балачагаларның ничек киченүләрен яхшы беләсез.

Муса. Әйе, мин аннан башка да кайбер нәрсәләрне беләм. Алай да сөйләгез – мин һәр сөйләгәнне тыңларга, һәр тыңлаганны уйларга яратам.

Җаббар. Менә, җәмәгать, сөйләшегез үзләре белән.

Халык. Нәрсә сөйләргә!

– Монда сөйләп торырга да урын юк.

– Сөйләштек инде, җитәр!

– Сөйләшми генә бәрергә кирәк үзләрен!

Бикморза. Шауламагыз! Нәрсә базар ясадыгыз! Сез, булмаса, туп-туры әйтегез: кемнәр алар табылды сезнең арагыздан эт алдына ташланган сөяккә сатылучылар?..

Җаббар. Кем-кемне саткандыр, кем-кемне алдагандыр, анысын менә сезгә җәмәгать әйтер. Алар монда ачлыктан үлек төсенә керделәр. Урманда тора-тора аларның аюбүредән аермасы калмады. Айлар буена туярлык аш, рәтле йокы, юеш пычрактан гайре баш куяр урын күргәнебез бармы?

Халык. Әйтегез, бармы?

Бикморза. Ә... сез яхшы чакта гына дуслар, иптәшләр дә, азрак авырлык килсә, дусларыгызны гына түгел, җаныгызны да сатарга әзер торасызмыни?

1 нче кеше. Сез безне куркыта алмассыз!

2 нче кеше. Безне тагы да алдый алмассыз.

3 нче кеше. Җәмәгать, шауламагыз!

4 нче кеше. Юк, син безне тыя алмассың!

2 нче кеше. Күп тыйдыгыз инде, җитәр!

5 нче кеше. Кайтарыгыз безне моннан!

Бикморза. Туктагыз!

2 нче кеше. Кайтарыгыз безне балаларыбыз янына.

3 нче кеше. Кычкырмагыз, саташканнар!

4 нче кеше. Җитәр сиңа карышырга!

5 нче кеше. Без – ачлар. Без – ялангачлар. Кайтарыгыз безне балаларыбыз янына! Без дә дөньяда торырга телибез.

Бикморза. Дөньяда торырга теләсәгез, без сезгә тормыш өләшүче түгел.

5 нче кеше. Ә... түгелмени? Алайса, сез безне алдадыгыз? Алайса, сез апара кебек аяк астында изелүдән башкага ярамыйсыз!..

Бикморза. Кит минем янымнан! Без сезне алдамадык. Без бары – сезнең арагыздан берәүләр генә.

1 нче кеше. Нәрсә алар белән сөйләшеп торасыз?

2 нче кеше. Без үзебез хуҗа үз эшебездә. Без кайтабыз.

Бикморза. Әгәр сез, башларыгызны аяк табаннарына кадәр иеп, аңа кайтырга телисез икән – юл булсын! Тәндә җаныбыз булганда, сез безне сата алмассыз.

1 нче кеше. Без сезне тереләй өстерәп илтербез.

2 нче кеше. Без тиреләрегезне тунап илтербез.

Бикморза. Без йөз үлемне берьюлы күтәрербез, әмма Хөсәен мирзага кайтып баш ию хурлыгын күтәрмәбез.

5 нче кеше. Аркан белән тышаулап кайтарырбыз без сезне!

2 нче кеше. Нәрсә сөйләшеп торасыз алар белән!

3 нче кеше. Тавышланмагыз, хайваннар!

4 нче кеше. Без кайтарырбыз аларны!

6 нчы кеше. Кычкырмагыз, рәтләп сөйләшегез!

7 нче кеше *(Җаббарга).* Син кыздырма алай – үзең пешәрсең.

Бикморза. Мин сезнең арагызда низаг ишетәм. Бу – безнең өчен хәерле фал. Әгәр чынлап та мирза каршына кайтучылар булса – китсеннәр, йөзтүбән кадалсыннар! Ә без калырбыз... соңгы чиккә кадәр көрәшербез...

Җаббар. Җәмәгать! Алар безне тагын үзара буташтырырга телиләр...

5 нче кеше. Сөйләтмәгез үзләрен!

1 нче кеше. Бәйләп ташлагыз фетнәчеләрне!

3 нче кеше. Кул ягасы булмагыз!

2 нче кеше. Капчыкка төяргә кирәк башларын!

6 нчы кеше. Орынмагыз миңа – эчәкләрегезне айкармын!

5 нче кеше. Нәрсә карыйсыз, бәрегез!

7 нче кеше. Кара!.. *(Җаббарга.)* Мин синең сакалыңның бөртеген калдырмам!

1 нче кеше. Курыкмагыз, туганнар!

2 нче кеше. Бәрегез үзләрен!

4 нче кеше. Бәйләгез икесен дә!

5 нче кеше. Изегез измәләрен!

(Халык арасында шау-шу. Муса белән Бикморзаны сырып алалар, үзара да ызгыш бара, берничәсе Мусага сугарга чамалый. Муса урыныннан сикереп тора.)

Муса. Туктагыз! Алыгыз кулларыгызны минем өстемнән. Әгәр куркасыз икән, менә мин мылтыгымны да ташлыйм сезнең аяк астыгызга. *(Мылтыгын ташлый.)* Ләкин белегез: иң элек сез кыргыйларча безнең тәннәребезне кискәләрсез дә, аннан соң гына мирза каршына илтә алырсыз. Әгәр сезнең күңелегездә тузан кадәр генә ачу, зәррә кадәр генә үч алу теләге калмаган икән, сезнең юлыгызга үзебезнең буыннарыбызны турап салудан без катрә[1] кадәр генә дә чирканмыйбыз. Кирәк икән, әнә, алыгыз шул картның ак сакалыннан! Кем бар арагызда шуңа батырчылык итүче?! *(Халык арасында наразыйлык[2], тавыш.)*

Җә, нигә җавап бирмисез? Нигә сез йөзләрегезне җир шикелле каралттыгыз? Аз гына, бик аз гына уйлагыз да, бу эшегездән оялыгыз! *(Берсенә.)* Оял син, яңадан кай-

---

[1] Катрә – тамчы.

[2] Наразый – риза булмау.

тып, шул ата дошманның баскан туфрагын үбәргә. Моннан бер генә ел элек кулындагы таягына чорналган ап-пак сакалын көчкә күтәреп йөргән карт атаңны казаматта череткәннәрен оныттыңмы әллә? *(Бер картка.)* Оныттыңмы син, карт, бердәнбер талчыбыктай кыз балаңны ерак Азия сахраларына сатып җибәргәндә кыр капкасына сөялеп җылап калганыңны? *(Бер егеткә.)*

Оныттыңмы син чәчәк кебек сөйгәнеңне үз кулың белән бояр малаена ястык итеп керткәндә, борчак-борчак яшьләреңә төелеп, озатып калганыңны? Оныттыгызмы, дуслар, көчләнгән хатыннарыгыз, мыскылланган кызларыгыз, сатылган улларыгызның йөрәкләргә салган яраларын? Оныттыгызмы гомер буе җан тирләрегез белән боярларга хезмәт итеп, ач бүреләр, таланган этләрдәй кыйналып гомер итүегезне? *(Пауза.)* Ягез, нигә җавап бирмисез?

Бикморза. Ник эндәшмисез? Без соң аларны оныта алабызмы? Без үз көнебезне үз кулыбызга алу өчен, өстебездә албасты булып яткан мирза, түрәләрнең көлләрен җилгә очыру өчен, ирекле тормыш өчен канлы көрәштән баш тарта алабызмы?

Җаббар. Җәмәгать! Җә, нәрсә карап торасыз?

2 нче кеше. Безгә әзрәк уйлашырга миһләт[3] бирегез.

Шакир. Иптәшләр! Тагын нәрсә уйлашырга! Бу фетнәләрнең төбендә нәрсә ятканы безгә ачык түгелмени?! Халык арасына коткы салучыларны нигә яшерәбез?

Муса. Син, егет, курыкма, ачыграк сөйлә!

Шакир. Бу эшләрнең төбен, әнә, Җаббарның олтырак битеннән сорагыз.

Җаббар. Син үлчәп сөйлә, егет!

3 нче кеше. Шакир дөрес әйтә.

6 нче кеше *(Җаббарга)*. Син җыя төш салма савытыңны!

Шакир. Иптәшләр! Нигә яшерергә! Бу коткыларның башында торучыларның берсе шул Җаббар түгелме?

3 нче кеше, 6 нчы кеше. Шул, шул!

5 нче кеше, 2 нче кеше. Җаббарга бәйләнмәгез!

Җаббар. Син, Шакир, ул сүзләреңнең кая барганын уйлап сөйлә!

Шакир. Мин чынын сөйлим. Бу турыда атналар буенча яшертен эш алып баручылар Солтан белән Җаббар булды. Үзләренә каршы булган кешеләрне кичә үлем белән куркытучы шулар булды.

3 нче кеше, 6 нчы кеше. Дөрес!

Бикморза. Йә, Җаббар, әйдә инде ачыктан сөйләшеп карыйк!

Шакир. Кичә халыкны җыючылар, Әхмәтне җибәрүчеләр шулар булды түгелме?

Җаббар. Син ялганлама!

6 нчы кеше. Ә син бугазыңны күтәрмә!

Җаббар. Сез миңа яла яга алмассыз!

Муса. Тавышланмагыз! Тәртип белән.

Шакир. Иптәшләр! Эчтәге зәһәрне нигә сытып чыгармаска!

6 нчы кеше. Дөрес! Моннан өч-дүрт көн элек Муса белән Бикморза аганы үтереп ташларга өндәмәдегезме, әйт, эт баласы!

Җаббар. Ялган! Ифтира[4]!

Шакир. Тик кенә тор. Мин ике атнадан бирле сезнең артыгыздан сагалап йөрдем. Мин бер атнадан бирле төн йокысы күрмәдем. Мин кичәдән бирле корыдагы балык кебек кая барып сугылырга белмәдем.

Муса. Җаббар, Шакир. Хәзер һәммәсе ачык!

[3] Миһләт (мөһләт) – кичектереп тору.
[4] Ифтира – яла ягу.

Җаббар. Җәмәгать!

Бикморза. Чыгарма тавышыңны, суккин сын!

3 нче кеше. Кая качкан Солтаны?

6 нчы кеше. Алар безне алдап йөрттеләр.

8 нче кеше. Җыярга кирәк башларын!

Җаббар. Егетләр! Миндә гаеп юк. Мин бары Солтан сүзен генә тоттым...

6 нчы кеше. Нәрсә сөйләтеп тотасыз – бирегез башына!

Шакир. Салыгыз сөякләрен аяк астына!

3 нче кеше. Кая качты әле башка этләре!

7 нче кеше. Кыйнагыз!

Шакир. Җәһәннәмгә җибәрегез!

Муса. Туктагыз! Аңа кул ягасы булмагыз! Әгәр дә сез миңа ышанасыз икән...

Тавышлар. Ышанабыз! Мең кат ышанабыз!

Муса. Ул вакытта сез аны минем кулыма тапшырыгыз. Мин аңа үзем җәзасын карармын. Бикморза ага! Ал Җаббарны үз каравыңа!

Бикморза. Әйдә, ләгънәт төшкере!

Муса. Ә башкалары турында без соңрак сөйләшербез. Иптәшләр!

Әгәр дә сез моннан соң да үзегезнең башлыгыгыз итеп танысагыз...

Тавышлар. Без сиңа гына ышанабыз!

– Без синнән калмыйбыз!

– Синең сүзеңнән чыкмабыз!

– Син кайда, без шунда!

Муса. Әгәр дә шулай булса, без бүгенге күңелсезлекләрнең тапларын тиз бетерербез. Без нәрсә күрсәк тә бергә күрербез.

Озын сүзләргә хәзер вакыт юк. Безгә иң тиз арада бу урыннан күчәргә кирәк. Приказны тыңлагыз!

Халык. Муса безнең атабыз булсын!

Муса. Ярты сәгатьтән атлар иярләнгән, арбалар җигелгән, һәммәгез дә сугышка хәзерләнгән булсын. Без юлга чыгабыз! Һәммәгез дә урыннарга!

(Халык тарала, тавышлар, сызгырулар.)

Пәрдә

АЛТЫНЧЫ ПӘРДӘ

Урман арасы. Артка тау менеп китә. Сәхнәдә төпчекләрдән, агачлардан башка бернәрсә дә юк. Вакыт кич.

Пәрдә ачылганда ерактан җыр тавышлары килә.

Җыр

Башлаучы. Кара урманның уртасында
Боегып гөлләр үсә икән.
Шул боеккан гөлләр кебек
Яшь гомерләр үтә икән.

Хор. Нигә сула, яна-яна,
Сөйгән өчен кыз бала?
Кай җирләрдә ул сызлана
Бибисара бичара.

Башлаучы. Кая барсам ак каенлай,
Кайда юллар, дускаем?

Юллар сапкан юлаучыдай
Йөри ялгыз башкаем.
Хор. Нигә сула, яна-яна,
Сөйгән өчен кыз бала?
Кай җирләрдә ул сызлана
Бибисара бичара.
(Югарыдан бер төркем кызлар төшәләр.)

Кызлар

Хәдичә. Тсс! Әкрен!

Кызлар. Тсс!

Хәдичә. Әллә нинди таулы җирләрне үтәбез. Монда да һичкем күренми.

Нәфисә (*кычкыра*). Ә-у-у!

Хәдичә. Тсс! Бер тавыш та юк! Нишләрбез, нишләрбез? Әгәр аны таба алмасак, ничек кайтып күренербез?!

Нәфисә. Без хәзер бөтенләй юлны саптык. Әгәр кая таба барганыбызны белсәк, бәлки, табар идек.

Хәдичә. Мин сизәм – без көньягына таба барабыз. Дивана урманны яхшы белә. Ул, шиксез, авылга таба алып киткәндер.

Нәфисә. Мин әллә нинди тавыш ишетәм шикелле.

Хәдичә. Мин дә бая нәрсәдер ишеткән шикелле булган идем. Ләкин ул курыкканнан гына.

Нәфисә. Әйдәгез, шул якка таба китик!

Хәдичә. Әйдәгез. Безгә аны тапмый кайтырга ярамый – харап булырбыз...

Нәфисә. Әйдәгез!

Хәдичә. Сез курыкмагыз! Әле бик караңгы түгел. Әгәр бөтенләй караңгы төшсә, без Тимер казык йолдызына карап китәрбез. Ул безне Зирекле елгасына алып чыгар.

Нәфисә. Тсс!

Хәдичә. Әйдәгез! Әкрен! Курыкмагыз. Бер-берегездән калмагыз!

(Тезелешеп уңга китәләр. Сәхнә бераз буш тора, Шакир белән Бикморза чыгалар.)

Бикморза, Шакир

Бикморза. Шакир! Әллә бер чәйләп җибәрәбезме?

Шакир. Анысы була, Бикморза агай. Тик менә чәй янына бернәрсәсе дә юк бит, каһәрне... *(Өчаяк куя, ут яга, чиләк аса.)*

Бикморза. Менә монда бераз бәрәңге, ярты ипи бар. Бүгенгә шулар белән сыйланып торыйк, ә иртәгесен күз күрер анда.

Шакир. Монда безгә тыныч булыр инде.

Бикморза. Әйе, әгәр анда калган булсак, алар инде безне килеп басканнар булыр иде. Ярый, син үзеңне ирләрчә тоттың, Шакир.

Шакир. Ай, мин ничек шатланам, Бикморза ага. Кичә сөйләшкәннән соң минем өстемнән дөнья кадәр йөк төшкәндәй булып китте.

Бикморза. Әй, кем ул анда килә?

Шакир. Муса абзый булыр. Ул каравылларны карарга киткән иде.

Бикморза. Әйе, Муса булыр.

Шакир. Бикморза агай! Син утны карый тор, мин корырак агачлар җыйнап килим әле.

Бикморза. Ярый, бар. *(Муса керә, Шакир аңа каршы очрый.)*

Муса, Бикморза, Шакир

Муса. А, Шакир. Син яңа нигезнең учагын терелтергә дә өлгердеңме?

Шакир. Әһә! Хәзер бик һәйбәтләп чәй эчеп җибәрербез... Син дә бик аргансың...

Муса. Сыйлаганда су эч, ди... Шәп, шәп...

Шакир. Ә беләсеңме, Муса абзый, нәрсә белән эчәрбез?

Муса. Нәрсә белән?

Шакир. Минем, бик кирәккә генә, дип, саклап калдырган шакмак ярым шикәрем бар. Бүгенге шатлыктан шуның белән гуляйт иттерми хәл юк инде үзегезне...

Муса. Ха-ха-ха! Яхшы, яхшы...

Шакир. Бәйрәм ясап бер фарсит итеп җибәрик әле...

Муса. Ярыйсың син, Шакир, ярыйсың... бар, эшеңдә бул... *(Шакир китә.)*

Муса, Бикморза

Бикморза *(учакны карап)*. Җә, Муса, ниләр бетердең?

Муса. Мин бөтен каравылларны карап- тикшереп чыктым. Егетләр янына барып, бераз әңгәмәләрен тыңладым. Хәзергә һәммәсе дә май кебек.

Бикморза. Киләчәктә шундый күңелсезлекләр булмауны нык күзәтергә кирәк.

Муса. Шулай. Дошман йогынтысыннан бик сак булырга кирәк.

Бикморза. Җаббар ничек?

Муса. Мин аның белән шактый озак сөйләштем.

Бикморза. Һаман шулай болгатамы әле?

Муса. Юк, хәзер үзенең үткен казыкка туры килгәнен аңлаган булырга кирәк. Мин аларның бөтен серләрен тарттым, бөтен корган уйлары турында күп нәрсәләрен алдым. Хәзер һәммәсе дә ачык.

Бикморза. Шулаймы?

Муса. Солтан белән Җаббар күптән хәзерләнеп килгәннәр. Тик егетләрнең ныклыгы гына аларның кул-аягын бәйләп тоткан.

Бикморза. Хәзер инде ул безгә артык кирәк тә булмас, алайса?

Муса. Әйе.

Бикморза. Мин әле аны кичә калдырудан да шикләнеп торган идем. Булмаса, мин барыйм да, аның эшен бетереп тә килим.

Муса. Шулаймы?

Бикморза. Әйе... Үзе хәзерләгән табагыннан үзе татысын.

Муса. Ярый, бар. Ә калган берничә йогынтыларын без ничек тә болай ышкыларга тырышырбыз.

Бикморза. Дөрес... Мин хәзер килермен. *(Бикморза уңга китә.)*

Муса ялгыз

Муса. Аз гомердә никадәрле юллар үтелгән! Уйласаң, башыңдагы чәчләреңнең чал булмавына таңга калырсың... Инде тагын бер бусага калды. Анда да аяклар чуалмаса, минем өчен дөньяның үкенечле бернәрсәсе дә калмас иде. (*Пауза.)* Әгәр дә булмаса... Мин боларның иң чыныкканнарын ияртермен дә, атаманга әйләнермен. (*Бер күләгә күренә.)* Әй, кем анда караңгы кичнең тынлыгын бозып йөри?

(Сара чыга, аның күлмәкләре өзгәләнеп беткән.)

Муса, Сара

Сара. Муса!

Муса. Нинди хатын безнең арабызга керүнең юлларын тапкан, әйт яхшы чакта, кем буласың син?

Сара. Син мине танымыйсың да?..

Муса (*гаҗәпләнеп*). А... Сара... Ялгышмасам, бу – син... Алай да синең мондый чакта бу урында очравың мине таңга калдыра.

Сара (*каранып*). Ай, нинди куркыныч...

Муса. Караңгы урманнарның кочагында шулай булуы гаҗәп түгел. Ә синең монда килеп чыгуың гаҗәбрәк. Әйт, нәрсә кирәк булды сиңа бездән?

Сара. Тукта, син нигә миңа алай усал карыйсың? Синең бервакытта да миңа болай караганың юк иде...

Муса. Ә мин бервакытта да мондый очрашуны уйламаган идем. Син хәзер яшерми әйтергә тиеш, кемнәр белән син монда килдең?

Сара. Мин үзем генә килдем.

Муса. Ялганлама, Сара – начар булыр. Кемнәр белән син безне күзәтергә килдең?

Сара. Ялгызым гына, Муса... Ә, юк... минем иптәш кызларым бар иде... Җиләккә чыктык... Кичкә таба алар өйгә кайтырга йөдәткәч, мин алардан качтым да кара урман эчендә берүзем калдым. Минем белән калган дивананы да, караңгы төшкәч, кайдадыр югалтып калдырдым. (*Мылтык атыла.*) Ай!..

Муса. Кара... Сине монда безгә каршы караңгы уйлар белән йөрүче кешеләр китермәдеме? Әгәр шулай булса, мин һичбер минут кичектермичә... *(Муса мылтыгын кулына ала.)*

Сара. А... юк... син ничек алай уйлый аласың? Минем монда йөргәнемне кызлардан башка берәү дә белми. Менә ничә көннәр инде мин баласын эзләгән ана шикелле синең эзләрең артыннан йөрим. Атылган кош шикелле агачтан агачка сугылып, мин хәлдән тайдым... Мине куркыныч җанварлар куды... Әнә, сәләмәләнеп беткәнмен...

Муса. Алай да бу минем өчен бик серле. Син миннән нәрсә генә өметләнә алырсың икән...

Сара. Мин сине эзләп, синең яныңа килдем...

Муса. Мин һаман да бернәрсә дә аңламыйм.

Сара. Син миңа нәрсә диярсең?

Муса. Мин сиңа моңа кадәр әйткәннәрдән башка бер сүз дә әйтә алмас идем.

Сара. Әгәр дә мин бөтенләйгә урманга, синең яныңа килергә теләсәм...

Муса. Тукта! Син нәрсә сөйлисең! Монда андый сүзләрнең урыны, вакыты да түгел...

Сара. Син алай ачуланма! Минем болай да бәгърем таланган...

Муса. Мин сиңа үзеңне дә, мине дә артык борчымаска киңәш бирә алам.

Сара. Мин синең яныңда артык кашык булмас идем...

Муса. Юк! Әгәр дә безнең икебез өчен бер генә йөрәк яратылган булса да, анда да йә син, йә мин генә аңа хуҗа була алыр идек.

Сара. Син нигә бу кадәрле каты буласың?

Муса. Әгәр дә без бер үк ана карыныннан төшкән булсак та, анда да бу урманда безнең икебезне тоташтырырлык бер генә шырпы да табылмас иде.

Сара. Әгәр дә мин атамның бөтен нәрсәләреннән кул селтәсәм дәме?

Муса. Юк, син аны булдыра алмас идең.

Сара. Мин аның үзеннән баш тартсам дамы?

Муса. Синең аңа көчең җитә алмас иде.

Сара. Мин дөньясында һәммәсен дә, һәммәсен дә ташлар идем... Тик син генә мине какмасаң иде...

Муса. Минем йөрәгемнең бер почмагын синең күләгәң борчыганын мин яшерергә теләмим. Алай да... бүген ул гына да безне бармак иллесе кадәр булсын якынайта алмас иде.

Сара. Муса! Мәрхәмәт ит!

Муса. Юк, куй! Безнең арабызда бертөрле дә якынаюга юл куймый торган биек һәм нык коймалар тора. Син бүген калын урманның караңгылыгын кичә алган булсаң да, ул коймаларны гомергә дә кичә алмассың... *(Атыш башлана.)*

Сара. Ай...

Муса. Чү!.. нәрсә бу! Әй, кем бар анда?.. *(Бикморза йөгереп керә.)*

Бикморза, Муса, Сара

Бикморза. Муса! Җиттеләр!..

Муса. Ах, син нәрсә сөйлисең?

Бикморза. Безне чолгап алдылар. (*Берничә егет керә.)*

Егетләр. Муса агай! Җиттеләр!

Муса. Башлыклар! Урыннарга! Бөтен кешене күтәрегез! Тауның бу ягына чәчелегез!

Бикморза. Кем бу? (*Сараны күрә.)* Муса! Рөхсәт ит тә, мин моны урман бүләкләренең беренчесе ясыйм!

Сара. Муса!

Муса. Калдыр, ага, коралсыз хатынга беренче ядрәң әрәм булмасын!

Егетләр! Минем командамны тыңлагыз! *(Китәләр.)*

Сара ялгыз

Сара. Ах! Мин нинди бәхетсез сәгатькә туры килдем... Чү, җиттеләр... кинәт... ялгыш... йә булмаса... чү... шунда... агач арасына... бәлки бары да үтәр...

(Сара югала. Атыш көчәя, сәхнәдән крестьяннар, казаклар үтеп-үтеп китәләр, казаклар крестьяннарны кысалар. Бер крестьян белән бер казак әумәкләшеп чыгалар.)

Казак, крестьян

Крестьян. Ә, нәләт төшкере!

Казак. А, җибәр! Җибәр!

Крестьян. Җибәрермен, бәдбәхет, җәһәннәмгә!

Казак. А!

Крестьян. Йөз түбән кадал, шайтан оргыры! *(Казакны чәнчеп үтерә, ега, мылтыгын ала да китә. Бикморза Мусаны күтәреп чыга.)*

Бикморза, Муса

Бикморза. Муса! Муса! Ах, нишләдең? Шулай ук безне канатсыз кош итеп калдырасыңмыни! Муса!

Муса. Бикморза ага! Бу синме?

Бикморза. Мин, балакаем, мин!

Муса. Минем хәлем начар...

Бикморза. Муса! Кан әсәре дә юк... Кайда булды соң җәрәхәтең?

Муса. Менә... монда... Ах...

Бикморза. Балам! Бер йотым гына су эч әле... бәлкем...

Муса. Юк... Хәзер бернәрсә файда итмәс...

Бикморза. Ай, Муса...

Муса. Син бар... егетләргә бар... Миңа бернәрсә кирәкми... Кара! Егетләрне ташлама... Бар... ахырына кадәр... Җиңүгә кадәр... Ах... *(Үлә.)*

Бикморза. Үлде... *(Сара чыга, Мусага ташланмакчы була.)*

Сара, Бикморза

Сара. Ах, үлгән...

Бикморза. Кит, нәҗес, якын киләсе булма!

Сара. Агай! Бер генә күрсәтегез! Йөзен генә күрсәтегез! Зинһар өчен!

Бикморза. Югал күз алдымнан! *(Крестьян керә.)*

Бикморза, крестьян, Сара

Крестьян. Бикморза! Безне кысалар!

Бикморза. Егетләр! Приказымны тыңлагыз! Тауның көн ягына таралыгыз!

Крестьн. Әйдәгез!

Бикморза. Әйдәгез! Мусаның гәүдәсе безнең өчен крепость булсын... Ахырына кадәр... җиңүгә кадәр...

Сара. Бер генә күрсәтегез!

(Бикморза Мусаны күтәреп китә. Яшьләр ата-ата чигенәләр.)

Сара ялгыз

Сара. Ах! Нәрсә булды! Аның йөзен дә күрсәтмәделәр. Йөрәгемнең яртысын ярып киттеләр... Нигә, нигә барысын да алмадылар!..

Тукта... әнә анда... бик тирәндә... тизрәк... тизрәк... *(Югала.*

Сулдан Әхмәт белән Иргали килеп чыгалар.)

Әхмәт, Иргали

Иргали. Ах, алар тауның икенче ягына күчеп өлгерделәр. Алай да, мин үз кулым белән Мусаның күкрәгенә төзәп аттым.

Әхмәт. Син аны үтердең алайса?

Иргали. Мусаның кулыннан кылычы төшеп аварга торганда, минем өстемә котырган юлбарыс төсле Бикморза ташланды... Ансын да ут алмады бит шайтанны... Казаклар! Очраганнарның берсен дә исән калдырмагыз, әйдәгез! *(Китәләр.)*

Әхмәт ялгыз

Әхмәт. Нинди ерткыч бу Иргали! Ах, әгәр мин кичә аны тыңламаган булсам, бәлки болай канлы сугыш булмас иде...

(Хөсәен, Солтан, капитан, берничә егет керәләр.)

Хөсәен һәм башкалар

Хөсәен. Коралларыгызны ташлагыз. Һәммәгез дә чигенегез! Кем бу?

Солтан. Әхмәт.

Хөсәен. Ах, эттән туган эт, тизрәк сөйлә, нәрсә күрдең?

Әхмәт. Качкыннар чигенде. Бездән егермеләп кеше үлде, яраланучыларның хисабы юк.

Хөсәен. Телең корсын. Тизрәк! Качкыннар нишләде? Мусаны кем күрде?

Әхмәт. Шакирның үлеген мин үзем күрдем. Бикморза аягыннан яраланган, диделәр...

Хөсәен. Ә Муса, Муса?

Әхмәт. Иргали үз кулы белән аның йөрәгенә атты.

Хөсәен. Шайтан алсын телләреңне! Ә син миңа нәрсәләр сөйләдең алар турында ялганлап, бәдбәхет!

Әхмәт. Хуҗам! Мин гаепле. Ләкин минем бу эштә гөнаһым юк. Мине Иргали шулай өйрәтте.

Хөсәен. Таптырыгыз моңардан Иргалине дә, аннан соң җанын җәһәннәмгә җибәрегез!

Солтан *(Әхмәткә)*. Әйдә, тизрәк!

Капитан. Әйдәгез!

Хөсәен. Китерегез Иргалине минем каршыма! Үз кулларым белән суырып алыйм мин аның телләрен.

(Солтан, Әхмәт, капитан китәләр. Дивана чыга.)

Дивана һәм башкалар

Дивана. Гомердән вафа юк,
Үлемнән – чара...
Бүгеннән терәксез
Диванаң кала.
Дәвасы ярага
Кая соң, кая?..
Тагын зар көяргә
Каладыр дивана.

Хор. Йөрәгем яна ла
Күзем кан ала,
Кыз балаларга
Авыр замана.
Абау ла.
Зифа буең михнәт өчен үстеме?
Баш очыңнан хәсрәт җиле истеме?

Хөсәен. Нишләп монда йөрисең син, дивана? Әгәр аз гына акылыңда булсаң, аяк астында шаукым булып йөргән өчен мин сине әллә кайчан өзгәләп чүбек ясаган булыр идем. *(Кызлар Сараны күтәреп чыгалар.)*

Хөсәен, кызлар

Хөсәен. Кем бу? Кемне сез болай озатасыз? *(Кызлар үлекне җиргә куялар, дивана үлекнең баш очына утыра.)*

Хәдичә. Хуҗа хәзрәтләре аны бездән сораганчы, үзенә түземлек сорасын иде.

Хөсәен. Нинди хатын ул ахмак башына үлем эзләп йөргән мондый вакытта?

Хәдичә. Аны без үлгән килеш яр астыннан таптык. Ул дөнья кадәр биектән сикереп үзен харап иткән. Аның әле зифа тәне дә суынып өлгермәгән. *(Үлек өстеннән пәрдәсен ача, Сара күренә.)*

Хөсәен. А! Сара! Мин дөрес күрәмме, әллә гакылымнан яза башладыммы?

Хәдичә. Әйе...Бибисара ул, бичара...

Хөсәен. Бибисара! Ул үзе... Әнә, аның ябылмый калган күзләре! Куркудан чәйнәлгән иреннәре... Бар да, бар да аныкы... Сез, сез аны ничек китердегез... *(Иргали, Солтан керәләр.)*

Хөсәен, Иргали һәм башкалар

Хөсәен. Иргали!

Иргали. Мин сезнең алдыгыздамын, хуҗам!

Хөсәен. Җә, кайда, ник китермисең син миңа Искәндәрне?

Иргали. Искәндәр! *(Карап.)* Сара! Әйе, сез калышмыйсыз... Әмерегез буенча алдыгызга башын китерә алмасам да, сез инде Искәндәрне бервакытта да күрә алмассыз!

Хөсәен. А, син авыр күтәрерсең моның җәзасын!

Иргали. Әйе, мин төшенәм... Мин үземнең уйлаганнарымның берсенә дә ирешә алмадым. Ләкин бу эшләргә Сезнең белән миннән башка берәү дә гаепле түгел.

Хөсәен. Барысына да син сәбәпче, бәдбәх...

Иргали. Әйе, барысына да... һәм үземнең һәлакәтемә дә.

Хөсәен. Югалтыгыз хәзер шуны күз алдымнан! Кулларын аркасына әйләндереп, үз хәнҗәре белән кадаклагыз, күзләрен чыгарып, урынына шәмнәр куегыз да, утарыма илтегез!

Иргали. Ярый. Һәммәсен дә эшләрсез... Тик миңа актык сәгатемдә атамның беркемгә дә чыгармаска диеп әйтеп калдырган васыятен белдереп үтәргә рөхсәт итегез.

Хөсәен. Җә, тагын нәрсәләр сөйләрсең икән!

Иргали. Мин бүген Искәндәр белән Сараның һәлакәтенә сәбәпче булдым. Ләкин аларның сиңа якынлыгы минем сиңа якынлы- гымнан артыграк түгел.

Хөсәен. Мин әле саташмаганмын, син шуны белеп сөйлә.

Иргали. Чөнки моннан 23 ел элек Мәрьям бикә, үлем якасында калып, үлек бала дөньяга китерде. Шул ук сәгать җырчы Гаскәрнең хатыны игез бала китереп, үзе вафат булды. Минем атам, Сезнең ачуыгыздан куркып, үлек балагызны җырчы Гаскәрнең ике баласы белән алмаштырды. *(Гөлбәһар белән Ибраһим керәләр.)*

Хөсәен. Син нәрсә сөйлисең?

Иргали. Шулай. Искәндәр дә, Сара да Сезнең балаларыгыз түгел, әнә, дивананың балалары.

Хөсәен. Ә... Сез әле Хөсәен мирза белән шаярасыз...

Иргали. Әнә, моның тагы да ышанычлырак шаһиты Гөлбәһар карчык үзе түгелме?

Гөлбәһар. Әйе. Без атаклы мирзаның шатлыгы өчен җырчы Гаскәрнең тормышын һәлак иттек.

Хөсәен *(Иргалигә)*. Аһа! Син әле мине үзеңнән элек кабергә тыгарга уйладың... Сез әле минем нигеземне, тормышымны җимердегез дә, хәзер җанымны суырырга телисез?.. Юк... мин сине шулай итеп... менә шулай итеп... *(Иргалине буа.)*

Иргали. А...а...а!

Хөсәен. Җәһәннәмгә йөзтүбән кадалдырырмын... А...а...а! Шулаймы? Кадалдыңмы? *(Үзгәреп, куркынып.)* Үлде... ха-ха-ха! *(Әйләнә.)* Әй, сез, агачлар! Хөсәен мирзага юл бирегез! *(Китә, чәчләрен йолыккалый, халык, куркышып, тарала, ара-тирә атыш тавышлары килә. Дивана тора, Сараны күтәрә. Кызлар, носилка ясап, аны салалар, күтәрәләр.)*

Дивана, кызлар

Дивана. Атам юк, анам юк...
Югалган нәсәбем...
Балам юк, чагам юк...
Чуалган исәбем...
Үлем хәсрәтеннән
Уралган җәсәдем.
Шуңа зар янам мин,
Торам мин – дивана...

(Кызлар күтәрәләр, чәчәкләр җыеп өстенә сибәләр, дивана Сараны кочаклап елый.)

Хор. Йөрәгем яна ла.
Күзем кан ала.
Кыз балаларга
Авыр замана.
Абау ла!
Зифа буең михнәт өчен үстеме?
Башларыңнан хәсрәт җиле истеме?

(Борылалар, китәләр.)

Пәрдә ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ *татар китабы*

Хатыйп Миңнегулов

I

Мәгълүм ки, төрле сәбәпләр аркасында әби-бабаларыбызның бер өлеше, тарихи ватаннарын калдырып, чит җирләргә, башка мәмләкәтләргә күчеп китәргә мәҗбүр булган. Мөһаҗирлек дулкыны аеруча соңгы гасырларда, бигрәк тә 20 нче йөзнең беренче яртысында (Беренче һәм Икенче Бөтендөнья сугышлары, Октябрь инкыйлабы, милли, сәяси эзәрлекләүләр... нәтиҗәсендә) киң колач ала. Милләттәшләребез, дуңгәләк кебек, бөтен җиһанга сибелә. Алар һәм аларның буыннары Төркия, Финляндия, Кытай, Польша, Алмания, Япония, АКШ, Канада, Австралия һәм кайбер башка илләрдә гомер кичерә башлый. Мөһаҗирлеккә дучар ителгән әби-бабаларыбыз арасында шактый гына иҗат әһелләренең, галимнәрнең дә булуы мәгълүм [Сәйф Сараи, Бәркә Фәкыйһ, Мәхмүт Сараи Гөлестаный (14 йөз), Өмми Кәмал (XV гасыр), Муса Акъегетзадә, Йосыф Акчура, Рәшит Рәхмәти Арат, Рәшит Ибраһимов, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Гаяз Исхакый һәм башка бик күп билгеле затлар]. Милли асылны, телне, иманны, гореф-гадәтләрне саклау, буыннар арасындагы дәвамчанлыкны тәэмин итү, рухи ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен шактый гына китаплар языла, дәреслек-әсбаплар төзелә, мәгърифәти-мәдәни учаклар корыла. Әгәр дә бу төр язмалар әүвәл кулдан-кулга күчерелеп таралса, 19 нчы йөздән аларның басма нөсхәләре дә күренә башлый. XX гасырда инде мөһаҗирлектә өч-дүрт дистәдән артык татарча гәҗит-журналларның чыгуы, берничә йөз исемдә китапларның нәшер ителүе мәгълүм. Төрле (әдәби, дини, гыйльми, педагогик, мәдәни..., оригинал, тәрҗемә...) характердагы бу төр басмаларның төп өлеше гарәп язуында. Бераз соңрак латин, кирилл графикасы да кулланыла башлый. Төрекчә, гарәпчә, фарсыча, алманча текстлар да очрый.

Мөһаҗәрәттәге татарча басмалар, язма истәлекләр – рухи мирасыбызның аерылгысыз өлеше. Кызганыч ки, совет чорында алар илебездәге халыкка җиткерелмәде диярлек. Бу төр ядкярләр юньләп өйрәнелмәде дә.

Фәнгә, нигездә, 60 нчы еллар ахырында килгән без фәкыйрегез әүвәл мөһаҗирлектәге татар язма мирасы белән аз-маз гына кызыксынды. Ленинград, Мәскәү, Ташкент, Дүшәнбе китапханәләрендә эшләгәндә аерым материалларның очравын, хәтта «Яңа милли юл», «Kazan» журналларын актаргалавымны да хәтерлим. Әмма чит илләрдәге татар язма истәлекләре белән мин чын мәгънәсендә узган гасырның соңгы дистәсендә генә шөгыльләнә башладым. Моңа төп этәргечне Финляндиягә сәфәрем ясады.

Казан университетының үтенеч-мөрәҗәгате нигезендә, СССР Югары белем министрлыгы без фәкыйрегезне Суоми мәмләкәтенә 1990 елның гыйнварында өч айга гыйльми командировкага җибәрде. Бу сәфәр минем өчен бик тә уңышлы, кызыклы, нәтиҗәле булды (хәтта аз-маз финчә дә сукалый башлаган идем. Бераздан, гадәттәгечә, онытылды). Бу илдәге Хельсинки, Тампере, Турку һәм кайбер башка калаларны күрү, тарихи мәдәни истәлекләр белән танышу бәхетенә ирештем, китапханә-архивларында эшләдем, аерым галимнәре белән очраштым, төрле чараларда катнаштым, чыгышлар ясадым. Минем өчен иң мөһиме һәм файдалысы биредәге милләттәшләребез белән очрашу-



«Азат Ватан» журналы. Германия, 1952 ел



Финляндиядә басылган татар әлифбасы. 1935 ел

аралашулар булды. Аларның сүзләре, биргән китап-язмалары аркылы миңа мөһаҗир татарларның тарихы, рухи дөньясы ачылып китте. Читтәге милләттәшләребезнең катлаулы, гыйбрәтле язмышы күңелемне биләп алды. Алга таба, бигрәк тә Төркиягә, кайбер башка илләргә сәфәрләр вакытында ул хис тагын да көчәя, тамырлана төште. Шуның тәэсирендә узган йөзнең ахырларында-бу гасырның тәүге елларында мин татар мөһаҗирлеге тематикасына татар һәм урыс телләрендә күп санлы мәкалә-хезмәтләр (мөгаен, йөздән артыктыр) яздым. Төрле мәдәни, гыйльми, шул исәптән халыкара конференцияләрдә күпләгән докладлар сөйләргә, радио-телевидениедән чыгышлар ясарга туры килде. Төп игътибар, әлбәттә, «татар мөһаҗирлек әдәбиятының атасы» Гаяз Исхакый мирасына юнәлтелде. Фәнни-аналитик язмалардан тыш, аның мөһаҗирлектә язылган әсәрләре, аеруча публицистикасы, тиешле шәрех-аңлатмалар белән, киң катлам укучыларга тәкъдим ителде. «Инкыйраз» авторыннан тыш, Сания Гыйффәт, Хәсән Хәмидулла, Хөсәен Габдүш, Мансур Арсланбәк, Минһаҗ Исмәгыйли һәм башка күп кенә каләм әһелләренең тормышы һәм иҗади эшчәнлекләре өйрәнелде, әсәрләре матбугатта нәшер ителде. Шулай ук без фәкыйрегез «Яңа милли юл», «Kazan», «Яңа япун мөхбире», «Азат Ватан» кебек журналларны өйрәнүгә дә күп көч кертте, алардагы шактый гына язмалар гавамга җиткерелде. Университеттагы татар филологиясе һәм журналистикасы бүлеге студентларына дистә елдан артык «Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты» исемле махсус курс укытуымны да искә төшерим. Студентлар аны бик теләп, яратып тыңлыйлар иде.

Язмаларның, әзерләгән материалларның күпчелеге әүвәл төрле гәҗит-журналларда («Казан утлары», «Мирас», «Татарстан», «Сөембикә», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» һ.б.) дөнья күрде, аннан төрле җыентыкларга, китапларга кертелде. Мәсәлән, «Дөньяда сүземез бар...» исемле басмада (К., 1999. – 336 б.) мөһаҗирлек темасына багышланган дистәләгән язма бар. Безнең «Гасырлар өнен тыңлап...» (К., 2003. – 335 б.), «Иҗади гамәлле шәхесләр» (К., 2014. – 287 б.), «Записи разных лет» (К., 2010. – 407 с.), «Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур» (К., 2014. – 288 с.), «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей» (К., 2017. – 360 с.), «Әдәбиятны өйрәнү юлында» (К., 2018. – 383 б.) кебек китапларда да чит илләрдәге татар әдәбиятына, матбугатына, мәдәни, гыйльми бәйләнешләргә шактый зур урын бирелә. Ә инде бу китапларыбыз тулысы белән мөһаҗирлектәге татар язма мирасы турында:

1. Исхакый мөһаҗирлектә. Монография. – К.: Таң-Заря, 1999. – 84 б.
2. Гаяз Исхакый. Ислам мәмләкәтләрендә. – К.: Иман, 2003. – 102 б.
3. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты: Монография. – К.: Татар кит. нәшр., 2004. – 368 б.
4. Чит илләрдәге татар әдәбияты: Монография. – К.: Мәгариф, 2007. – 399 б.
5. Яңапар тарихы/ Басмага әзерләүче, кереш һәм «Хәсән Хәмидулланың шигъри иҗаты» мәкаләләренең авторы Х. Миңнегулов. – К.: Изд.-во жур. «Татарстан». 2008. – 128 с.

Шунысын да искәртик: бу төр һ.б. мәкалә-хезмәтләребез, публикацияләребез, аеруча китап-монографияләребез җәмәгатьчелек тарафыннан бик тә уңай кабул ителде. Илдә һәм чит мәмләкәтләрдә алар турында мәкалә-рецензияләр дә дөнья күрде. Язмаларыбызның шактые киң фәнни һәм гомуми әйләнешкә, төрле дәреслек-әсбапларга да кертелде.

II

Озын-озак яшәү чорында минем шәхси китапханәгә китаплар, төрле язма истәлекләр

YAÑA MILLI YUL
Chefredakteur und Herausgeber: A. Ishaki
Jahrg. 8
Juli-August 1936
Nr. (101) 7-8
REDAKTION „YA
Berlin-Charlottenburg
Postfach Nr. 8
«Süyümbike Kültür Cemgiyeti» ceyimlerinden : No. 4.
Şehabettin Mercanî
Turmuşu hem eserleri
Cinap yazuçısı :
Dr. A. Lebib Karan
SAYI : 3
A. BATTAL - TAYMAS
KAZANLI TÜRK MEŞHURLARINDAN
III
ALİMCAN BARUDÎ
Kişiliği, fikir hayatı, içtimaî - kültürel emekleri.
İSTANBUL — 1958
Romantik
Milliyetçi
Ayaz
İshakî
Dr. Alsu Kamalieva
Grafiker

күпләп кергән, алар шулай ук чыгып та тора. Шәхсән, үземнең китапларымны нәшер ителүгә үк төрле китапханәләргә, таныш-белешләргә өләшеп торам. Авторы үзем булмаган басмаларны, кулъязмаларны да өемдә генә тотмыйм. Казан университеты, Алабуга, Чаллы, Әлмәт, Төркестан, Астана китапханәләренә, Татарстан Милли музеена, Казандагы Милли мәдәни үзәккә, Тукай, Яуширмәдәге Исхакый музейларына шактый гына китаплар бүләк иттем. Әле 2018 елда гына да Г.Ибраһимов исемендәге институтның «Мирасханә»сенә, Болгар Ислам академиясенә, нигездә, гарәп графикасындагы йөзәрләгән кулъязма һәм китаплар тапшырдым. Татарстан Милли китапханәсендә дә мин биргән ядкярләр, шул исәптән мөһаҗәрәттәге татар язма истәлекләре дә, мөгаен, берничә дистәдән артып китәдер. Болар арасында Тукайның Төркиядә, Финляндиядә нәшер ителгән җыентыклары, «Kazan» һәм кайбер журналларның аерым нөсхәләре бар.

Инде менә Татарстан Милли китапханәсе җитәкчелеге үтенечен искә алып, бу белем йорты өчен татар мөһаҗирлегенә тулысынча яисә теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәте булган китап-басмаларның яңа партиясен әзерләдем (барлыгы – 70 тирәсе). Әмма әле исемлек, шәт, болар белән генә чикләнмәс.

Мөһаҗирлектәге татар басмаларының зур өлеше Финляндиягә мөнәсәбәтле. Милләттәшләребез бу мәмләкәттә (ул 1809-1917 елларда Рәсәй империясе составында була) 19 нчы йөзләрдә үк яши башлый. Ике гасыр аралыгында аларның саны тагын да күбәя. Биредәге татарларның шактый өлеше – Нижгар төбәгеннән, аеруча хәзерге Кызыл Октябрь районының Актүк (Яңапар) авылыннан (Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Рифат Фәттаховларның туган төбәге). Алар, нигездә, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Биредәге милләттәшләребез, гәрчә аларның саны бер меңнән артып китмәсә дә, милли барлыкны, динне, туган телне, моңны, гореф-гадәтләрне саклап киләләр. Моңа, әлбәттә, аларның татарча төрле китаплар бастырулары, гәҗит-мәҗмугалар чыгаруы да зур ярдәм итә.

Милли китапханәгә адресланган басмаларның да яртысын диярлек Финляндиядә нәшер ителгән китаплар тәшкил итә. Болар арасында Сания Гыйффәтнең «Тормыш көзгесе» драмасы (1937), «Уку китабы» (II кисәк, 1938), Закир Кадыйринең дәреслек-әсбап рәвешендәге «Төрк тарихы сабаклары» (I кисәк, 1938), «Дин сабаклары» (III кисәк, 1938) бар. Мәгълүм ки, халкыбызның билгеле бу ике заты узган гасырның 30 нчы елларында Финляндиядә яши, бик тә нәтиҗәле эш-гамәлләр кыла.

Мөһаҗәрәттәге татарлар арасында иң күп китап чыгарган кеше, мөгаен, Хәсән Хәмидулладыр (1900-1986). Ул Актүк авылында туып үсә, Октябрь алды елларыннан алып гомеренең ахырына кадәр Финляндиядә яши. «Мәгърифәт», «Шималь очкыннары» кебек гәҗит-журналлар, ярты йөздән артык китап язып бастыра. Милли китапханәгә тәгаенләгән исемлектә аның «Пикай» (поэма, 1948), «Хәйрелниса» («Дүрт пәрдәлек фаҗига»), «Вәгазьләр» (1974), «Йөрәк янулары» [(шигырьләр), «Илһам чишмәләре»нең дәвамы)], «Тәкъдир каршында. Беренче дөнья сугышының канлы фаҗигаләрендән». —1973) һәм кайбер башка китаплары бар.

Финляндиядәге иҗат әһелләре арасында Садрый Хәмид (1905-1987) исеме дә күпләргә мәгълүм. Китапханәгә тәкъдим ителгән басмалар арасында аның да «Хаким» (поэма, 1947), «Закир» (поэма, 1946) исемле китаплары бар.

Әүвәл Нижгар төбәгендә, аннан, нигездә, Финляндиянең Тампере шәһәрендә имам, мөгаллим булып эшләгән Зиннәтулла Әхсән Бүре (1883-1945) – берничә китап авторы. Ул, «Коръән»не фин теленә тәрҗемә итеп, аны йөз мең данә белән бастырып, аеруча дан казана. «Turan» исемле гәҗит тә чыгарып ала (1934). Гаҗәеп бай китапханәсе белән мәшһүр. Зиннәтулла әфәнденең кызы Зәкия ханым 1990 елда ул бай хәзинәдән безгә дә бераз өлеш чыгарды (рәхмәт үзенә). Милли китапханәгә тапшырылган китапларның



да берничәсе – әнә шуннан. Аларның берсендә (Тампере, 1945) Садри Максуди һәм «Төркләр берлеге» хакында сүз бара. Ул Зиннәтулла Әхсән Бүренең үзе тарафыннан язылган.

Финляндиядәге милләттәшләребез Октябрь инкыйлабына кадәр илдә нәшер ителгән аерым китапларны да кабат бастырып тараталар. Болар арасында «Габдулла Тукай. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (Хельсинки, 1953), «Гани бай» (Тампере, 1945) һәм кайбер башка төр китаплар бар.

Сирәгрәк булса да, соңгы елларда да Финляндиядә татарча басмалар дөнья күреп тора [«Сандугачым, син дә сайра» (1990), «Кәҗә белән сарык» (балалар өчен, 1981) һ.б.].

Төрки кардәшләребез яшәгән Госманлы дәүләте (узган гасырның 20 нче елларыннан алып Төркия җөмһүрияте) – татарлар өчен элек-электән тыгыз аралашкан мәмләкәтләрнең берсе. Биредә күп кенә әби-бабаларыбыз, аеруча зыялыларыбыз, әдип-галимнәребез укыган, яшәп алган яисә гомер кичергән. Дәүләтсез калган, коточкыч колониаль изелүгә тарыган берничә йөз мең кавемдәшебез, шул исәптән кырым татарлары да Кече Азиягә күчәргә, үзләренең тереклекләрен шунда дәвам итәргә мәҗбүр була. Алар Төркиянең яшәешенә, үсешенә үзләреннән сизелерлек өлеш кертәләр. Мөһаҗирләрнең эшчәнлегеннән башка, бу дәүләтнең фән һәм мәдәниятен, рухи тормышын тулысынча күз алдына китереп булмый. Әлеге мәмләкәттә татар һәм төрек телләрендә безнең милләтебезгә теге яки бу дәрәҗәдә кагылышлы шактый гына басмалар дөнья күргән. Милли китапханәгә тапшырылган ядкярләр исемлегендә аларның саны дистәдән артып китә. Болардан аеруча күренекле тарихчы А.Баттал-Таймасның (1883-1969) Ризаэддин Фәхреддин, Галимҗан Баруди турындагы монографияләре (1968, 1958), Русиядән аерылган милләтләр (эстоннар, латышлар, литвалылар, финнар һәм ляһлар) хакындагы китабы (1927) игътибарга лаек. Табиб, журналист, тарихчы, әдип, Г.Исхакыйның фикердәше Әхмәд Ләбиб Каранның (1887-1967) «Шиһабеддин Мәрҗани: тормышы һәм әсәрләре» монографиясе дә (1964) шактый кызыклы, бай эчтәлекле.

Соңгы өч дистә ел эчендә, аеруча узган гасыр ахырларында күп кенә татар яшьләре Төркиядә укыды, белемен күтәрде, бер өлеше шунда ук эшкә дә калды. Мәсәлән, минем университеттагы сабакташым, фән докторы Малик Хәйруллинның улы Сәгыйть Хәйри, безнең элекке студентларыбыз Чулпан Зарипова, Рамилә Яруллина, Роза Корбанова, Алсу Камалиева һәм башкалар Төркиядә халкыбызны таныту, аның рухи мирасын өйрәнү юнәлешендә нәтиҗәле генә хезмәт куялар. Мәсәлән, Зәй төбәге кызы (якташым) Алсу Камалиева үзенең монографиясе белән (Анкара, 2009. – 248 б.) Г.Исхакыйны гыйльми өйрәнүгә саллы гына өлеш кертте.

Мәгълүм ки, бөек әдибебезнең кызы Сәгадәт Чыгатай (1907-1989) ярты гасырдан артык Төркиядә яшәде. Күренекле профессор, тюрколог буларак таныла, татар тематикасы буенча да хезмәтләр яза. Төркиянең гыйльми, мәдәни җәмәгатьчелеге аны зурлый, аның турында язмалар чыгып тора. 2007 елда, мәсәлән, Истанбулда бу затның тормыш юлын, күпкырлы эшчәнлеген яктырткан, кыйммәтле иллюстрацияләргә бай китап нәшер ителде. Милли китапханәгә әлеге басманы да бүләк иттем. Исемлектә шулай ук Исфәндияр Ишгайның (1908-1992) «Җәһәннәмнән котылганнар» исемле шигырьләр җыентыгы (Анкара, 1956) һәм кайбер башка китаплар, «Kazan», «Төрек йорды», «Төрек культуры» журналларының аерым саннары да бар. Ахыргы икесендә, гәрчә алар төрек телендә булсалар да, безнең милләт вәкилләре дә актив катнаша, татар тематикасы да мул гына яктыртыла.

Соңгы йөз елдан артык вакыт эчендә Алманиядә дистәгә якын татарча гәҗит-журнал чыгуы, шактый гына китаплар басылуы мәгълүм. (Аларны нәшер итүгә Финляндиядәге милләттәшләребез сизелерлек матди ярдәм күрсәтә.) Боларның инде кайберләрен мин элегрәк Татарстандагы аерым китапханә-музейларга бүләк иткән идем. Бу юлы исә Милли китапханәгә Шиһап Нигъмәтинең «Шигырьләр» җыентыгын (Мюнхен, 1953), «Яңа милли юл» (1928-1939), «Азат Ватан» (1952-1953) журналларының аерым саннарын гына тапшырдым.

Финляндия, Төркия һәм Алманиядән тыш, татарча яисә халкыбызга мөнәсәбәтле кайбер башка телләрдәге басмалар Кытай, Япония, Румыния, Үзбәкстан, Казакъстан, Австралия, АКШ кебек мәмләкәтләрдә дә дөнья күргән. Болар хакында безнең хезмәтләрдә шактый гына мәгълүматлар бар. Шуңа күрә биредә аларга тукталып тормыйм. Минем китапханәгә тәкъдим ителгән ядкярләрнең дистәдән артыгын ул илләрдә чыккан басмалар тәшкил итә. Аларның кайберләрен генә атап китәм: «Яңа япун мөхбире» (журнал, Токио, 1935-1945. Берничә саны), «Татар әңгимелери» (Татар хикәяләре җыентыгы. – Алматы, 2013), Әхмәд Гәрәйнең Нью-Йоркта 1963 елда чыккан ике китабы: а) «Ниләр, ниләр, тагы да ниләр?» б) Америка шагыйрәсе Эмилия Дикенсонның инглизчәдән татарчага тәрҗемәләре (бу китапта Сания Гыйффәтнең дә өч шигыре теркәлгән) һ.б. Исемлектәге «Яшь Төркестан», «Милли Төркестан», «Азад Төркестан» журналларында да (алар Алманиядә нәшер ителгән) татарга кагылышлы күп кенә факт-мәгълүматлар теркәлгән.

***

Бу язмада без мөһаҗәрәттәге татар басма сүзе хакында, нигездә, шәхси китапханәбездәге Республика Милли китапханәсенә тапшырылган басмаларга мөнәсәбәттә генә фикер йөрттек. Ул да чагыштырмача гомум, белешмә рәвешендә генә. Алдарак әйтелгәнчә, татар мөһаҗирлек әдәбияты, матбугаты турында безнең һәм кайбер башка авторларның хезмәтләрендә шактый мул язылган, күптөрле факт-мәгълүматлар китерелгән. Биредә шунысын гына искәртеп китәбез.

Чит илләрдәге татар китаплары, гәҗит-журналлары, гәрчә аерым хосусый характер-



«Яңа милли юл» журналының Р.Фәхреддингә багышланган саны, 1936 ел

«Яңа япон мөхбире» журналы, 1934 ел

дагы үзенчәлекләргә ия булса да, гомумтатар мирасының аерылгысыз өлеше. (Әмма, ни кызганыч, алар әле күп кенә гыйльми язмаларда тиешенчә исәпкә алынмый.) Ул үзенең тамырлары, төп асылы белән Идел-йортка – татарның төп Ватанына бәйле. Мөһаҗәрәттә иҗат ителгән күпчелек язмаларның авторлары (Гаяз Исхакый, Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Исфәндияр Ишгай, Мансур Арсланбәк, Шаһвәли Келәүле Илдәр, Шиһап Нигъмәти, Минһаҗ Исмәгыйли, Исхак Хәйрулла, Рәшит Рәхмәти, Арат Габделбарый (Габдулла) Баттал-Таймас һ.б.) – әүвәл үз илләрендә иҗат, язу-сызу эшләре белән шөгыльләнеп, аннан чит мәмләкәтләргә киткән затлар. Аларның әсәрләрендә, нигездә, 19 нчы йөз-ХХ гасыр башы татар әдәбияты, язма теле традицияләре дәвам иттерелә. Совет җирлегендәге әдәбияттан үзгә буларак, мөһаҗирлектәге язмаларда миллилек үзәктә, татар язмышы, аның үткәне, хәзергесе, киләчәге – әйдәп баручы төп мотив. Аларда дини-әхлакый тәрбиягә зур урын бирелә. Туган җирне, Идел-йортны сагыну, мөһаҗирлекнең гыйбрәтле язмышы, үз халкыңны азат, бәхетле итеп күрергә омтылу мөһаҗирлектәге сүз сәнгатенең бөтен тукымасына сеңгән. Шуның белән бергә, чит мәмләкәтләрдә иҗат ителгән әсәрләрдә шул илнең, төбәкнең табигате, тормыш-яшәеше, аерым гореф-гадәтләре, кешеләре дә билгеле бер гәүдәләнеш тапкан.

Мөһаҗәрәттәге әдәбият төр һәм жанр ягыннан да шактый бай. Анда чәчмә, тезмә, драма, публицистика төрләре дә иркен кулланыла. Күпләгән дастан-поэмалар, шигырьләр, хикәя-повестьлар, хәтта романнар да иҗат ителә. Оригиналь язмалар белән беррәттән, тәрҗемәләр дә бар. Фәнни, методик әдәбият, дәреслек-әсбаплар да языла.

Әйткәнебезчә, соңгы 20-30 елда инде без гәҗит-журналларда, үзебезнең китап-җыентыкларда мөһаҗирлектә иҗат иткән күп кенә авторларның (Гаяз Исхакый, Хәсән Хәмидулла, Сания Гыйффәт, Минһаҗ Исмәгыйли, Хөсәен Габдүш һәм башкаларның) шактый гына язмаларын киң катлам укучыларга җиткергән идек. Алла боерса, «Безнең мирас»ның алдагы берничә санында чит илләрдә нәшер ителгән аерым язмаларны (нигездә, әдәби текстлар) журнал укучыларына тәкъдим итәргә җыенабыз. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

КЫЗЫЛ АРТЫНДА – КАРАЛЫК

Фәрит Хатипов

Совет чорында инкыйлаб солдатлары – кызыл гаскәриләр – бары тик уңай яктан, романтик биеклектә генә сурәтләнделәр. Рәхимсез көрәш-бәрелешләрдә кан койган, шәһит киткән затларны бүтәнчә тасвирлау, ничектер, гаделсезлек булыр, күңелләрдә ныклап утырып калган күркәм образның типиклыгына күләгә төшерер кебегрәк күренә иде. Аннары кызылармияче турында башкача уйлау хәвефсез дә түгел иде.

Ләкин бәндәләрнең барысы да бер генә калыптан сугылмаган бит. Дөнья күргән ил агаларына төрлесен очратырга туры килгән: әйбәтләрен дә, холыксызларын да. Төптән уйлаганда, тегеләре дә, болары да әдәбиятта үзләренә урын даулый. Хәят турында китап

аркылы гына фикер йөртмичә, тормышның үзенә текәлеп караган әдип игътибарын андыйларга да юнәлтмичә калмый. Моңа мисал итеп, Ә.Еникинең «Коръән-хафиз» (1964) хикәясен, Г.Бәшировның «Сарут» (1981) повестен күрсәтергә була. Алар һәр икесе дә Гражданнар сугышы чорын бәян итәләр, кызылармияче образын яктырталар. Ләкин болар без күрергә күнеккән гаскәриләргә бер дә охшамаганнар, холык һәм гамәлләре, кыяфәтләре белән алардан шактый ерак торалар. Әллә шунлыктан, әлеге әсәрләр тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк кала килделәр, гәрчә әдәби яшәештә күзгә чалынырлык булсалар да, аларга аерым дикъкать юнәлдерелмәде, тәфсилле анализ ясалмады, болар тирәсендә әллә ни бәхәс тә кузгалмады. Ошбу әсәрләр тикшерү, шәрехләү өчен җайсызрак та күренделәр, ахрысы.

Һәр ике әсәрнең авторы да персонажларының болай төшеп калганнардан булмавына басым ясый. «Коръән-хафиз»ның баш герое Хафиз хәлфә, мәсәлән, килеш-килбәте белән гаять күркәм, көяз: «Озын кара казаки кигән, нечкә билле, киң күкрәкле, уртадан калкурак нык, какча гәүдәле, бәрхеттәй кара сакал әйләндереп алган ак чырайлы, юешләнебрәк торган кызыл иренле, ефәктәй йомшак кара мыеклы һәм аз гына сары йөгергән елтыр кара күзле бик чибәр бер кеше иде ул».

Өстәвенә, бу әфәнде Коръәнне яттан бик матур итеп, көчле Мисыр мәкаме белән укый. «Әгузү билләһи...» дип аз гына сакауландырып, тавышын аз гына калтырата төшеп башлап җибәрүгә, мәҗлес халкы тәмам оеп, мәрткә киткәндәй, тынып кала, ә ишек артына җыелган хатын-кызлар, авызларын яулык чите белән каплап, тәмам эреп, яшьләрен агыза-агыза аны тыңлыйлар». Мәхәлләдә, Дәүләкәндә аның шөһрәте, дәрәҗәсе үсеп китә, агай-эне аның зур гыйлем иясе булуына, зирәклегенә соклана. Ул, хәтта күп кенә сәүдәгәр кызларының да төшләренә кереп, күңелләрен кытыклый һәм төн йокыларын качыра башлый.

Ләкин хәлфә менә шушындый бер генә төс белән тасвирланырдай адәм түгел. Ә.Еники аны кискен контраст фонда чагылдыра. Бу кешенең мәдрәсәгә беренче керүендә үк шәкертләрнең эченә, салкын бизгәк шикелле, өшеткеч бер курку йөгерә. Аның кем икәнен ачык сиздерер өчен, автор әсәргә гаҗәп үзенчәлекле бер деталь китереп кертә. Әлеге хәлфә кечкенә шәкертләр каршына өч талдан үрелгән озын чыбык белән килеп баса һәм юк кына гаеп өчен, сизмәгәндә, бер сүз әйтмичә, җитмәсә, әле көлемсери биреп, шул чыбык-камчы белән балага китереп суга, аларны яңаклый, базга төшереп яба. Аның җәзаларыннан соң, кайбер шәкертләрнең колагы ага торган булып кала. Коръән-хафиз бөтен мәдрәсәнең котын алып торган ерткыч зобанига әверелә. Әсәрне хикәяләүче шәкерт аны өч урында селәүсенгә тиңли.

Шул ук вакытта хәлфә үзенең хакимлек масштабын арттыру, хокукларын киңәйтү турында да хыяллана. Аныңча, моңа ирешүнең иң ышанычлы юлы – Искәндәр ахунның җиләктәй сылу кызы Гайшәгә өйләнеп җибәрү һәм, ахун кияве сыйфатында, бай мәхәлләдә имам булып калу. Моның өчен ул хәзрәткә ничек тә якынаерга, үзен итагатьле итеп күрсәтергә, имамның җылы карашын яулап алырга тырыша.

Ләкин ахун хәзрәт колагына хәлфәнең кырын эшләре турында ишетелгән була инде. Ул аңа болай ди: «Алайса, ишек төбенә китеп, минем сүземне тыңлагыз: килмешәк мишәр өчен минем үстергән кызым да, әзерләп куйган мөнбәрем дә юк». Мондый җавап көяз-усал хәлфә өчен бөтенләй көтелмәгәнчә була.

«Сарут» повестеның баш герое Мифтах Шәмгуновны да Г.Бәширов күркәм кыяфәтле, гайрәтле егет, дип тәкъдим итә. Ә.Еники хикәясенә хәлфә әзер характер белән килеп кергән иде. Әдип аның үткәне турында бер сүз дә әйтми. Беренче заттан, «мин» исеменнән хикәяләгәндә, читтән килгән кеше турында сүз барганда, бу мөмкин дә түгел. Аның бөтен барлыгы әсәрдәге вакыйгалар барышында, укучы күз алдында

ачыла. Мифтах Шәмгуновта яман холык формалашуын исә Г.Бәширов тәрбия шартлары белән аңлата, моның байтак мисалларын китерә. Әсәрдән күренгәнчә, Мифтах рәхимсез үги ана типкесендә үсә: «ул кечкенәдән үк явызлыкның зәһәре белән агуланып, аның «тәмен татып», шуннан рәхәт табып үсте».

Гражданнар сугышы чорында бу егет ихтыяри булып Кызыл Армиягә языла да качып кайта, гаскәри киемнәрен сатып эчә, бомба ыргытып, авыл Советы йортын шартлата, бөтен халыкны кан калтыратып тора. Трибунал аны атарга, дип хөкем чыгара. Мифтах атарга алып барган җирдән качып китә.

Бу әсәрләрнең сюжеты гыйбрәтле характерларны ача баруга корылган. Ике әсәрдә дә әлеге персонажларның үчлекле булулары, ярсый-ярсый үч алырга йөрүләре бәян ителә. Гражданнар сугышы вакытында, авыл, шәһәрләр әле бер якта, әле икенче якта калган чакта, Хафиз хәлфә Искәндәр ахун йортына бәреп керә: «Шпорлы итекләрдән, кызыл галифедән, ак папахадан, папаханың бөтен буена кыеклап кызыл тасма тоткан; аркылы-торкылы каеш шлеялар кигән, бер янтыгында – кылыч, икенче янтыгында – наган». Шундый шартларда да бу егет кыяфәтне китерә белә. Ул, наган белән куркытып, Гайшәне таптыра, үзенә бирүне таләп итә.

«Сарут»тагы Мифтах, җаен туры китереп, товар поездына утырып китә, сактагы кызылармиячене имгәтеп, киемнәрен, документын ала. Ләкин аның эш-хәрәкәтләре гадәти мантыйк буенча бармый. Тормыш логикасы буенча йөрсә, ул бу җирләрдән мөмкин кадәр арырак китү, җан саклау, тынычрак урында яраларын дәвалау ягын карар иде. Мифтах исә үзенең дуамал холкы логикасы буенча китә. Анда үч алу тойгысы шулкадәр көчле ки: ул башка бөтен хисләрне, акылны каплап китә, сукыр ачу тойгысы яшь гомерен саклау инстинктыннан да өстенрәк булып чыга. Ул, аягы, кулбашы яраланган булуына, хәтсез кан югалтуына карамастан, вагоннан төшеп кала, приговор җыйган өчен бөтен авылны яндырырга, кара күмергә калдырырга, күзе төшеп йөргән Гөлҗиһанны – авылның беренче чибәрен мәсхәрәләргә ниятли. Күренгәнчә, аның гамәле генә түгел, уй-нияте дә яман була. Күпер төбенә килеп җиткәч, ул әлеге чибәрнең туен бозу чарасына керешә.

Бу әсәрдә бик мәгънәле бер деталь бар. Җирән кашка, Мифтахның җәзалавына, колынны аерып калдыруына түзә алмыйча, чыгымчылый, сикеренә башлый, егет ат сыртыннан егылып төшкәндә, өстәмә явызлыклары өчен, Мифтахны тибеп очыра. Кайбер иптәшләр финалның болай төгәлләнүе белән килешмәделәр. Ничек инде соңгы хөкемне кешеләр түгел, ат чыгара? Ләкин, беренчедән, Мифтахка карата кырыс, каты хөкемне иң әүвәл авыл халкы чыгара. Икенчедән, хайванның сабырлыгы төкәнүе повестьта җиренә җиткереп, бик оста, ышандыргыч сурәтләнгән. Өченчедән, һәм монысы аеруча мөһиме – ат биредә, гомумән, табигатьне гәүдәләндерә, табигатьнең явызлыкка мөнәсәбәтен белдерә. Реаль тормышта да бит, яшәеш кануннарын сакламаган чакта, табигатьнең берәгәйле сүзен әйтүе белән еш очрашабыз. Димәк, биянең явыз кешегә тибеп җибәрүенең тирән генә фәлсәфәи мәгънәсе бар булып чыга. Биредә гүяки кешеләр карары белән табигать мөнәсәбәте арасында тыгыз бәйләнеш төсмерләнә: ат кешеләрнең хөкем карарын гамәлгә ашырып куя. Укучылар хәтерлидер, шундыйрак күренешне без Розалин Маилзның «Эдемга кайту» романында да очратабыз.

Ә.Еники әсәрендә Коръән-хафизның кеше атып үтергәне күренми. Әмма дин әһеленең, рухани зат хозурына килеп җәнҗал куптаруы, кыз сорау, гаилә кору кебек үтә нечкә, четерекле мәсьәләне наган төзәп хәл итәргә тырышуы, йола-тәртип белән исәпләшмәве күп нәрсә турында сөйли. Автор Хафиз хәлфәнең, яңа хакимияткә җайлашып, алга таба аның исеменнән бәндәләргә җәбер-золым кылып йөрү ихтималына басым ясый. Хикәянең ахырында нәтиҗә рәвешендә бик хикмәтле сүзләр теркәлгән:

«Кем булып чыкты бу кансыз, икейөзле кеше, кая кадәр барыр ул, язмышын кайларда, ничек итеп очлар икән, дип, гел баш вата идек. Әгәр кызыллар үзләре аның кем икәнлеген сизеп, башын чапмасалар, ул, бертөрле кыяфәткә кереп, әллә нинди явызлыклар эшләп бетерер! Бик хәтәр кеше». Күрәсез, гаять җитди, еракларга төбәлгән кисәтү бу. Әсәр гүяки алга таба киң күләмдә таралачак террор, репрессияләрнең тәүге шытымнарын, яралгыларын чагылдыра, беренче аккордларын яңгырата.

Хәятнең җанны бимазалый торган якларына күз текәп карау, шуларга җәмәгатьчелекнең дикъкатен юнәлтү Ә.Еники иҗаты өчен гадәти хәл. Ягъни «Коръәнхафиз»да әдипнең күпчелек әсәрләренә хас булган, зирәклек һәм кыюлык үрелешеннән туган күркәм сыйфат дәвам итә.

Беренче карашка «Сарут» Г.Бәширов стиленнән беркадәр аерылыбрак тора кебек. Күпчелек әсәрләрендә әдип хәятнең уңай якларын, шуларның матурлыгын-гүзәллеген чагылдыра килде. Биредә исә яман холыклы башкисәр сурәтләнә. Әмма асыл хасияте белән «Сарут» та Г.Бәширов иҗатының төп юнәлешендә урын ала. Бу әдип кешенең нindилеген әхлак сыйфатларына карап бәяләргә ярата иде. «И язмыш, язмыш» (1986) повестенда өлкән яшьтәге гади авыл карчыгы совет учреждениесендә эшләүче коммунист улына болай ди: «Бу яңа тормышта шарт-шорт мылтык шартлатулар озакка бармас. Киләчәктә гомер итәргә вөгъдә, ант, мәхәббәт, намус шикелле нәмәстәкәйләр дә кирәк булып чыгар». Автор Мифтахта яшәешнең нигезен тәшкил иткән кадерле рухи-әхлакый кагыйдәләрдән тайпылу, читләшүне күрә, аны әнә шундый затлы сыйфатлардан мәхрүм булганы өчен тәнкыйтьли, язмышының үкенечле төгәлләнүен чагылдыра.

Күрәсез, ике әсәрдә дә кызыл гаскәриләр тискәре геройлар итеп тасвирланалар. Алар икесе дә иҗтимагый вазгыятьне, илдәге буталыш-чуалышларны шәхси үч алу өчен файдаланалар, кешелек сыйфатлары җуелганлыгын үзләре үк фаш итәләр.

Шул ук вакытта «Коръән-хафиз»да, байтак әсәрләрдән үзгә буларак, автор Искәндәр ахунны каралтып күрсәтердәй бер генә штрих та кулланмый. Әсәрдә ул ихтирамга лаеклы рухани зат буларак күз алдына килеп баса.

Димәк, әсәрләрдә инсанның дәрәҗәсе, ул еллардагыча, кайсы якта көрәшүе белән үлчәнми, ә бәлки, аның асыл сыйфаты, холкы белән, әхлак кануннарына, гореф-гадәтләргә, йолаларга мөнәсәбәте белән бәяләнә.

Әлеге әсәрләр бу хасиятләре ягыннан социалистик реализм күрсәтмәләре белән бик үк ярашып та бетмиләр иде. Асылда исә алар ил гаме турында, кешеләрнең рухи-әхлакый сафлыгы хакында кайгырту, дөньяга җитди караш җирлегендә иҗат ителгәннәр.

Редакциядән: *мөхтәрәм авторыбыз Фәрит Миргалим улы Хатиповка 1 нче гыйнварда 90 яшь тулды. Аны гомер бәйрәме – юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, гыйльми-иҗади уңышлар һәм табышлар теләп калабыз!* ■

ХӘСӘН ТУФАН
(1900-1981)
Гомәр Бәширов көндәлегеннән[1]

Хәсән Туфан. 1960-1970 нче еллар

Бүген Аккош күленнән кайттык, хәзер инде кышны шушы тузанлы, шау-шулы шәһәрдә уздырырга туры киләчәк. Бүген Аккош күлендә һава шулкадәр яхшы, шундый җылы, шундый сөйкемле иде, аннан һич кузгаласы килми башлады. Ләкин нишләмәк кирәк? Кышны анда уздырып булмый лабаса!

[1] Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кулъязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – Б.464.

Хәсән Туфан Татарстан телевидениесендә. 1962 ел

Кайткач та Хәсәнгә чылтыраттым. Озакламыйча Уфада Мостайның 60 еллыгы узарга тиеш. Хәсәнне шунда кунак итеп чакырганнар иде. Ул анда барырга риза, берникадәр хәзерләнә дә башлаган иде шикелле. Беренче сорауда үземә дә әйтте: юбилей үзе бик зур вакыйга, миңа анда булырга кирәк. Шул сылтау белән мин анда бик күп сандагы дус-ишләрне, мәсәлән, Сәйфи Кудашны һ.б.ны күрәчәкмен. Ул миңа җан азыгы бирәчәк, дигән иде. Әмма бүген хәлне, Уфага бару-бармавын сораша башлаган идем, аның җавабы мине хәйран калдырды, хәтта уңайсыз бер хәлгә куйды. Хәсән: «Уфага барасыңмы?» – дигәч, миңа болай җавап бирде: «Мин, бик озак уйлаганнан соң, бармаска булдым. Минемчә, син – безнең әдәбиятыбызның олы кешесе. Әгәр мин сине калдырып үзем генә китсәм, бу яхшы булмас иде...»

Мин моны хәзергә берничек тә аңлый алмыйм әле.

1979, 14 октябрь

Кичә көндез сәгать 10нарда Хәсән Туфанның аяклары йөрми башлаган иде. Ул, аягына торып баскач, егылып киткән. Соңыннан ничек булуын сорагач: «Мин аякларымны бөтенләй сизми башладым», – диде. Аннан соң менә беркадәр вакыт узды, аның хәле тагын да начарланды. Бүген көндез мин барганда, ул инде үз аягы белән бөтенләй йөри алмый иде. Минем белән сөйләшкәндә дә бик авыр тәэсир калдырды. Кайбер сүзләрне аңламыйммы, ничекме, әмма җавап бирми, бик кыенлык белән генә телен әйләндерә иде. Иң кызыксынган мәсьәләсе – Мостай Кәримнең кичәсе ничек узуы булды. Мин мөмкин булган кадәр тәфсиллерәк итеп сөйләп бирдем. Кемнәр катнашуын әйттем, халыкның канәгать булып калуы да телгә алынды. Әмма байтак утырып инде китәргә вакыт җиткәч, ул миннән яңадан: «Мостай кичәсе ничек узды?» – дип сорады. Менә шундый хәлләр.

Бүген Хәсәнне шифаханәгә салдык.

1979, 16 октябрь

Кичә шифаханәдә Хәсән янында булдым. Аңа үзенә бер палата биреп, башка кешеләрне аннан чыгарганнар. Дәвалау шартлары яхшы. Мөнҗия аны бик тәрбияли. Ул яклары яхшы.

Әмма сәламәтлеге ягына килгәндә, бик борчылырлык әле. Аяклары хәзергә йөрми,

әллә ни кузгала да алмый. Сөйләшүгә дә бик саран. Өченчекөн барганда тагын да начаррак иде. Ул вакытта бөтенләй диярлек сөйләшә алмый иде. Бүген алай ук түгел, бераз уңайрак. Акрынлап булса да сорауларга җавап бирә. Сорауны ишеткәч тә түгел, бәлки бераз уйлаганнан соң гына җавап бирә.

Мин аны берникадәр үземнең хәлләрем белән таныштырдым. Үземнең 20 ноябрьдә Иҗат йортына китәргә тиешлегемне әйтеп, аңа кадәр тазарырга тырышуын теләвемне әйттем. Шунда киткәнче, туган көнне уздырырга телибез, дидем. (Әлеге дүрт иптәш: Хәмит Ярми, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан һәм мин. Байтак еллардан бирле бу дүрт иптәш туган көннәребездә бер-беребезгә барып тәбрик итәбез, күчтәнәчләр алып барган булабыз.) Ул боларны елмаеп кына тыңлап ятты. Минем «Каш ясыйм... дип» дигән мәкалә искә алынгач, аңа Хәким Сәлимҗановны очратуымны, аның шундый хәл сөйләвен әйттем. Кәрим Тинчуринның 80 еллыгын уздырганда, кичерәк кенә банкет булган. Шунда җитәкчелек итүче: «Хәзер сүзне Кәрим абзыйның тормыш иптәше Заһидә ханымга бирәбез», – дигәч, Заһидә ханым: «Мин Кәрим Тинчуринның тормыш иптәше булмадым, мин аның хатыны идем», – дигән, аңа бик яратып кул чапканнар. Шуны сөйләгәндә, Хәсән бик рәхәтләнеп көлде. Мин исә шуңа шатланып утырдым.

Аннан соң, аның 80 еллыгы якынлашу уңае белән, Татарстан китап нәшриятында китабын чыгару мәсьәләсен кайгыртып, үзе шифаханәдән чыкканны көтеп тормыйча, кемгә дә булса тапшырып, китапны хәзерли башларга кирәклекне әйттем. Ул моңа башта берни дә җавап бирмәде. Мин китәр алдыннан бу, шыпыртлап кына: «Сине шатландыра торган сүзем бар», – диде. «Хәзер үк әйтәсеңме?» – дидем. «Хәзер әйтәм», – ди. Ул бик акрын сөйләгәнлектән, Мөнҗия белән, янына ук барып, сүзенә колак салдык. Нәрсә диде? «Мин элек язып та, китапка кермәгән шигырьләремне яңадан карап чыктым. Алар арасыннан китапка кертергә яраклы дигәннәренә, әһәмиятле дип тапканнарына # билгесе куйдым. Владимир Ильич эшләгән вакытта иң әһәмиятле дип санаган кәгазьләренә шундый билге куя торган булган. Минем китапны оештырганда төзүче шуңа карап мәсьәләне хәл итәр». Бу сүзләрне ул акрын-акрын гына, берәмләп кенә әйтте. Без – аны ишеткән кешеләр моның әһәмиятен, җитдилеген аңларга тиеш идек. Аңладык та кебек.

Хәсәнгә 80 яшь. 1980 елның 9 декабрендә тула. Аның ул хакта үзенең берни дә әйткәне юк. Әмма ул әйтүнең кирәге дә юк. Чөнки ул, безнең чор шигърияттен тудыручылар, башлап җибәрүчеләрнең иң өлкәне, иң хөрмәтлесе буларак, зур ихтирамга лаеклы кеше. Аның 80 еллыгы зур тантанага, культура бәйрәменә әверелергә тиеш.

Исән-сау гына була күрсен.

1979, 22 октябрь

Хәсән Туфан янында булдым. Мин кергәндә, ул, йокымсырап, стенага таба карап ята иде. Сәлам бирдем, исәнлек-саулык сораштым. «Хәлләр ничек? Эшләр кая таба бара?» – дидем. Ул: «Хәлләр өйгә кайтуга таба бара», – диде, бераз елмайды. Әмма мин Союздагы, үземдәге хәлләрне сөйли башлагач, аларга һич игътибар итмәгән кебек күренде. Кичә алынган «Кичке Казан» газетасын караштырырга керешә. Күзлек кимәгән килеш газетаның беренче битен карый, әмма укымый иде. Мин дә аңа игътибар иткәч, газетадагы янәшә торган ике ханымның берсен күрсәтеп: «Берсе – безнең кеше», – диде. Әмма мин сөйләгәннәргә игътибар итмәде.

Хәзер аны утыртып ашаталар. Ул аякларын карават кырыеннан кушырып салындырып утыра ала, әмма шуннан артыкка аның хәле җитми әле. Саубуллашканда миңа кулын бирде. Кулы нык иде. «Һи, болай булгач, эшләр шәп бара, син озакламый тазарасың», – дидем.

1979, 27 октябрь

Хәсән бу арада бераз аягына баса башлады. Аны, җитәкләп, коридорга алып чыгалар, бераз йөртәләр. Ул һәйбәт кенә сөйләшә дә башлады. Шулай итеп, тазаруга таба бара, дип әйтергә мөмкин.

1979, 7 ноябрь

Хәсән янында шифаханәдә булдым. Кәефе яхшырып килә. Акрын гына йөри дә башлаган. Ләкин әле саклауларын үзенә артык сиздермичә генә, янында, егылып китмәсен, дип карап йөриләр икән.

Мин барып кергәч, йөзе яктырып китте. Ул бит инде айдан артык ятып тәмам ирегеп беткән, шифаханәдән күптән чыгасы килә башлаган. Мөнҗия шушы арада Хәсәннең хәлен белергә килүчеләр хакында сүз кузгатты да, фәлән кеше дә килде, диде.

– Мин ул кешене кем дип атаган идем әле? – диде Хәсән.

– «Талейран» дип.

– Әһә, менә шул килде инде, – ди, үзе елмая. – Шундый матур сөйли, шундый сайрый, әйтерсең, ул сине майлап кына куя, сүзләре белән эретеп җибәрә. Ә сүзендә хакыйкатьнең уннан бере дә юк.

– Болай булгач, тазардың инде син, Хәсән! – дидем. Чыннан да, ул элекке көннәргә караганда, ачыграк чырайлы да, теләбрәк тә сөйләшә, гомумән, күңеле күтәренкерәк күренә иде.

– Моннан туп-туры Аккош күленә китәм. Бик сагындым. Песнәкләрем, чәчәкләрем... – ди.

Мин, Аккош күле юлында боз, йөрүләр бик кыен икәнлеген әйтеп, көч-хәл белән генә бераз тынычландырдым. Никадәр авырган булса да, холкы шул ук. Шул ук чуар йөрәк, шул ук берни белән дә исәпләшми торган үзсүзлелек. Ничек кенә булмасын, тазарып килә инде, шөкер.

(«Талейран» дип атаган кешесе өлкә комитетында эшләүче Мөдәррис Мусин иде[2].

1979, 19 ноябрь[3])

Бүген Хәсән өенә кайтты. Әле генә сөйләштем. Күңеле көр, кәефе күтәренке. Шәт, тазаруы шулдыр инде.

1979, 18 ноябрь

Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур дусларымның вафат булуларына берсенә – бер ел, икенчесенә ике ел тулып килә. <...>

Хәсән Туфан авырганда, ике-өч көндә бер мин аның янына кергәләп йөрдем, һәр күреп кайткан саен шушындый дәфтәргә тәэссоратны язып куя идем. Әмма: «Авырая башлагач ук миңа хәбәр итегез», – дип Мөнҗиягә әйтеп куйган булсам да, вафаты вакытында янында була алмадым, бер сәгать соң гына барып җиттем.

Хәсәннең соңгы көннәре турында, минем үтенүем буенча, аның абыйсының кызы Гамбәр сөйләп бирде:

– Мин үзем Пермь шәһәрендә яшәсәм дә, Хәсән абый авырый башлагач, Мөнҗия апага аны карарга ярдәм итәрмен, дип, Казанга килдем. Эш зурга китте. Иремнең мине җибәрәсе килмәде, безнең үз тормышыбыз бар, үзебезчә яшик, диде. Мин туганнарымны андый кыен хәлдә калдырырга теләмәдем. Иремнән аерылырга туры килсә дә, Казанга килдем.

Хәсән абый апрельдә үк каты авырый башлаган иде. Врач Кандалина Валентина Гавриловна аңа шифаханәгә керергә әйткәч, ул, авыр сулап: «Бу авыру әҗәлемә тигәндер инде», – диде.

---

[2] 1969-1984 елларда КПССның Татарстан өлкә комитетында мәдәният бүлеген җитәкли.

[3] Хронологиягә карасаң, Гомәр Бәширов җәя эчендәге өлешне генә 19 ноябрьдә өстәп куйганга охшый. Ихтимал, башка өлешен иртәрәк язгандыр. – Редакция.

Аны спецбольницада 7 нче палатага салдылар. Ул өч кешелек иде. Сезнең югары оешмалар белән сөйләшүегез нәтиҗәсендә, тора-бара палатада үзен генә калдырдылар. Аны һәрдаим карап торырга кирәк булды, чөнки ул тора-бара йөри алмый башлады. Мөнҗия апа көндез карый, мин кич аның янында куна идем.

Бервакыт мин аңа кызы Гуляны чакырырга ярармы икән, дип киңәш иттем. Хәсән абый, башын селкеп:

– Кирәкми, аны холкым күтәрми, килмәсен, – диде.

Шулай да хәле кыенлаша башлагач, без Гуляны, көч-хәл белән булса да, бер кичкә чакырдык. Әмма ул килгән дә төнлә ятып йоклаган. Иртән бик иртә Мөнҗия апага чылтыратты.

– Килегез тизрәк, мин бүтән түзә алмыйм, ул минем белән сөйләшми, – диде. Кызы шуннан соң үлгәч кенә килде.

Ни сәбәпле кызы белән аралары бозык булды? Чөнки Гуля аның квартирын үзенә алып калды, аның шагыйрь булуын танымады, ул аңа: «Синең каля-маляң нәрсәгә ярый?!» – дигән. Ул кыз Хәсән абыйның иң авырткан җире булды.

Мин тагы кунарга калгач, беркөнне карасам, Хәсән абый, яткан җиреннән бармак очларын бер-беренә бәреп, авыз эченнән нәрсәдер көйләп ята. Мин «саташмыймы икән?» дип, аны сөйләштереп карадым. Хәсән абый, башы белән тышка ишарә итеп: «Әнә, матәм маршы уйныйлар», – диде. «Нәрсә соң ул син әйткән?» – дидем. «Траурный марш...» – диде.

Ул аның саташуы түгел, аңлап шулай әйтә иде ул. Мин тышка колак салсам да, бернинди музыка тавышы да ишетмәдем. Ә ул музыка тактына шулай бармакларын бармакларына бәреп ята.

Без аны үзен генә калдырмый башладык. Ник дигәндә, аның аякларының хәле юк, ул аякларына басып тора алмый иде. Әйе, дөрес, баргач аның белән сөйләшеп утырганда, мин аны юатырга теләп:

– Беразга түз инде, Хәсән абый, менә бераз ныгый төш, аякларыңа да хәл керсен, Аккош күленә шуннан соң барырбыз, – дидем.

Ул көрсенеп куйды, аякларын кыймылдаткалады.

– Ай-һай, бу аяклар белән ничек барырмын икән? – диде. Гамбәр дәвам итте:

– Ул Аккош күлендәге бакчасын бик сагынып яшәде. Больницага кереп бераз гына яткач, иртә белән бер өйгә чылтыратты. «Әйдә, килегез, мине моннан алыгыз, мин мондый матур язгы айларда биредә ята алмыйм», – диде. Мөнҗия баргач, ул аны тагын да ныграк кыса башлаган. «Калмыйм, барабыз! Әйдә, киттек».

Мөнҗия апа, аптырагач, Сезгә чылтыратты...

Әйе, Мөнҗия минем Хәсән белән сөйләшүемне үтенде. Мин аны бу көннәрдә бармаска күндердем. Врачлар да барып йөрмәскә киңәш биргәннәр. Әмма ул хәл, ягъни Хәсәннең Аккош күлендәге бакчасын күреп кайтмыйча вафат булуы, үкенечле булып калды.

Тагын Гамбәр сөйли:

– Аккош күлен теленнән төшерми башлагач, мин, дачага барып, аннан чәчәкләр бәйләме алып кайттым да, күренерлек итеп, Хәсән абыйның аяк очына куйдым. Ул чәчәкләрне озаклап иснәде, матурлыгына сокланды. Шунда иртә өлгерә торган бер гөл бар иде. Хәсән абый бермәлне иреннәрен кыймылдатып нәрсәдер исенә төшерергә тырыша башлады. Мин аннан сорадым: «Хәсән абый, берәр нәрсә кирәкме әллә?» – дип. Ул әйтә: «Менә бу чәчәкнең исеме юк, ә үзе бик матур. Ул «тургай чәчәк» булсын. Чөнки бу гөл тургай килгән вакытта чәчәк ата», – диде.

Ун көн ятканнан соң, мин Хәсән янына икенчеме, өченчеме мәртәбә бардым. Ул йокымсырап ята иде. Исәнләштем, янына утырып хәлен белештем. Ул, гадәтенчә:

– Ярый әле... – диде.

Мин аның бу җавабының мәгънәсен беләм инде. Ул – хәлен сораучыны борчымас өчен генә әйтелә торган сүз. Хәсән, никадәр авыр булса да, дөресен әйтмәячәк. Хәсәнне азрак сөйләштерәсем килеп, мин аңа Аккош күлендә аның ояларына сыерчыклар килүе, аларның бала чыгарулары турында сөйләдем. Шулай да, Хәсәннең күңелен кузгатмас өчен, Аккош күлендәге җәйге матурлыкларны бик кабатларга ярамый, өстән-өстән генә кагылып узарга кирәк иде. Мин аны нигәдер сөйләштерә алмадым. Хәсәннең беләген тотып, пульсын санадым. 70 чамасы иде. Аның хакында Мансур Хәсәнов белән сөйләшүемне әйттем, аны бу палатада ялгызын гына калдырырга тиеш иделәр. Хәсән бераз гына башын селкетеп куйды. Әмма теле белән берни дә әйтмәде. Ул мин сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлап ята, әмма җавап бирми иде.

Биш-алты минут чамасы шулай янында утырып та сөйләштерә алмагач, минем күңелемә шик төште, бәлки, авыруы бик көчәйгәндер, аңа ялгыз калырга кирәктер, дип уйладым да, хушлашып, китеп бардым. Әмма Хәсәннең шундый хәлдә калуы миңа бик авыр тәэсир итте.

Бу хакта Гамбәр болай ди:

– Сез чыгып киткәннән соң, мин Хәсән абыйдан шул хакта сораштым. «Хәсән абый, нишләптер, син Гомәр абый белән сөйләшмәдең. Ул бит сине якын дусты итеп, яратып килгән, хәлеңне белергә дип килгән», – дидем. Хәсән абый әйтә: «Әй мин Гомәр белән сүзсез генә сөйләштем. Ул минем йөземнән, күзләремнән нәрсә әйтергә теләвемне – һәммәсен дә аңлады. Без аның белән сүзсез дә күңелләребездә ни булганны аңлаштык», – диде.

Врач Калерия Николаевна Хәсәнне аз-маз гына булса да йөртергә кушкан. Юкса, аяклары оешыр, язылмый башлар, дигән.

Гамбәр белән Калерия Николаевна Хәсәнне, җитәкләп, тәрәзә янына алып барганнар. Тәрәзәдән бакчадагы яшеллек бик яхшы күренә икән. Хәсән бераз гына карап торган да, аны кире койкасына китереп салганнар. Гамбәр аннан: «Хәсән абый, син яшеллекне бик яратасың, нигә азрак карап тормадың?» – дип сораган. Хәсән аңа: «Матур булса да, Аккош күлендәге бакча түгел шул ул», – дигән.

Гамбәр сөйли:

– Хәсән абыйның хәле көннән-көн начарлана барды, без аны инде ялгыз калдырмый башладык. Әмма беркөнне, без азга гына китеп торган арада, ул бәдрәфкә чыккан да хәле бетеп егылган, бик озак тора алмыйча салкын идәндә яткан. «Ишеккә ябышып карыйм, әмма күтәрелергә хәлем юк», – дип сөйләде үзе. Күпмедер ятканнан соң, аны күтәреп алып кергәннәр. Әмма шуннан соң аның хәле гел начарлана барды. Без аның яныннан китмәдек, яткан җиреннән кузгатмаска тырыштык. Төнлә белән шулай да ул, үз аягы белән чыгып керәсе килеп, шыпырт кына урыныннан тора иде. Саклык өчен аның караватындагы одеалны аягыма тоташтырып, киенгән килеш кенә күрше караватка ятып тордым. Күземне йомып күпме генә черем иткәнмендер, колагыма: «Гамбәр!» – дип дәшәләр кебек ишетелде. Сискәнеп торып бассам, торуым бик вакытлы булган: Хәсән абый яланаяк идәнгә төшеп маташа. «Минем йөреп карыйсым килә!» – диде. Ләкин мин җитәкләп карасам да, ул берничә адым да атлый алмады.

10 июнь көнне ул бик борчыла башлады. Аның хәле чыннан да яхшы түгел, аның бәвеле китми башлаган, ә ул ярдәмче аппаратны йолкып алып ташлый иде. Иртә белән уянып торгач, мин аның битләрен юдырдым, мендәргә сөяп утырттым да тамагын туйдырдым. Аннан соң яткырдым. Әмма ул бик борчыла башлады. Ул, никадәр сорашып карасам да, авырган җирен әйтми иде. Хәле мөшкел, Мөнҗия апа һаман килеп җитми, мин нишләргә белмим. «Хәсән абый, Мөнҗия апа килсен, беразга түз инде», – дидем.

Ул минем ни әйтергә теләвемне аңлады. «Ярар, Мөнҗия килгәнче генә...» – диде.

Мин хәйран калдым. Шул актык чиккә барып җиткәндә дә, аның үз акылы үзендә, ул үзен тота белә иде.

Мөнҗия апага чылтыратып, тизрәк килеп җитүен үтендем. Ул килгәч, Хәсән абый, берникадәр тынычлап киткәндәй булып, сузылып ятты. Ул арада Калерия Николаевна да, сестралар да кереп җитте. Хәсән абый йомылган күзләрен бик кыенлык белән генә ачып, караваты тирәсенә җыелган кешеләргә һәммәсенә берәм-берәм күз салып чыкты. Тагын күзләре йомылды, тагын күзен көч-хәл белән генә ачып бер карады да тынып калды. Бер «әһ» иткән тавыш та чыкмады, акрын-акрын сүнә барды. Шулай үлеп тә китте.

Аның болай тавышсыз-тынсыз сүнеп китүенә хәтта врач Калерия Николаевна да хәйран калды.

– Ничек тыныч яшәсә, шундый ук тыныч үлем белән үлеп тә китте. Искиткеч тыныч үлем бу, аның үзенә лаеклы үлем, – диде.

Хәсән абый 1981 елның 10 июнендә 10 сәгать 30 минутта өзелде.

Ул көнне мин Аккош күлендә идем. Иртә белән Зөфәр килеп кергәч, имәнеп киттем. Җитди сәбәп булмаганда, эш вакытында килеп йөрми инде ул. Шулай булып чыкты да: аңа Мөнҗия Хәсән абыйның хәле авыр, дип хәбәр иткән.

Мин палатага барып кергәндә, Хәсән янында сеңлесе Сәгыйдә генә иде. Хәсән, йоклаган кебек, тыныч кына койкасында ята, йөзендә һичбер үзгәреш юк. Маңгаена кулымны куйдым, суынып та җитмәгән иде әле. Күзләремә яшь тулды, моннан элек килгәндә дә: «Бу аяклар белән ничек Аккош күленә барырмын икән?» – дигән иде. Менә бит, Аккош күленә барасы урынына Яңа бистәгә китәргә язган икән, анда да үз аягың белән түгел.

Бер баруымда Хәсән сеңелләренә, миннән соң менә шушы абыегызга сыенырсыз инде, дигән иде. Алар тирәсендә ир затыннан берәү дә юк, күмү мәсьәләсен Союздагы кешеләр белән миңа кайгыртырга кирәк иде.

Рәис Гариф Ахунов белән, кабергә урын сайлар өчен, Яңа бистә зиратына киттек. Хәсәнгә үзенең дәрәҗәсенә лаек урын сайларга кирәк иде, әмма андый урын башта күренмәде. Безне каядыр агачлар арасына алып кереп, тар гына бер урынны күрсәттеләр. Ул урынны ошатмадык. Капкадан кереп бераз баргач та, аллеяның уң ягында калку урын күзгә чалынды. Ләкин зират конторасының мөдире ул урынга күмәргә рөхсәтне шәһәр Советының зур түрәсе бирүен, аның министрларга дип саклануын әйтте. Шул вакытта Гариф Ахунов үзенең егетлеген күрсәтеп алды.

– Кем ул министр? Кирәге бетә икән, аны артына тибеп урынынннан төртәләр дә төшерәләр. Ә Хәсән Туфан – мәңге халык күңелендә яшәячәк кеше. Менә шушы урынга күмәбез! – диде.

Шулай итеп, Хәсән Туфанның мәңгелек квартиры яхшы урыннан сайлап алынды.

Ул көнне Хәсән үз өендә кунды, икенче көнне яшь язучылар белән без аны Татар академия театры фойесына куйдык. Митингта Г.Ахунов, М.Хәсәнов, С.Хәким, тагын кемнәрдер сөйләде. Зиратта халык ул кадәр күп түгел иде. Моңа минем йөрәгем әрнеде. Һади Такташны, Салих Сәйдәшне күмгәндә, күмү мәрасименә катнашкан халык санын меңнәр белән саныйлар. Ә монда, күп булса, берәр йөз булгандыр. Хәзер халык андыйларга торган саен азрак катнаша. Хәсәннең дәрәҗәсе теге өстә әйтелгән талантлардан ким булудан түгел, халык аның шигъриятен ярата, үзен ихтирам итә. Әмма соңгы елларда халыкта ваемсызлык, битарафлык чире көчәйде. Монда да шул сиздерде.

1982, 3 июнь

Хәсән Туфан миңа үз тормышыннан төрле вакыйгалар сөйләгән иде. Шуларны ниндидер формада язып чыгарга кирәк. Әгәр, мәсәлән, кечкенә новеллалар рәвешенә китерсәм? Аяныч ягы шунда ки, аларның, ягъни ул сөйләгәннәрнең күбесе матбугатка чыгардай түгелләр, аның атарга хөкем ителүенә һәм аннан соң Себергә сөргенгә җибәрелүенә бәйләнешле вакыйгалар. Шулай да, бәлки, аларны башка фонга күчереп булса да язып карарга кирәк әле. Мәсәлән, мондый вакыйгаларны язып булыр иде:

1. Көтүче булып йөргәндә эт баласының аңа ничек хезмәт итүе турында.

2. Атылырга хөкем ителеп, караңгы камерага кергәндә аны нинди юмор белән каршы алулары.

3. Телевидениедән кырау төшүе турында хәбәр ишеткәч, Аккош күленә килеп, чәчәкләрнең өстен ничек ябып китүләре һ.б.

1983, 17 август

Кичә Маяковскийдагы элекке квартирыма, улым янына барган идем. Шуннан чыгып килешли чүплектәге кәгазьләргә күзем төште. Карасам, «Казан утлары»ның 1967 ел, 8 нче (август) саны күземә чалынды. Бу бит бик сәер хәл! Ничек инде ул шунча еллар кайдадыр саклаган журнал хәзер генә кирәксезгә чыккан да чүплек башына ташланган? Пычракта яткан журналны читеннән генә тотып ачып карасам, хәйран калдым. Журналдагы кайбер әсәрләрдә, бигрәк тә шигырьләрдә Хәсән Туфанның яшел кара белән язган битләре, әсәргә биргән бәяләре бар. Минем «Туган ягым – яшел бишек»не укыганда аның да кырыйларына үзенең фикерен язып куйган.

Нинди хурлыклы хәл бу? Гаҗәпләнеп сораша башласам, шундый оялырлык хәл мәгълүм булды. Бу йортта Хәсән Туфан да яшәгән иде. Үзе икенче фатирга күчкәннән соң, аның бу йортта архивының бер өлеше калган. Шунда яшәүче кызы Гуля (тулы исемен белмим)[4] ул архивны, бер кешегә дә, хәтта Мирас комиссиясенә дә күрсәтмичә, үзенә алып калды. Союз рәисе Туфан Миңнуллинга архивны үзе сакларга вәгъдә итеп, бүтән беркемгә дә, хәтта Әдәбият музеена да бирмәячәген белдерде.

Ә менә хәзер күренде инде, ул атасының мирасын, башка варисларына бирмәс өчен, юри, үч итеп кенә алып калган икән. Аңа атасының мирасы кадерле түгел, чөнки ул үз телендә бер сүз дә белми, атасының иҗаты белән таныш түгел. Нигилистка, киртә сикергән кеше. Атасын ул исән чагында ук шагыйрь дип танымый, ихтирам итми иде. Бервакыт Хәсән Туфан безгә кунакка килгәч, оныгын күрәсе килеп, элекке квартирына кергән иде. Ләкин ул аннан, бик күңелсезләнеп, тиз арада кире чыкты. Ул вакытта мин моның сәбәбен сорарга уңайсызланган идем. Бераз вакыттан соң, урамда йөргәндә, кызының үзен санламавыннан, әти дип карамавыннан зарланып, Хәсән үзе әйтте. Оныгы Тимурны[5] күрү нияте белән кергәч, кызы аңа: «Балама грипп йоктырасың», – дип, ишек яныннан борып чыгарган.

Менә шундый хәлләр. Хәсәннең тормышында җәмәгатьчелек белмәгән әнә шундый фаҗигаләр дә бар иде. Әле бу гына да түгел.

Хәсән кызы Гуля, атасы кулга алынганнан соң, анасы Салиәскәрова[6] һәм апасы кулында русча гына тәрбияләнгән, ул атасы телендә бер сүз дә белми иде. Шул сәбәпле, аны гаепләү дә кыен. Әмма ул атасына бик мәрхәмәтсез булды, аның әйберләрен (өстәлләрен) коридорга чыгарып ташлады, аның телен каля-маля дип мыскыл итте. Коточкыч хәл. Ул яктан Хәсән, бичара, бик бәхетсез иде. Бу хәлләрне ул бик авыр кичерде.

1987, 1 октябрь

---

[4] Гөлгенә.

[5] Истәлекләр азагында, йомгаклау рәвешендә, Хәсән Туфанның шушы оныгына багышлаган шигырен тәкъдим итәбез. – *Редакция.*

[6] Луиза (Гайникамал) Галим кызы Салиәскәрова (1907-1955).



Ак шагыйрь безнең белән хушлаша...

ХӘСӘН ТУФАН

***

Гасыр үтәр, бәлки, чорлар үтәр,
Син дә бергә үтә барырсың.
Уяныр да, бәлки, нәсел хисе,
Сискәнеп бер уйга калырсың.

Барлык милләт күптән күчкән булыр
Җирнең олы, көчле теленә.
Кайберсенең әле исеме калган,
Кайберсеннән – берәр көй генә.

Меңләп телдә киңәшсә дә алар
Яңа чорга кергән чагында,
Тик бер телле телгә әверелгәннәр
Сыйфат санга күчкән чагында.

Өч мең елдан соң да
Телен тапкан,
Үз теленә кайткан илләр бар.
Тарихыңның башларына бак та,
Гыйбрәтләр ал – син дә легендар.

Тибәрсә дә, этәрсә дә читкә,
Тарих, бабаларың искә ал:
Китмә, күчмә, бер карыш та чикмә,
Үз Тукаең барган юлда кал!

Ни күрсәң дә,
Берәм-берәм түгел,
Бергә күтәр, бергә чыда син.
Еласаң да әгәр берәр чорда,
Алты миллион, бергә ела син!

Иләс нәфес киңәшләрен түгел,
Җаның-бәгъреӊ әмерен искә ал:
Китмә, купма, бер карыш та күчмә,
Тукай баскан җирдә –
Илдә кал!

Безнең җанда урын юк та инде
Һичбер нинди күккә, Ходайга.
Язмыш дигән нәрсә ил башына
Югарыдан төшә шулай да.

Дәвер – бүтән.
Һәм аның да инде
Бүтәнчәрәк Столыпины:
«Үзең теләп кит син телеңнән», – дип,
«Көчләмичә» кыскалый инде,
Үз теленнән күчерешкән кулны
Тәбрик итеп кыскалый инде.

Метислашып бетсәң дә син әгәр,
Калсаң да тик гибрид кына булып,
Чәчкәсе бул асыл тамырның:
Каралганы – Карамзины[7] түгел,
Каракозовы[8] бул каныңның!

Әдәбият:
Туфан Х.Ф. Әсәрләр: 5 томда [төзүчесе Мәсгуд Гайнетдинов. Том III. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008. – Б.368-369. ■

[7] Николай Михайлович Карамзин (1766-1826) – рус тарихчысы, язучысы.
[8] Дмитрий Владимирович Каракозов (1840-1866) – инкыйлабчы, террорчы. Император Александр IIгә һөҗүм ясаучы буларак мәгълүм.

Ике министр

Әгъзам Фәйзрахманов

Мирза Мәхмүтов (уңда) һәм Владимир Иванов

Рәсемдәге кешеләр республикада яшәүчеләрнең күпчелегенә яхшы таныштыр, дип уйлыйм. Алар икесе дә зур галимнәр, Татарстанның фән, мәгариф, мәдәният тармакларын үстерү буенча җиң сызганып эшләгән шәхесләр – Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов һәм Владимир Васильевич Иванов. Икесе дә төрле елларда Татарстан Республикасының мәгариф министры вазыйфасын башкардылар.

М.Мәхмүтов – көнчыгыш телләре белгече, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен яхшы белә иде. Казан дәүләт университетында белем алганда, ул безгә дә гарәп телен укытты. Мирза Исмәгыйль улы – СССРның Педагогика фәннәре академиясе, Татарстан Фәннәр академиясе һәм Нью-Йорк Фәннәр академиясе әгъзасы. Аның педагогика һәм ислам белгечлеге буенча 500дән артык фәнни хезмәте бар.

Владимир Васильевич исә – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы.

Миңа бу галимнәрнең икесе белән дә даими аралашып яшәргә насыйп булды. Журналист буларак, аларның хезмәтләрен даими пропагандаладым.

В.Иванов ул чорда университетның тарих бүлегендә миннән ике курска гына түбәнрәк укыды. Студент елларында без аның белән газеталарга һәм радиога язмалар әзерли идек. Мәкаләләрне бергәләп язган очраклар да булды, шул исәптән, кайбер радиотапшырулар да уртак хезмәт җимешебез иде. Өстәвенә, өйләнгәндә туемны да ул алып барды.

Яшь аермалары шактый зур (13 ел) булса да, мин бу галимнәрне еш кына бергә очрата идем. Сөйләшәсе сүзләре, хәл итәсе мәсьәләләре аз булмагандыр, күрәсең.

Инде аларның тормыш юлларына да азрак күз салып үтик.

Мирза Мәхмүтов 1926 елның 1 маенда Бакуда туа. Әмма аның яшьлек еллары Мордовиянең Ромодан районындагы Алтары авылында үтә, чөнки гаиләләре шунда күченеп кайта. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Мирза тракторчылар курсында белем ала. Армиягә киткәнче, ул МТСта механизатор булып эшли. Бөек Ватан сугышында разведчик буларак катнаша. 1948 елда Иркутск хәрби авиатехника училищесын, аннары Чит телләр хәрби институтының көнчыгыш факультетын тәмамлый.

Күп кенә көнчыгыш телләрен җентекләп өйрәнгәннән соң, М.Мәхмүтов берничә ел Казан дәүләт университетында гарәп һәм татар телләрен укыта. 1958 елда аны Татарстан АССРның мәгариф министры итеп билгелиләр. М.Мәхмүтовка бу вазыйфаны 18 ел дәвамында башкарырга туры килә. 1976 елда Мирза Исмәгыйль улы яңа җаваплы эшкә күчә – ул СССР Педагогика фәннәре академиясенең Казан шәһәрендәге Профессиональ-техник фәнни-тикшеренү институты директоры итеп билгеләнә. Мирза Исмәгыйль улы биредә 16 ел эшли.

1992 елда ул Татарстан-Америка төбәк институтын оештыра, аның беренче ректоры була. Мирза Исмәгыйль улы анда 1995 елга кадәр, ягъни Татарстан Фәннәр академиясенең социаль-икътисади бүлеге академик секретаре вазыйфасына күчкәнче эшли.

Күренекле галим 2008 елның 26 мартында вафат булды, Казанның татар зиратында җирләнде.

Шунысы гаҗәп: Профессиональ-техник фәнни-тикшеренү институты да, Татарстан-Америка төбәк институты да кыска гомерле булып чыга – алар бер-бер артлы ябыла. Мирза Исмәгыйль улыннан соң бу институтларның эшчәнлеген дәвам итәргә сәләтле кеше табылмый, күрәсең.

М.Мәхмүтов – көнчыгыш телләре һәм лексикология өлкәләрендәге хезмәтләре белән танылган галим. Ул, беренчеләрдән булып, гомуми белем бирү һәм һөнәри училищеларда фәннәрне проблемалы үсештә өйрәтү алымнары теориясен эшләде. Аның 1985 елда дөнья күргән «Современный урок» дигән монографиясе Крупская исемендәге дәрәҗәле премиягә лаек булды. М.Мәхмүтов 9 доктор һәм 36 фән кандидаты әзерләде.

Мирза Мәхмүтов тарихка җәмәгать эшләрендә актив катнашуы белән дә кереп калды. Ул 1959-1980 елларда ТАССР Югары Советы депутаты иде. 1963-1976 елларда ЮНЕСКОның Укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча халыкара консультация комитеты, төрле елларда Бөтендөнья тынычлык комитеты әгъзасы булып торды.

Мирза Исмәгыйль улы Бөтендөнья татар конгрессын оештыручыларның берсе иде, «Ватан» татар иҗтимагый оешмасының ватандашлар белән элемтәләр буенча президенты булды.

1956 елда аңа Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе тапшырылды. Ул Ленин, Октябрь революциясе, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, күп санлы медальләр белән бүләкләнде.

Бүгенге көндә Казан шәһәренең 184 нче мәктәбе Мирза Мәхмүтов исемен йөртә. 2018 елда аның исемендәге республика премиясе дә булдырылды. 100 мең сумлык әлеге премия дидактика, педагогик кадрлар әзерләү өлкәләренә зур өлеш, уку-укыту процессына нәтиҗәле алымнар керткән өчен бирелә. Тәтешнең 1 нче гомуми белем бирү урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Ю.В.Мышев бу дәрәҗәле бүләккә беренче булып лаек булды.

Нинди генә вазыйфалар башкарса да, М.Мәхмүтов һәркайда бөтен көчен биреп, зур җаваплылык тоеп эшләде. Ул министр булганда Татарстан илнең проблемалы укыту буенча полигонына әйләнде. Мирза Исмәгыйль улы укытуның мондый төрен эшләү, сынау, киң кулланышка кертүнең авторы булды. Республикабызга, тәҗрибә туплау өйрәнү өчен, илнең төрле почмакларыннан галимнәр, укытучылар килде. Аның китаплары, монографияләре педагогика фәненең алтын фондына керде.

М.Мәхмүтовтан соң Татарстанның мәгариф министры итеп Владимир Васильевич Иванов билгеләнде. Ул – 1939 елның 12 апрелендә Алексеевск районының Югары Кондрат авылында туган керәшен татары. Владимир Васильевич, 1962 елда Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлагач, матбугатка килде: «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында, радиода эшләде. Казан шәһәренең 80 нче урта мәктәбендә бер ел укытып та алды.

Владимир Васильевич шуннан соң фәнгә кереп чумды: башта кандидатлык, аннары докторлык диссертацияләрен яклады. Түбән һәм Казан педагогика институтларында тарих укытты, Казан дәүләт финанс-икътисад институтында студентларга философия һәм социология буенча лекцияләр укыды, семинарлар алып барды. 1971-1976 елларда ул КПССның Татарстан өлкә комитетында Фән һәм уку йортлары бүлеген җитәкләде. Язып үткәнчә, В.Иванов 1976 елда республика мәгариф министры М.Мәхмүтовны алыштырды.

В.Иванов оста оештыручы һәм сәләтле җитәкче иде. Татарстанда мәгарифне һәм фәнне үстерүдә аның өлеше бик зур. Владимир Васильевич социаль танып белү һәм социаль-рухи тормыш методологиясе актуаль проблемаларын тикшерү юнәлешенә нигез салучы һәм аның җитәкчесе булды. Татарстан Фәннәр академиясенең Социология буенча фәнни советын, СССР социологлар җәмгыятенең Татарстан бүлеген җитәкләде.

В.Иванов тарихи һәм икътисади социологияне торгызуда һәм үстерүдә дә фидакарь хезмәт куйды. Аның инде 1960-1970 елларда ук язылган тарихи социологиянең чагыштырма алымнары турындагы хезмәтләре ил социологиясенең беренче библиографик күрсәткече санала.

Владимир Васильевич Почет Билгесе ордены, күп санлы медальләр белән бүләкләнде, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек булды, берничә тапкыр ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Мирза Мәхмүтов һәм Владимир Иванов кебек олуг галимнәрнең хезмәтләре әле бүген дә актуальлеген югалтмый. ■

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ!

Библиограф Исмәгыйль Рәмиевнең тууына 125 ел

Язучы, әдәбият белгече, библиограф, ерак ата-бабаларының нәсел шәҗәрәсе буенча татарның мәшһүр шагыйрьләре Закир Рәмиев (Дәрдемәнд) һәм Сәгыйть Рәмиевләр белән бер үк кавемнән булган Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиев 1895 елның 1 гыйнварында элекке Уфа губернасының Эстәрлетамак шәһәрендә туган.

Казандагы «Амур» кунакханәсендә конторчы (хисапчы) булып хезмәт иткәндә, ул анда яшәүче яки анда еш килеп йөрүче күп кенә татар язучылары һәм сәнгать кешеләре (Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Кариев, Г.Ибраһимов һ.б.) белән якыннан таныша.

1912-1914 елларда «Сәйяр» театр труппасының суфлеры сыйфатында гастрольләргә йөри. 1915-1917 елларда исә патша армиясендә хезмәт итә.

1922 елда үз наширлеге һәм мөхәррирлегендә «Бабич» исемле юмор-сатира журналы чыгара башлый. Ләкин журналның беренче һәм икенче саннары гына укучылар кулына барып ирешә, өченче һәм дүртенче саннары басылып беткәч тә, Уфа совет хакимияте карары белән җыеп алынып, чыгудан бөтенләй туктый.

1925 елда И.Рәмиев Казанга күчеп килә.

И.Рәмиевнең иҗат мирасында юмор-сатира әсәрләре, хикәяләр, «Кызыл бәдәвам» исемле көйле әсәр (Уфа, 1919), пьесалар («Тәфтиләү», «Кайда, кемнәр бу?» һ.б.), әдәби тәрҗемәләр (С.Кравчинскийның «Яңа көчләр» драмасы, Уфа, 1920; А.Чеховның «Футлярдагы кеше» хикәясе, Казан, 1936 һ.б.), әдәбият һәм матбагачылык, китапчылык тарихына караган күп санлы мәкаләләр, истәлек язмалары, библиографик хезмәтләр бар. Аларның бер өлеше авторның 1965 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Истәлекләр. Татарча басма сүз» исемле җыентыгында урын алган.

Гомеренең соңгы елларында әдип Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты һәм мәдәни хәрәкәте буенча кыскача сүзлек-белешмә төзү өстендә эшләде.

И.Рәмиев 1969 елның 28 декабрендә Казанда вафат булды.

Шагыйрь Шәехзадә Бабичның тууына 125 ел

Шагыйрь Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабич 1895 елның 15 гыйнварында (кайбер чыганакларда – 2 гыйнвар) элекке Уфа губернасының Бөре өязе (хәзерге Башкортстанның Дүртөйле районы) Әсән авылында мулла гаиләсендә туган.

Шәехзадә, уку яшенә җиткәч, авыл мәдрәсәсендә әтисе кул астында белем ала.

1910 елда, казакъ далаларына китеп, Тургай төбәгендәге Дүсәнбай дигән авылда бер ел балалар укыта. Шунда ул казакъ акыннары белән якыннан аралаша, казакъ халык әдәбиятын өйрәнә, үзе дә каләм тибрәтә башлый.

Ш.Бабич 1911 елның көзендә, Уфа шәһәренә килеп, «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Мәдрәсәдә шәкертләр чыгарган «Эләктергеч», «Парлакъ» исемле кулъязма журналларда актив языша. 1913 елда инде аның шигырьләре матбугатта («Акмулла», «Шура» һ.б. журналларда) күренә башлый.

1916 елда «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач, Ш.Бабич бер ел Троицк шәһәрендә мөгаллим булып эшли.

1917 елның җәен ул Уфа шәһәрендә уздыра, аннары «Кармак» исемле көлке журналының чакыруы буенча Оренбургка күчеп, журналның җаваплы сәркатибе булып эшли.

Ш.Бабич үзе исән чагында аның аерым басма рәвешендә нибары бер җыентыгы гына дөнья күрә («Яшь Башкортстан», Оренбург, 1918). Төп поэтик мирасы исә газета-журналларда басылганынча яки кулъязма хәлендә кала килеп, бары 1922 елда гына Г.Ибраһимов аларның бер өлешен җыеп бастыра («Шигырьләр мәҗмугасы», I китап, Казан). Ләкин шагыйрьнең егерменче елларда тупланган гаять бай кулъязма архивының зур өлеше – басылмаган шигырьләре, автобиографик язмалары, көндәлек дәфтәрләре, халык арасында йөргәндә язып алган мәкальләр һәм әкиятләр соңыннан югала.

1919 елның 28 мартында Темәстән Моракка Башревкомның типография җиһазларын күчереп алып барган вакытта, Зилаир авылы тирәсендә Ш.Бабич, дусты, шагыйрь Гәбделхәй Иркәбаев белән бергә, кызыл гаскәриләр тарафыннан җәзалап үтерелә.

Композитор Җәүдәт Фәйзинең тууына 110 ел

Композитор, фольклорчы, ТАССРның (1944) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), ТАССРның халык артисты (1964), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1966) Җәүдәт Харис улы Фәйзи 1910 елның 4 гыйнварында Оренбург шәһәрендә укытучы гаиләсендә туган.

Башлангыч музыкаль белемне Оренбургтагы музыка мәктәбендә ала. 15 яшендә «Яшьләр» драмасын яза.

1925 елда аларның гаиләсе Казанга күчеп килә. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул Түбән Новгород якларындагы Ишә авылында укытучы булып эшли.

1929-1933 елларда Җ.Фәйзи Казан дәүләт университетының юридик факультетында укый. 1934 елда исә, Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе ачылгач, ул студиянең уку бүлеге мөдире итеп җибәрелә.

Җ.Фәйзинең иң беренче җыры – «Урман кызы» (Һ.Такташ шигыре).

Композитор 1938 елда Казанга кайта. Биредә ул музыка һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашып, радиокомитетта музыка редакторы, Татар дәүләт академия театрында музыка бүлеге мөдире, Татарстан филармониясенең директоры һәм сәнгать җитәкчесе булып эшли. Аның «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт), «Шәмсекамәр» (М.Әблиев), «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт) спектакльләренә язган көйләре тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә.

Җ.Фәйзи музыкаль комедия жанрын үстерүдә күп көч куя. Аның «Башмагым» музыкаль комедиясе бик күп сәхнәләрдә уйнала. Композитор «Акчарлаклар» (Ә.Фәйзи либреттосы) һәм «Идел буенда» драмаларына да көйләр язган, Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча опера иҗат иткән.

Җ.Фәйзи 1973 елның 2 маенда Казанда вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Милли музейда – ГАЗ-А АВТОМОБИЛЕ

ГАЗ-А – массакүләм конвейер җыюлы беренче совет җиңел автомобиле. Ул 1932-1936 елларда Горький автомобиль заводында һәм 1933-1935 елларда Мәскәүнең КИМ заводында җитештерелә. 1932 елда Совет хөкүмәте Американың FORD MOTORS компаниясеннән әлеге модельне җитештерүгә документлар һәм җиһазлар сатып ала. Шул ук елның 8 декабрендә беренче ике машина җыела. Завод конвейерыннан барлыгы 41917 машина төшә. 1936 елда конвейерда аны икенче модель – ГАЗ-М1 автомобиле алыштыра.

ГАЗ-А, нигездә, армиядә штаб, санитар яки ведомство автомобиле, шулай ук такси буларак кулланылган. Мондый автомобиль шәхси кулларга бик сирәк кенә эләккән.

Музейга даими саклანышка кергәнче, бу машина озак еллар буе Казан урамнары буйлап йөреп, шәһәрлеләрнең игътибарын җәлеп итә.

1971 елда машина музей бинасына үз йөреше белән килә һәм экспозициядә мәңгелек тукталышка куела. Заманында ул СССРның Авыр сәнәгать халык комиссары Сергей Орджоникидзе тарафыннан Горький автозаводы төзүчесе, якташыбыз А.П.Липинга бүләк ителгән.

Ленар Нәгыймов,
ТР Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

КАМАЛ III

Әхтәм Зарипов

Бу кушаматны Камал Ситдыйк улы Сәләхетдиновка Казаннан 1918 елда Әстерахан театрына күчеп килгән Галиәсгар Камалның өлкән энесе Габдулла Камал куша. Үзен ул Камал I, энесе Габдрахманны Камал II, дисә, яңа оешкан Әстерахан театрында «Сакмарский» псевдонимы белән эшләп йөрүче яшь артист Сәләхетдинов Камал I һәм Камал IIләр арасында Камал III буларак таныла.

«Тукай» (Ә.Фәйзи) спектакленнән күренеш. Сулдан уңга: Каюм Бариев, Камал III, ..., Нәҗип Гайнуллин, Ибраһим Гафуров (?), Хөсәен Уразиков. 1939 ел

Камал III (Камал Ситдыйк улы Сәләхетдинов)

...Яңа оешкан профессиональ театрга, ул чакта куелган пропаганда бурычларын үтәү өчен, тарихи-революцион эчтәлекле әсәрләрне сәхнәләштерү таләп ителә.

Камал III абыйның үзе хәтерләвенчә, заман таләбен канәгатьләндерү максатында, театр үз репертуарына Әхмәт Гомәровның «Көннәрнең көне» дигән драмасын сайлый. Бу әсәрнең каһарманы – 1918 елда фетнәчеләр тарафыннан җәзалап үтерелгән Әстерхан мөселман комиссариатының беренче рәисе Касыйм Туйбактин.

Профессиональ театрга алынганчы, Камал Сәләхетдинов Туйбактин кул астында курьер булып хезмәт иткән. Сәләхетдиновтан «Сакмарский» буларак театрда төп артистлар исемлегенә кертелеп, Камал IIIкә әверелгәч, аңа Туйбактин булып уйнау бурычы куела. Камал III Туйбактинга тышкы кыяфәте белән дә охшарга тырышып, кара мыек үстерә, озын чәчле парик эшләтә, ярым хәрби киемнәр тектерә (Камалның үз әтисе Әхмәтситдыйк бабай – тегүче). Туйбактин кыяфәтле Камал IIIнең сәхнәгә чыгуы зур сенсация була. Халык аны Туйбактин үлмәгән икән, дип кабул итә. Бу факт Камал IIIне артист буларак танытып, аны театрның иң популяр, иң кирәкле артистына әверелдерә, берсеннән икенчесе җаваплырак рольләр

«Мәкер һәм мәхәббәт» (Ф.Шиллер) спектакленнән күренеш. Фердинанд – Камал III. 1950 ел

башкарттыра. Буй-сыны мәһабәтле, тавышы-тембры ягымлы Камал III «Галиябану»да – Хәлил, «Башмагым»да – Галимҗан, «Юлбасарлар»да – Родриго (Шиллер әсәре), «Отелло»да Отелло (Шекспир әсәре) рольләрен уйнап танылгач, аны 1924 елда Казан театрына чакырып алалар.

Артист тормышының һәм иҗатының яңа этабы башлана. (Бу вакытта татар театры әле Академия театры да, Г.Камал исемендә дә түгел. 1926 елда гына театрга Академия дәрәҗәсе бирелә.) «Академия театры» дип аталуга лаек булгач, театр Гогольнең «Ревизор» комедиясен куярга алына. Режиссеры итеп Вахтанговның шәкерте Гомәр Девишев чакырыла. Камал IIIкә Хлестаков роле тапшырыла. Әстерхан театрында куелган «Ревизор» спектаклендә Камал III Добчинский ролен башкарса, татар Академия театрында Хлестаков буларак таныла. Гомәр Девишев трактовкасында Хлестаков булып кыланырга түгел, шулай булып «яшәргә» кирәк була Камал IIIкә. Һәм «яши» ул Хлестаков образында – ышанып һәм ышандырып. Бу мәсьәләдә аңа Әстерхан театрының орденлы артисты, хезмәт батыры исеменә лаек булган тәҗрибәле режиссер Зәйни Солтанов киңәшче һәм терәк була.

Хлестаков образы, Камал III башкаруында буш куык, гротесклы мошенник буларак танылып, артист биографиясендә аның җитлеккән, өлгергән сәхнә остасы булуын дәлилли.

Хлестаков роленнән соң, аңа яңа куелган спектакльләрдә иң җаваплы рольләрне

«Мәкер һәм мәхәббәт» (Ф.Шиллер) спектакленнән күренеш. Леди Мильфорд – Фатыйма Ильская, Фердинанд – Камал III. 1950 ел

ышанып тапшыра башлыйлар. Такташ, Кутуй, Т.Гыйззәт әсәрләре буенча куелган спектакльләрдәге баш рольләрдә Камал III, ә режиссерлары Зәйни Солтанов, Хәким Сәлимҗанов, Хөсәен Уразиков була.

Ватан сугышы башлангач, театр репертуарында хәрби-патриотик эчтәлекле әсәрләр даими урын алалар. (К.Симонов, Б.Лаврентьев, Т.Гыйззәт әсәрләре.)

Милләтнең узган юлын, азатлык өчен көрәшен чагылдырган әсәрләрне сәхнәләштергәндә дә, Камал III – алгы сафта. Шундый спектакльләрдән В.Брагин әсәре буенча режиссер Бебутов куйган «Кайтарылган шәһәр», Хөсәен Уразиков куйган «Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт әсәре буенча) һәм Ширъяздан Сарымсаков куйган «Тукай» спектакльләрен (Әхмәт Фәйзи әсәре) күрсәтергә була. Тукай образы Камал III иҗатында аерым урында тора. Бу спектакль һәм Тукай образы язмам концепциясендә булмаганлыктан, бик кыска гына язып узганда, Камал IIIнең Тукае Тукайдан ерак булып, шагыйрь турында дөрес булмаган (социалист) фикер тудырган. Артист моны үзе дә аңлап, рольне Ибраһим Гафуровка тапшыра. (Бу турыда мин актер Дамир Хәйруллинга багышланган язмамда тәфсилләбрәк яздым. Ибраһим ага Гафуров Тукае да, шагыйрь исемен файдаланып, заман идеологиясенә иллюстрация генә була.) Без – щепкинчыларның диплом спектакле «Тукай»ны карагач, Камал IIIнең әйткән сүзләре хәтердә: «Әсәр кирәк, чын Тукайга, күзе күпне күреп, колагы бөтен дөньяны ишеткән шагыйрьгә тиң образ тудырырга нигез булырлык пьеса кирәк». Камал IIIнең бу сүзләре бүген дә актуаль яңгырый.

Без – щепкинчылар Академия театрына кайтып эшли башлаганда, Камал III инде баш рольләрне башкаручы штатный башкаручыдан спектакльләрдәге икенчел пландагы – ярдәмче рольләргә күчеп барган өлкән актер иде. Һәрхәлдә, үзен шулай тоя һәм шулай тота иде ул. Аласы дәрәҗәләр алынган, хезмәт хакы театрдан алу мөмкин булганның иң югарысы, фатиры әйбәт. Гаиләсе – хатыны да үзе. Балалары юклыкны авыр кичергәнлеген сиздермәскә тырышса да, эти-әниләренә ияреп «эшкә» килгән балаларга игътибарыннан аның күңелендәге хис-тойгыларны аңлап була иде. Кесәсендә балалар өчен дип сакланган карамеле булуын белгәч, качып-посып «өч борынга» кергәннәрне Камал абыйның «кәмфите» коткара иде. Камал IIIнең хәмер белән мавыккан чагын хәтерләмим. Булмагандыр. Бик интеккәндә, «хәмерче»ләрнең аннан акча

алып торуларын күргәнем булды. Бу аның, юмартлыгыннан бигрәк, кеше хәленә керә белүен күрсәтә иде. «Кеше хәленә керү», дигәннән, без – яшьләрнең аның хәленә керү омтылышы ясавыбызны хәтерләп «узу» данлы шәхеснең исеменә тап төшермәс, дип уйлыйм. 1964 елның көзе иде булса кирәк. Ташкент гастрольләреннән кайткач, безне Кайбыч, Апас, Буа якларына «Көзге ачы җилләрдә» спектакле белән гастрольләргә җибәрделәр. Директорыбыз Рәшидә апа Җиһаншинаның мәрхәмәте белән, мин – шул бригаданың бригадир-кассиры. (Азмы-күпме акчасы өчен, бу мәшәкатькә риза булына иде.) Әйе, шулай – 1964 ел. Әле кытлыкның «кырык чакрым китмәгән» чагы.

Артистларны фатирга урнаштыру – минем өстә. Яшь артистлар элекке гастрольләрдәге танышларына урнаштылар, ә Камал абый гостиница сорый. Ул чактагы Кайбыч гостиницасы бер катлы агач йортның яртысын биләп, такта белән бүленгән өч «номер»дан тора иде. Ул «номер»ларның берсендә Казаннан килеп ай буе яткан налог агенты яши икән, ике бүлмәсен без алдык. Камал абый бер урынлыга, Дамир Хәйруллин белән мин икенче бүлмәсенә урнашып, ашханәгә киттек. Ашханәләрендәге ашамлыклар аппетит кузгатырлык булмагач, Дамир, сөйләшмәкче булып, эчке бүлмәгә кереп китте. Янәсе, директор янына. Бераздан, Дамирга ияреп, бик чибәр хатын чыкты да, Камал абый алдына меню ташлады һәм:

– Сайлагыз, пилмән бар, котлет, көтеп торырга вакытыгыз булса, бефстроганов кыздырырбыз, – дип җавап бирде.

Камал абый:

– Үзегез әзерләп чыгарыр булсагыз, спектакль башланганчы көтәргә дә риза, – диде.

Дамир белән мин, азмы-күпме ит катыштырган котлет белән макарон ашадык та, клубка киттек. Камал III бефстроганов көтеп калды. Клубта гримланып киенәсе бүлмәләрне һәм декорацияләр әзерлеген күргәч, гостиницадагы «номер»ыбызга кайтып, ял итәргә яттык. Кандалалары көндез үк һөҗүмгә күчкән урында күпме вакыт аунаганбыздыр, бермәл авызы колагына җитеп елмайган Камал абзабыз кайтып керде дә:

– Уяныгыз, йоклый торган көн түгел бүген, – диде.

Дамир:

– Ни таптың, Камал абый? – дигәнгә, Камал абый: – Мин тапмадым, ул мине тапты. Радиодан тыңлаган буенча мине күптәннән белә икән, күргәне генә булмаган. Инде менә күргәч: «Кунак итми җибәрмим, кичке ашка бәлеш салдырам, иптәшләрегезне дә алып килегез», – диде. Давай торыгыз, зарыктырмыйк бәлешне!

Бәлешенең тәмен, сыйфатын хәтерләмим, ә менә өч кеше өчен түләгән акчасы Камал абыйның «директор каршында» банкир биеклегенә күтәрде кебек. Соңыннан белдек: ул Сәрия исемле «завпроизводством» икән. Мин аңа спектакльгә ике кешелек чакыру билеты язып бирдем.

Камал абый:

– Кунак ашы – кара каршы, спектакльдән соң безгә, гостиницага кайтабыз, – диде.

«Бәлештән» соң, Камал абый кибеткә китте, без – клубка.

Спектакль, ничек булса – шулай барды, Камал абый гына башка көннәрдәгедән үзгә – дәртле иде. (Ул станциядә поездларны каршылап, вокзалда тәртип саклап торучы карт ролен башкара иде.)

Спектакль бетте. Сәрияне ияртеп, гостиницага кайтуны безгә йөкләп, Камал абый китәргә ашыкты. Гадәттә, спектакльдән соң яшьләр «вечер» уйный, Сәрияне эзләп, без дә «вечер»га төштек. Тик Сәриябез юк. Аны эзләп, ашханәгә киттек. Андагы төнге каравылчыга ышанганда, «Сәрия иреннән башка беркая да бармый» икәнлекне белдек. Бу хәбәрне Камал абыйга ничек җиткерергә? Әллә, гостиницага кайтмый, клубта гына кунаргамы? Дамир әйтә: «Сумкасы бик авыр иде, Камал абыйга булышыйк», – ди.



Уфага барган чак. Уңнан беренче: Камал III, Әхтәм Зарипов, Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Зариф Закиров, Клара (костюмерша). 1963 ел

Шулай эшләдек тә. Үзе хәмер эчмәгәч, безгә күбрәк эләкте, йокы килә башлады. Камал абый берөзлексез тәмәкесен тарта-тарта безне сүгә, «булдыксызлар», ди. Шунда Дамир түзмәде: «Үкенмә, Камал абый, аның ире бар икән», – дип әйтеп ташлады. Моны әйтү кирәк булгандырмы-юкмы, Камал абыйның бу хәбәргә җавабы мине хәзер дә гаҗәпләндерә: «Ә мин аны белә идем, минем сезне сыныйсым килде», – диде. Чыны ничек булуын белә алмый гомер узды. Инде менә ничә еллардан соң уйлап утырам: Камал IIIнең хатыны Асия Мәсәутова, авызыннан тәмәке төшмәгән кырыс холыклы, кискен табигатьле, бала табудан мәхрүм хатын булганлыктан, Камал абыйның чибәр хатынга күзе төшүе гаепме?!

Без – артистларның күбесе, кассадан эш хакы алуга, аны хатыннарыбызга тапшырырга ашыгабыз. Ә Камал абый, чират торып, кеше белән бергә алмый, аерым ала. Кесәсендәге бумажникта һәрчак акча була. Аның бу гадәте артистлар өчен файдалы булуына бер мисал китерәм.

1963 елның җәендә театрыбыз Өфе шәһәренә пароходта гастрольләргә барды. Директорыбыз мунча директоры вазыйфасыннан театрга күчерелгән «партчиновник» иде. Суточный түләргә дә, эш хакы бирергә дә театрның акчасы юк. Шунда театрны бу хурлыклы кыенлыктан Камал IIIнең сакчыллыгы коткара: ул үз кесәсеннән театрга бер айлык эш хакы һәм юл чыгымнарын капларлык акча биреп тора. Театр тарихында булмаган бу хәлне әлегә исән булган щепкинчы артистлар хәтерлиләрдер. Ә миндә, шул гастрольләр истәлеге булып, бер фоторәсем сакланган. Шуны бу язмама өстәп, журналга бүләк итәм. Бу фоторәсем бердәнбер булган кебек, Камал III үзе дә бердәнбер иде. Конфликтсыз, ызгышуны белми торган, түзем, нәзакәтле ир – шәхес иде. Аның үлеме дә, һич көтмәгәндә, кинәт булып, күпләрне гаҗәпкә калдырды. Авырлыклар күрмәгән, үз-үзен тәрбиядә генә тоткан артистның 70 яшен дә тутырмый дөньядан китүе театрны гына түгел, артистны күреп белгән тамашачыларны да әлегә кадәр гаҗәпләндерә. Нихәл итмәк кирәк, үлем үкенечсез булмый, дигән сүз дөрестер. Үкенәбез һәм олы артистны күреп калуыбыз белән горурланабыз. ■

Филармония коллективы. 1941 елның көзенә билгеләнгән Мәскәүдә узарга тиеш булган декада алдыннан

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

БЕРЕНЧЕ 10 ЕЛ

Вакыйгалар:

1937 ел, 21 август – Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советының Татар дәүләт филармониясен оештыру турындагы карары чыга.

1937 ел, 11 сентябрь – филармония каршында татар фольклоры кабинеты ачыла. 10 октябрьдән аны Александр Ключарев җитәкли.

1937 ел – Хөкүмәт карары нигезендә, филармониядә Дәүләт хор капелласы барлыкка килә. Ярты ел үткәч, ул ТАССРның җыр һәм бию ансамбле итеп үзгәртелә. 22 ел дәвамында ансамбльнең сәнгать җитәкчесе һәм хормейстеры Зөләйха Әхмәтова була.

1937 ел – филармониядә эстрада-концерт бүлеге оештырыла.

1938 ел, 11 гыйнвар – филармониянең иң беренче коллективы – 35 музыканттан торган симфоник оркестр – Татар дәүләт симфоник оркестры дип атала башлый. Башлангыч чорда оркестр белән Михаил Шеппер дирижерлык итә, соңрак аны Ильяс Әухәдиев алмаштыра.

1939 ел – Александр Ключарев тырышлыгы белән, филармониядә татар халык инструментлары оркестры оеша. Ләкин оркестр 1941 елда таркатыла.

1940 ел – Җыр һәм бию ансамбле беренче тапкыр ил буйлап озак вакытлы гастрольгә чыгып китә. 160 көн эчендә Ерак Көнчыгышта һәм Себердә 100дән артык концерт бирелә.

1941 ел – республиканың бөтен мәдәни тормышы бары тик бер вакыйгага – көзен Мәскәүдә үтәчәк ТАССРның әдәбият һәм сәнгать декадасына юнәлдерелә. Бөек Ватан сугышы башлану бу планнарны җимерә. Филармониянең күп артистлары сугышка алына.

Симфоник оркестр чыгышы. 1937 ел

1941-1945 еллар – Татар дәүләт филармониясе республика территориясендәге госпитальләрдә, хәрби частьларда 1700 шефлык концертын куя. 60 артист, 17 бригадага бүленеп, төрле фронтларда концерт программалары белән чыгышлар ясыйлар.

1945 ел – Татар дәүләт филармониясе артистлары Мәскәүнең дәрәҗәле концерт залларында чыгыш ясый. Бу елны Мәскәүдә Наилә Рәхмәтуллина, Сара Садыйкова, Асия Измайловаларның зур концертлары уза.

1945 ел – Җыр һәм бию ансамбле гастроль белән Урта Азия республикаларын йөреп чыга.

1945 ел – Әдәби-музыкаль лекторий бүлеге оеша.

1946 ел – Росконцерт, Союзконцерт, Москонцерт, Гастрольбюро кебек эре концерт оешмалары белән тыгыз элемтә урнаштырыла.

1946 ел – Милли музыка мәдәниятенә керткән зур өлеше өчен һәм Габдулла Тукайның тууына 60 ел тулу уңаеннан, Татар дәүләт филармониясенә бөек шагыйрьнең исеме бирелә.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле. Солистка – Разия Тимерханова. Баянчы – Габдулла Халитов. 1941 ел

ОПТИМИСТИК ФИКЕР *һәм хисләр җырчысы*

Дания Гайнетдинова

«Яңа буралар». Киндер, майлы буяу

Татарстанның 100 еллыгына әзерлек барган бу көннәрдә татар сынлы сәнгате өлкәсендә үзләрен таныткан сәнгатькярләрне искә алмасак, хилафлык булыр иде. Сүзебез рәссам, график, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның халык рәссамы, СССРның Дәүләт һәм Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Лотфулла Габделмән улы Фәттахов турында барыр.

Лотфулла Фәттахов тумышы белән Нижгар өлкәсенең Сергач районындагы Анды авылыннан. Лотфулла Фәттаховның әтисе Гражданнар сугышында һәлак була, әнисе 1926 елда ачлыктан үлә. Аларның дүрт ир баласы ятим кала. Лотфулланың әдәби әсәрләре һәм рәсемнәре мәктәп елларында ук «Пионер каләме» газетасында басыла башлый. Беренче уңышларыннан канатланган малай, укырга, дип, Казанга җәяүләп юлга кузгала. Аркасына биштәр аскан, аягына аркылы-торкылы киндер белән бәйләнгән галош кигән малай, Казанга килеп, Яңа бистәнең 13 нче мәктәбендә укый башлый. Мәктәптә кунып калучы бу ятим баланы Маһикамал һәм Габдрахман Якуповлар, үзләренең 6 баласы һәм тәрбиягә алынган бер кыз бала өстенә 8 нче бала итеп, тәрбиягә ала. Булачак ике рәссам – уллары Харисның мәктәп дусты Лотфулла тырышып укый һәм рәсем түгәрәгенә йөри. Лотфулла, әдәбият белән мавыгып, «Әдәбиятчы» дивар газетасына хикәяләр яза, рәсемнәр ясый. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, ул укуын Казан сәнгать училищесында дәвам итә.

Лотфулла Фәттахов 1939 елда фин сугышына китә. 1941 елда Бөек Ватан сугышы

башлангач, ул чик буендагы Брест шәһәре янындагы каты сугышларда катнаша, контузия алып, әсирлеккә төшә. Әсирлектән берничә тапкыр кача да. Ләкин аны һәр качуында да тотып, кабаттан концлагерьга ябалар. Соңгы дүртенче качуы гына уңышлы була. Лотфулла Фәттахов өчен Бөек Ватан сугышы 1946 елда Венгриядә тәмамлана. Сугыштан ул Казанга, туп-туры дусты Харисның өенә кайта һәм шушы гаиләдә яши башлый. Соңрак Лотфулла Фәттахов Харис Якуповның сеңлесе Суфыяга өйләнә.

Рәссам Лотфулла Фәттахов – зур картиналар, пейзажлар, портретлар остасы. Аның иң яраткан темалары – авыл тормышы турындагы сюжетлар һәм әкиятләргә иллюстрацияләр. Фронтта карандаш белән ясаган рәсемнәре дә шактый Л.Фәттаховның. Әлбәттә, алар арасында иң уңышлылары – үзе белән бергә хезмәт иткән фронтовиклар

«Күчмә лаборатория янында». Киндер, майлы буяу

– «Иван Хитров», «Петя солдат», «Старшина Гусев» портретлары. Боларның һәммәсе дә – 1945 елда ясалган эшләр.

Лотфулла Фәттаховның сугыштан соңгы иҗаты да гаҗәеп кызыклы. Алар, дусты Харис Якупов белән, китап бизәүдә дә актив катнашалар. Л.Фәттаховның китап графикасында беренче уңышы ул – А.Нәваиның «Фәрхад һәм Ширин» исемле поэмасына ясалган 20 эштән торган рәсемнәр. Татарстан китап нәшриятында 1948 елда дөнья күргән әлеге китапка автор эшләрен тушь белән ясый һәм алар китап геройларының рухи дөньясын ачып бирә. Шул ук елны рәссам «Гали баба һәм кырык карак» дигән гарәп әкиятенә дә рәсемнәр иҗат итә. Ул, әлеге китапны бизәгәндә, декоратив орнаментларга да таяна.

Л.Фәттахов татар халык әкиятләренә дә, рус һәм чит ил классик язучылары әсәрләренә дә шактый рәсемнәр ясый. Аларны санап үтү дә озынга китәр иде. Шулар арасында К.Нәҗминең «Яңа өйдә» (1947), М.Әмирнең «Якташ», А.Әхмәтнең «Солдат балалары» (1948), Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1959), Г.Ахуновның «Хәзинә» (1966) исемле китапларын әйтеп үтми мөмкин түгел. Кылкаләм остасы һәр китапка рәсемнәр ясаганда, әсәрнең эчтәлегенә зур игътибар биреп, аларны шул геройларга тәңгәл килердәй итеп чагылдырырга тырыша. Ул, һәр язучының стиль үзенчәлекләрен дә исәпкә алып, рәсем ясау техникасын сайлый.

1952 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гөлчәчәк» әкиятләр җыентыгында исә Л.Фәттахов тушь белән ясаган рәсемнәренә акварель өстәп җанландырып җибәрә. Әкиятләргә ясаган рәсемнәре аша без аның халык тормыш-көнкүрешен якын белүен дә сизәбез. Аларда төсләр аеруча оста салына, шуңа күрә бизәлештә бик югары нәтиҗәгә ирешә дә. Авторның графика өлкәсендәге хезмәтләре, шулар арасында, әлбәттә, әкиятләргә ясалган рәсемнәре дә шул чордагы татар совет графикасында күренекле урын алып тора һәм классика дип бәяләнергә хаклы.

1956-1958 нче елларда «Татар халык әкиятләре» дигән ике томлыкны бизәгәндә исә автор акварель буяулар кулланып эшли. Л.Фәттахов бу зур хезмәтне дусты Х.Якупов белән бергә бизи. Ике останың китап графикасындагы әлеге олы хезмәте 1958 елда

«Әни күрмәгәндә». Киндер, майлы буяу

«Яшьлек». Киндер, майлы буяу

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Болардан тыш, кылкаләм остасының тематик картиналар иҗат итүдә куйган хезмәтләре дә әһәмияткә лаек. Сугыштан соң, рәссамнарның уй-хыялларын киндердә чагылдыру мөмкинлеге ачыла. Л.Фәттахов та сәнгатьнең бу төренә әзерлекле булып килә. Әйтик, 1948 елда иҗат ителгән «Туган ил турында җыр» картинасында автор, үзе кичергән хисләрне кушып, совет солдатларының туган илне сагынуларын лирик бизәкләрдә чагылдыру югарылыгына ирешә. Ул әлеге картинада чынбарлыкны шагыйрь күзе белән күреп, аны бәгырьгә үтәрлек итеп бирә. Юкка гына әлеге әсәре белән ул шактый күргәзмәләрдә, шул исәптән Мәскәүдә узган Бөтенсоюз күргәзмәсендә дә катнашып, югары бәя алмагандыр.

1950 нче еллар башында Совет Татарстанының оешуына 30 ел тулу уңае белән үткәреләчәк тантанага «В.И.Ленинның Татарстан АССР төзелү Декретына кул куюы» дип аталачак картина ясауны Л.Фәттахов белән Х.Якуповка йөклиләр. Юбилейга өч айлап кына калган бу кыска вакыт аралыгында авторларга, Мәскәүгә барып, Совет хакимиятенең беренче елларында барган әлеге атмосфераны дөрес чагылдыру өчен, шактый документлар белән танышырга туры килә. Композицияне ничегрәк төзү,

юлбашчының төс-кыяфәтен ышандырырлык итеп бирү кебек нәрсәләргә ирешү өчен, зур тырышлык сорала.

Бу эш Мәскәүдә күргәзмәдә катнаша һәм белгечләр тарафыннан югары бәя ала. Аннан соң әлеге хезмәт зур бүләккә – СССРның Дәүләт премиясенә тәкъдим ителә. Бу урында бик тә кызыклы һәм гыйбрәтле бер вакыйганы искә алып үтү урынлы булыр. «Л.Фәттаховны, сугыштан кайткач, еш кына Черек күлдәге оешмага чакыртып интектереп тордылар», – дип искә алгалаганы бар иде Харис абыйның. 1950 елда Х.Якупов белән эшләгән «В.И.Ленинның Татарстан АССР төзелү Декретына кул куюы» дип аталган әсәр Сталин премиясенә тәкъдим ителгәч, Харис абыйны Өлкә комитетына чакырталар. Шул вакыттагы секретарь Рәхмәтуллин Харис абыйга: «Менә

«В.И.Ленинның Татарстан АССР төзелү Декретына кул куюы». Киндер, майлы буяу

әле генә партиянең Үзәк Комитеты белән сүз булды, премияне сиңа гына бирәчәкләр, ә Л.Фәттаховка юк, чөнки ул пленда булган», – ди. Харис абый күп уйлап тормый: «Лотфуллага бирмәсәләр, миңа да бирмәсеннәр, ул – безнең уртак эшебез», – дип әйтеп ташлый. Ул вакытта әле Сталин исән чак. Шуннан соң Хаҗи Баязитович, икенче бүлмәгә чыгып, кабат Үзәк Комитет белән элемтәгә керә. Шактый җитди сөйләшү була бу. Нәтиҗәдә, әлеге Дәүләт бүләген Х.Якупов белән Л.Фәттаховка бирергә, дигән уртак фикергә киләләр. Әлеге вакыйганы Лотфулла Фәттаховның тууына 100 ел тулу уңаеннан «Хәзинә» милли галереясында узган күргәзмәдә аның улы Рәшит тә искә төшереп үткән иде.

Л.Фәттахов иҗатында тарихи тематиканы башлыча татар халкының үткәненә турыдан-туры бәйле вакыйгалар тәшкил итә. Әйтик, 1964 елда иҗат иткән «Революция комиссары Мулланур Вахитов» картинасында автор үз эшен аерым бер тарихи шәхес белән бәйләсә дә, бу әсәрендә Гражданнар сугышы комиссарының гомумиләштерелгән образын гәүдәләндерә. Бер караганда, В.И.Ленинның көрәштәше, интернационалист М.Вахитов Казан Кремле фонында бирелгән. Шул ук вакытта әсәрнең колориты – офыктагы кара-кучкыл болытлар, агач-куакларның җилдә җилфердәгән яфраклары, ерактан шәйләнгән ак дивар, комиссарның кояшта янган ачык йөзе, җитди карашы, һичшиксез, уңай тәэсир калдыра.

Кылкаләм остасының 1967 елда иҗат иткән «Совет властеның беренче еллары» дигән әсәре дә авторның гаять киң колачлы һәм үзенчәлекле рәссам булуы турында сөйли. Аның киндере кояш нурына күмелгән. Кызыл әләмнәр, җете буяу белән язылган транспарантлар, әйтерсең лә бәйрәм халәтен хәбәр итә. Автор моның белән Бөек Октябрь алып килгән шул чорга мәдхия җырлый.

Аның шулай ук 1969 елда иҗат иткән «Уйланулар. Володя Ульянов Идел буенда», 1965 елда ясаган «Яшәргә. Тиздән азатлык килә» картиналарын да шул чорның иң уңышлы эшләре дип бәяли алабыз. Боларда Л.Фәттаховның ил күләмендәге тарихи-патриотик теманы ачуда үзенчәлекле милли рәссам булуын күрәбез. Авторның шулай ук авыл хезмәтчәннәренә багышланган картиналарында да хезмәт кешесенең тырышлыгы һәм аның ял вакыты тасвирлана. «Игеннәр өлгерде» (1952), «Сабантуй» (1957), «Райком секретареның эш көне» (1961), «Шәһәрдән кайтканда» (1964) картиналары – шундыйлардан. Л.Фәттаховның «Игеннәр өлгерде» картинасының репродукцияләре заманында үзәк матбугатта да басылып чыга. Бүген дә әлеге әсәрне газета-журнал битләрендә еш очратабыз. Бу картина хәзерге вакытта Түбән Тагилдагы сынлы сәнгать музеенда саклана.

Л.Фәттахов «Сабантуй» картинасын, Мәскәүдә булачак Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына атап, 1957 елда иҗат итә. Бу әсәр дә аның Арча районында узган Сабан туе тәэсирендә языла. Әлеге декада узгач, рәссамга Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Л.Фәттаховның 1959 елда иҗат ителгән «Яңа буралар» картинасы да – авторның зур иҗат әсәре. Ул аны үзенең туган авылы Андыга кайтып килгәннән соң иҗат итә. Картинада Идрис Бәдретдинов образы иң үзәк урынны алып тора. Әлеге образ рәссамның бөтен иҗаты буйлап уза, дисәк тә, хата булмастыр. Идрис абыйның акыллы, мөлаем кыяфәте «Игеннәр өлгерде», «Күчмә лаборатория», «Сабантуй» һәм башка бик күп картиналарында чагылыш таба. «Яңа буралар» әсәрендә исә рәссамның төсләрне гаҗәеп нечкә сиземләвенә игътибар итәсең. Авылдашы Идрис Бәдретдинов образын шулкадәр оста тасвирлавы, аның чын-чынлап халык вәкиле буларак ачылуы әсәрне тулы мәгънәсендә көчле итә.

Лотфулла Фәттаховның балаларга багышланган картиналары да шактый. Әйтик, 1956 елда ясаган «Әни күрмәгәндә» дигән картинасы аеруча самимилеге белән аерылып тора. Киез итек кигән малайның язгы суга кереп китүе безгә сабыйның эчкерсез һәм кызыксынучан булуы турында сөйли. «Тургайлар» (1958-1959) картинасы да балаларга атап иҗат ителгән. Күзләрен күккә текәп, тургай җырын сокланып тыңлап торучы кызчык һәм аның янәшәсендәге ике малай безне зәңгәр күккә тургайлар янәшәсенә дәшә сыман.

Нинди генә темага алынса да, рәссам шул чорны, андагы геройларны халык күңеленә үтеп керерлек итеп сурәтли. Әйтик, 1955 елда киндердә тасвирлаган «Яшьлек» дигән картинасында автор алмагач төбендә хат укып утырган кыз баланы шундый итеп сурәтләгән ки, алмагачның ап-ак чәчкәләре әлеге кызның ак яулыгы белән алъяпкычы – барысы бергә яшьлекнең чинбарлыгын – борчу-мәшәкатьләрен дә, сөю-сөелү сагышларын да ачып бирә сыман. Л.Фәттахов иҗат иткән әсәрләр тамашачыны чын мәгънәсендә уйланырга, шул иҗат әсәре аша сәяхәт итәргә дәшә төсле. Аның бөтен иҗаты безне үткәннәр белән бәйләп, тормышны яратырга, Ватан-анабызга, туган халкыбызга тугрылыклы булырга өнди. Авторның милли үзенчәлекле мирасы бүгенге һәм киләчәк буыннар өчен дә үрнәк булып тора. Ул чын мәгънәсендә оптимистик фикер һәм хисләр җырчысы булып күңелдә саклана... ■

ТУГАН ЯК АВАЗЫ

Мөхәммәт Мәһдиев

Туган телем –
Әткәм-әнкәм,
Балам-онытым теле.



Вакыт әкрен генә, сиздермичә генә үтеп бара. Сөекле язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең арабыздан китүенә дә инде чирек гасыр гомер узган. Ләкин «Кеше китә – җыры кала». Мөхәммәт абыйның да җыры калды. Ул – аның татар әдәбиятының җәүһәрләренә әверелгән үлемсез әсәрләре, әһәмияте вакыт узган саен арта гына барган фәнни хезмәтләре, аның дәресләреннән белем эстәгән, аны сагынган, аңа гомергә рәхмәтле булган йөзләрчә шәкертләре һәм, әлбәттә инде, меңләгән укучылары...

Мөхәммәт ага Татарстан радиосы белән дә бик дус яшәде, ул безнең иң актив авторларның берсе булды. Һәр яңа язган хикәяне, күләмле әсәр булса, шуннан өзекләрне, ул, иң беренче итеп, безгә алып килер, аларны халыкка тәүге мәртәбә безнең радио аша ирештерер иде. Мөхәммәт ага тапшыруларыбызга әдәби әсәрләре белән генә түгел, шулай ук төрле темаларга багышланган кызыклы чыгышлары, әңгәмәләре белән дә даими катнашып килде. Әдәби әсәрләрнең кайберләрен артистлар, нәфис сүз осталары башкарса, кайсыларын, аеруча тәрҗемәи хәленә кагылышлыларын һәм публицистик язмаларын ул үз тавышы белән яңгыратты. Публицистик язмаларга килгәндә, туган тел язмышын, аның киләчәге тирән кайгырткан әдип аларның байтагын ана телебез ядкярләренә, туган төбәкнең тарихи атамаларына, аерым сүз-тәгъбирләрнең этимологиясенә, ягъни килеп чыгышына багышлады. Андый чыгышларның берничәсе безнең радио фондында да саклана. Шуларның берсен – «Туган як авазы» дигәнен журнал укучыларына да тәкъдим итәбез. Эчтәлегеннән шәйләнгәнчә, бу чыгыш этимология мәсьәләсенә җиңелчә караган кайбер галим-голәмәнең уйдырма-фаразларына беркадәр җавап та булып тора.

Рөстәм Акъегет

Миңа, соңгы елларда, Казан арты авылларының исемнәре каян килеп чыгуын сорап хатлар килә. Мин бу өлкәдә белгеч түгел, әлеге мәсьәлә белән махсус шөгыльләнгәнем юк. Фән-гыйлем өлкәсендә минем XX гасыр башы татар әдәбиятына һәм халык авыз иҗатына караган азмы-күпме хезмәтләрем бар. Авыл исемнәренә килсәк, монда инде мин туган як тарихының табигатендә, җирендә сакланып калган кайбер авазларын интуиция белән генә сизә алам. Шулай да бу өлкәдә тәҗрибә уртаклашып карыйсым килә. Авыл исемнәренең тарихын өйрәнгәндә, мин түбәндәге ике концепцияне нигез итеп алдым. Беренчесе – авыл исемнәре аларга кешеләр күпләп урнашканчы ук бирелгән һәм, шунлыктан, бик күп исемнәр шул тирәдәге урман, елга, басу, шунда үскән агач, шул тирәдәге рельефка, шунда тереклек иткән кыргый хайваннар, кошларга бәйләнешле ясалган. Икенчесе – Казан ханлыгы урыс дәүләтенә буйсындырылганнан соң, бу авыллар урыс түрәләре, землемерлар тарафыннан исәпкә алынган һәм, кәгазьгә язылганда, урыс теленә якынайтылып, үзгәреш кичергәннәр. Димәк, кайбер авылларның исемен урысчадан татарчага кайтып эзләргә кирәк. Менә шул ике концепциягә нигезләнгәннән соң, мондый нәтиҗәгә килдем: Болгар заманында «тау» сүзе урынына «мар» сүзен кулланганнар. Шул турыда шагыйрь Нәҗип Думави да әйтә: «Бу чокырлар бар да Болгарлар оры, Болгар мары», – ди ул «Юлда» шигырендә. Моннан ачыла: тау итәгенә урнашкан Кукмара һич тә мариларда «ике» дигәнне аңлаткан «кук» сүзеннән алынмаган, ә «Күк тау» сүзеннән ясалган, ягъни «күк мар». Идел өстендәге Моркваши «Мар куышы» булып чыга. Урманлы текә тау астына урнашкан авыл Поши тавы авылы (Балтач районында) Поши мары була. Документларга ул Пижмара булып кереп киткән. Арча районындагы Мөрәле авылы да шулай. Әлеге авыл ике яктан тау белән уратылган. Үзәндә утыра. Ул «мар иле», шуннан Мөрәле. Урмары – «Ор тавы», «Каймары» (Дөбьяз ягында) – «Каен тавы» дигән сүз була.

Күп кенә авылларның исеменә «ил» сүзе нигез булган. Ил, халык, бер күч мәгънәсендә. Умарта кортларының да күче «ил» дип йөртелә. «Ил» сүзеннән чыгып, байтак авылның исемен ача алабыз. Ләкин шуңарчы бер әйберне искәртеп үтик. Борынгы Казан арты – Арча, Әтнә, Дөбьяз, Балтач, Чыпья, Саба төбәкләре тоташ кара урманнан, тирән сулы елга-күлләрдән торган. Бик борынгы заманнарда, әлбәттә инде, бу якта исәпсез-хисапсыз киек кошлар, кыр хайваннары яшәгән. Киек кошлардан монда кыр казлары, торналар, аккошлар яши торган аерым урыннар булган. Табигатьнең кайбер сәерлекләренә очрап, бу кошлар, вакыт-вакыт колония булып, монда кышлауга да калганнар. Торналар бала чыгарган төбәк – Арча ягында Торна иле, хәзер Төрнәле, Олы һәм Кече Төрнәле авыллары дип исемләнгән. Ул якларда әле дә булса, басу һәм елгаларны, әйтик, Сикертән, Гөберчәк авыллары тирәсендә Торна басуы, Торна елгасы дип йөртәләр. Казан елгасы буендагы Каз иле авылының да исеме һич тә, мәдрәсә булганлыктан, казыйлар иле дип түгел (мәдрәсә анда XIX гасырның башында гына ачылган) яки борынгы заманда анда «каз кабиләсе» халкы яшәгән булуы мөмкинлегеннән түгел, ә бик гади табигый шартларга бәйле аңлатылырга тиеш. Урманлы-сулы бу төбәккә ел саен киек казлар килеп, анда бала чыгарган. Киек кошлар исә бик консерватив, ата-бабалары элек бала чыгарган урыннарын алар хәтерләрендә биш-ун мең еллар буе буыннан-буынга тапшырып саклап киләләр. Бу бигрәк тә аккошларда күзәтелә. Казан арты борынгы заманда аккошлар иле булган.

Урман эчендәге бик күп елга, күл буйларында аккош колонияләре утырган. Аккошны исә бер төбәктә «акку», икенче төбәктә «ку» дип йөрткәннәр. Шагыйрь Дәрдемәнд шигырьләрендә моңа мисаллар күп.

«Тоныклялтыр күлләрендә

Каңгылдый аккулары», – дип яза ул.

Яки:
«Гөрләсә, су чыңласа
Акку һаваларда очып...»

Бәс, шулай икән, Дөбьяз һәм Питрәч якларындагы Ташлы Ковал, Ковали авыллары исемендә «Ку иле» дигән сүз ята. Землемер яки түрә аны Ковали дип язмый хәле юк.

Сөн буенда Аккүз авылы бар (Актаныш районы). Аның болынына, ел саен булмаса да, ара-тирә берәр пар аккош килеп җәйли икән. Урысларда бу «вечный зов» дип атала. Ә бездә «бабайлар каны тарта», диләр.

Аккүз авылының да исеме башта, бәлки, Акку булгандыр, аны документка гына шулай Аккузево дип язганнардыр. Тагын шунысы да кызык, Дөбьяз төбәгендәге Ку Иле – Ташлы Ковал янындагы Бикнарат авылы кешесе Хәбибулла Әһмәдуллин, музыкабыз тарихында беренче буларак, марш – «Аккош маршы»н иҗат иткән. Бу моңнарны әби-бабалары тапшыргандыр аңа. Безнең халык җырларында аккош бик еш телгә алына бит.

Фламинго, пеликаннар юк, ә менә аккош гел очрап тора. Димәк, ата-бабаларыбыз аккошлар белән бергә гомер сөргән. Казан артындагы Чүриле авылы исемен дә ялгыш аңлату булып алды. Бу һич тә чуралар иле, янәсе коллар дигән сүздән түгел. Колбиләүчелек булмаган халыкта коллар иле буламыни? Һәм, гомумән, коллардан гына торган авыл буламыни? Юк, әлбәттә. Тарихка күз салыйк, Казан урыс дәүләтенә буйсындырылгач, урманлы-болынлы бу төбәккә урыслар килеп урнашкан. Менә алар: Казаннан Царицыно авылы чиркәве, аннан Биектау, Чыпчык, Чүриле, Төбәк Чокырча, Арча чиркәүләре. Барысы да – Казан елгасы бассейнында. Мул сулы, урманлы урыннар. Татар халкы урыс патшасын царь, чар дип йөрткән. Патша дигән сүз шәрык илләренең монархларына карата гына кулланылган. Һәм Казан елгасы буена килеп болын түренә урнашкан урыс авылын татарлар чар иле дип атаганнар, ягъни патша иле, патша авылы. Шуннан Чурилино, ягъни Патша иле килеп чыккан. Әле XIX гасыр башында гына чыккан татарча тарих китапларының барсында да чар Алексей, чар Александр, чар Николай дип язу модада булган. Болар инде бәхәссез кебек.

Инде «ор» сүзенә килик, бу – бик хикмәтле сүз. Бер урында ул – калкулыкны, икенче урында – чокырны, өченче урында коры елганы аңлата. Кешеләр килеп, урман кисеп басу ясагач, Казан артында бик күп елгалар сусыз калган һәм аларны коры елга дип йөртәләр. Кыйссабызга яңадан аккош килеп керә. Казан артына кара урман эченнән аккан Кесмәс-Мишә бассейнында мәгълүм бер урында аккошлар колониясе булган. Кесмәс буендагы тау битен бабайлар ку орысы дип йөрткәннәр. Шуннан авыл исемнәре: Югары У орысы, Урта У орысы, Түбән У орысы, У орысы башы, У орысы почмагы. Рәсми документларга ул Орса дип килеп кергән һәм соңгы заман халкы аны Курса, Курсабаш, Курса Почмак дип йөртә башлаган. Габделнасыйр Курсави үзенең аккошлар илендә туып-үскәнен белдеме икән?!

«Ор», дигәннән, бу сүз мәшһүр Арча исемендә ята. Әйткәләп-язгалап карадылар, имеш, Арча авылының исеме «ар» сүзеннән, ягъни шул якта яшәгән удмуртларны ар дип йөрткәнлектән, диделәр. Тагын бер гипотеза булды, имеш, аның тау битендә арча агачы үскән. Ничек инде Урта Азиядә үсә торган бу арча агачы, тикторганда гына, Питрәч, Саба, Теләчедә түгел, нәкъ менә Арча тау битенә генә килеп үссен? Алай булмый бит! Арчаны күргән кешеләр беләләр, ул Казан елгасы буенда борылмалы тау битенә урнашкан. Аны әле заманында бер коры елга урталай ярган булган. Аны инде акрынлап күмеп бетерәләр бугай. Арча сүзе, әлбәттә инде, орычадан алынган, калку урын, ягъни коры елга мәгънәсендә. Ор сүзеннән Орск сүзе дә ясалган. Орыча, Арча астында түбәндә Чокырча авылы бар. Борынгы татар телендә «чок» сүзе түбәнлекне

аңлата. Кайбер төбәкләрдә начар, әдәпсез кешене әле дә «чок кеше» дип йөртәләр. Димәк, Орыча, Арча калку урында булса, Чок орча – түбән урында. Ничек инде бер үк сүз «югары» дигәнне дә, «түбән» дигәнне дә аңлата, дип, каршы килүләре мөмкин. Ләкин бит фәндә мономорфизм күренеше бар, ягъни бер үк әйбернең үз эчендә капма-каршы мәгънәдә яши алуы. Иван Сергеевич Тургенев әйтә: «Верхом называется в Орловской губерни овраг». Моңа мисаллар байтак. Смрад – сасы ис дигән сүз, смородина – хуш исле карлыган һ.б. «Ор» дигән сүз шулай күп мәгънәле икән. Димәк, Арча астындагы Күпербаш авылының да исеме һич тә күпергә бәйле түгел. Кайсы авылда гына күпер юк соң?! Ә төньякка таба Казан елгасы бассейнына эчкәрәк кергән саен күп орлар булачагы ишарәләнә: менә бу урын күп орның башы, күп ор башы. Землемер үзенең кенәгәсенә яза: Күпербаш. Землемер эчкәрәк керә, картлардан сорый: «Бусы тагы нинди авыл?» – ди. «Ә, Күп орчык», – диләр бабайлар. Чөнки бу авылның бөтен болыны түмгәктән, бөтен басуы коры елгадан тора. Дөрес, алар моңарчы бу авылны Кече мул, дип йөртәләр иде. Ә монда инде төгәлрәк – Күп орчык. Шуннан инде рәсми документка Губорчок, шуннан Гөберчәк.

Бусы минем туган авылым. Землемер документы аркасында авыл исемнәренең үзгәрүенә Казан артыннан тагын берничә мисал. Чиканас. Һич тә авыл читендә Әнәс дигән кеше яшәгәннән түгел. Аңа калса, Әнәскә кадәр авылның исеме ничек булган? Ул авыл өрәнгеле, имәнле урман астында урнашкан. Халык исә өрәнгене Чаган дип йөрткән. Чаган асты дигән авылны урыс землемеры яки чиновнигы «Чикан асты» дип язган да, шуннан татарчага якын Чиканас барлыкка килгән. Тукай-Кырлай янындагы Алмалы авылы да һич тә анда алма үстерелгәннән түгел. Анда – элмә урманы. Элмәле авылы ул. Казан арты урманнарында элмә бик күп үсә. Чиновник аны үзенең кәгазенә Элмәле, дип язмый, чөнки андый хәреф юк. Ул, урыслаштырып, Алмалы, дип яза. Казан артының пошилы урманнары турында аерым сөйләргә кирәк. Поши аланнарындагы авыллар документларга Пошалым дип кереп киткәннәр. Ләкин бу – алдагы тема. Һәм соңгысы: Казаннан мәгълүм сәбәпләр аркасында күчеп утырган кешеләр мари, удмурт якларында гел ышна арчып, ягъни урман кисеп, ышна төбен чыгарып, иген басуы ясап барганнар. Ышна басуы дигән сүз бу якта әле дә актив. Ләкин җир ала-ала бара, урман эченә керә торгач, бабайлар бер урында урман халкы мариларга барып төртелгәннәр. Сугышып тормаганнар, шул чиктә туктап, соңгы авылны салганнар. Ул авылны Соңгы ышна арты, дип йөртә башлаганнар. Документка ул Ышна арты дип түгел, ә Ишнарат дип теркәлгән. Әлеге авылның исеменә нарат сүзенең бер генә дә катнашы юк. Сүземнең ахырында минем безнең урманнарыбызда яшәгән пошиларыбыз турында, аларга бәйле авыл исемнәре, халык иҗаты турында бик тә сөйлисем килә иде, ләкин алар киләчәктә. Киләчәктә әле Кышкар, Кышлау, Кушлавыч, Өчиле, Кысна, Арбаш, береаз читкә китеп булса да, Көек, Шапшы, Чыпчык, Азнакай исемнәре турында сөйләргә иде.

Язма, язучының 1970 нче еллар ахырында
«Тел күрке – сүз» тапшыруында ясаган чыгышына
нигезләнеп, ***Рөстәм Акъегет*** *тарафыннан әзерләнде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2020

Эльмира Шәрифуллина

Йөрәк сүзем

Үз Ватаным – алтын,
Йөрәк сүзем – ялкын,
Дөрли-дөрли яна хисләрем.
Искән җилкәем дә
Туган телкәемдә
Әрен сөйли иртә-кичләрен.

Үз Ватаным – алтын,
Йөрәк сүзем – ялкын,
Кот качырып Җирем-Күгемнән –
Туган телгә – күсәк,
Йә, Раббым, дисәк,
Әүлиялар калкыр гүреннән.

Үз Ватаным – алтын,
Йөрәк сүзем – ялкын,
Набат суга Таулар, Кыялар:
Кагылмагыз Телгә!
Иң авырткан җиргә,
Имин булсын, дисәк, дөньялар!

Үз Ватаным – алтын,
Йөрәк сүзем – ялкын,
Шушы Сөю белән яшим мин.
Шушы Сөю белән,
Янып-көю белән
Түбәм – биек, якты, дөньям – киң!

Үз Ватаным – алтын,
Йөрәк сүзем – ялкын,
Сөйлик сүзнең маен чыгарып! –
Галәм залларында,
Гавам алларында,
Анам теле белән сугарып! ■

ДЕКАБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● **Декабрь башында** күренекле язучы Лирон Хәмидуллинның мәшһүр әдипкә нисбәтле «Дәрдемәнд» дигән китап-альбомы дөнья күрде.

● **2 декабрьдә** ТР Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында шагыйрь һәм прозаик Марат Закирга 50 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды. Кичәне А.Ногманова алып барды.

● **3 декабрьдә** РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Исламия Мәхмүтова 76 яшендә вафат булды.

● **5 декабрьдә** Язучыларның Тукай клубында олуг галим һәм әдәбият белгече Хатыйп Миңнегуловка 80 яшь тулу уңаеннан юбилей кичәсе (кичәнең сценарий авторы – А.Әхмәтгалиева) булып үтте. Республикабызның күренекле язучылары, галимнәре һәм сәнгать әһелләре катнашында узган әлеге кичәне А.Әхмәтгалиева һәм Р.Гатауллин алып барды.

● **9 декабрьдә** Мәскәүдәге Россия дәүләт китапханәсенең Көнчыгыш халыклары әдәбияты бүлегендә татар морзалары җәмгыяте җыелышы үтте. Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең тууына 160 ел тулуга багышланган әлеге чарада Р.Шаһиева, Лирон белән Булат Хәмидуллиннар катнашты һәм чыгыш ясады.

● **Декабрьдә**, «Азатлык» татар яшьләр берлеге рәисе Н.Нәбиуллинның тырышлыгы белән, Г.Исхакыйның «Зөләйха» китабы дөнья күрде.

● **9 декабрьдә** Язучыларның Тукай клубында танылган язучы Әхәт Гаффарга 70 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе (сценарий авторы – Н.Акмал) булды.

● **11 декабрьдә** Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында, «Һөнәр – 2019» XI Бөтенроссия яшь режиссура фестивале кысаларында, Буа дәүләт драма театры (җитәкчесе – Татарстанның халык артисты Р.Садриев), драматург И.Вырыпаевның «Иран конференциясе» пьесасына нигезләнеп, тамашачыларга рус телендә спектакль тәкъдим итте.

● **13 декабрьдә** Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына нисбәтле гомумҗыелыш узды.

● **16 декабрьдә** К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында, Татарстанның халык язучысы, олпат галим М.Мәһдиевнең тууына 90 ел тулу уңаеннан, «Яктырак йолдыз янадыр...» дигән әдәби-музыкаль кичә (сценарий авторы – Л.Лерон, режиссеры – Р.Шәриф) булып үтте. Кичәне А.Лерон һәм А.Пискунов алып барды.

● **19 декабрьдә** Балык Бистәсенең мәдәният йортында Татарстанның халык шагыйре Р.Фәйзуллинның «Гомер калейдоскобы» китабын тәкъдим итү кичәсе үтте.

● **20 декабрьдә** ТР Милли китапханәсендә Татар ПЭН-үзәге (президенты – Разил Вәлиев) үзенең чираттагы утырышын уздырды. Утырышта мәшһүр галим М.Худяковның татар, рус һәм инглиз телләрендә дөнья күргән «Казан ханлыгы» китабы тәкъдим ителде. ■

Мирасворд



Мансур Гыйләҗев пьесасы

Агач чиләк (диал.)

… тәмләткеч

Композитор … Мөлеков

Драматург … Гыйззәт

XVIII-XIX йөзләрдә ике мачталы, җилкәнле кораб

Мәүла …

Рахит (иск.)

Каенана (диал.)

Атилла Расих романы

Бизәкле ситсы, миткаль (иск.)

Сихерче, күрәзәче

Көньяк чыршысы, кипарис (иск.)

Дөя сөтеннән ясалган кымыз (диал.)

Спарта патшасы

Посейдон улы

Элекке ашлык сугу коралы

Борынгы грек мифологиясендә сугыш Алласы

Нәсел, токым

Туку станогы детале

Нәфрәт, ярсу тойгысы

1991-2000 елларда Чаллыда чыккан журнал

Уй, фикер, күңел (иск.)

Ял итү өчен тукталыш (бор.)

…-вакыт килеше

Нәкъ (диал.)

Африкадагы ил

Габдерәхим … Имәни

… Акчура

Азәрбайҗан каласы

Борынгы грек мифологиясендә үлеләр патшалыгы

Миргазиян Юныс туган авыл

Кыр кәҗәсе (диал.)

Сорау алмашлыгы

Кисәкчә

Элекке административ-территориаль берәмлек

Кәрлә буйвол

Какшамас

Гарәп хәрефе

Язучы … Зәйнуллин

Төш вакыты, көн уртасы

Аның саен, торган саен

Мөнәсәбәтле (иск.)

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Бożра»

Өстән аска: багу, икона, дау, Җәвад, Ли, Арк, Ерикәй, гел, Айтуганов, Гана, әзи, Арафат, нанай, Луи, Насрый, Шәрәфи, аукан, Басыйрова, сәләмә, санам, клан.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы /гыйнвар

«Каюм Насыйри». Рәссам Байназар Әлмәнев эше

1180 ел элек (840)

Бөек Уйгыр каһанлыгы таркала.

650 ел элек (1370)

Аксак Тимер, зур гаскәр туплап, Бәлх каласын камап ала. Бәлх (хәзер Әфганстанга карый) алынгач үткәрелгән корылтайда аны Мәвараэннәһернең бердәнбер идарәчесе итеп таныйлар. Аксак Тимер Сәмәрканд шәһәрен башкала итеп тәгаенли.

145 ел элек (1875)

Күренекле юрист, тел галиме вә җәмәгать эшлеклесе Шәехгаттар Хәсән улы Иманаев (1875-?) дөньяга килә. Ул – «Бәянелхак» газетасының соңгы редакторы, шулай ук «Татар теленең сарфы вә нәхүе» исемле дәреслек китабы авторы буларак та мәгълүм.

110 ел элек (1910)

Истанбул каласында Рәшит казый Ибраһимов белән Әхмәт Таҗетдин госманлы төрки телендә «Тәгарифе мөслимин» («Мөселманнарны таныштыру») исемле атналык әдәби журнал чыгара башлый.

100 ел элек (1920)

28 гыйнварда күренекле актер Габдулла Кариев (1886-1920) вафат була.

95 ел элек (1925)

11 гыйнварда Татар дәүләт академия театрында Муса Җәлилнең «Бибкәй кыз» исемле музыкаль драмасы сәхнәгә куела.

85 ел элек (1935)

Яшь язучылар белән эшләү өчен, Татарстан Совет язучылары союзы каршында консультация бюросы төзелә. Бюрога Шәриф Камал, Хәсән Туфан, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай һәм Хәсән Хәйри сайлана.

75 ел элек (1945)

Рәссам Байназар Әлмәнев (Альменов), Каюм Насыйри замандашларының истәлекләренә һәм күрсәтмәләренә таянып, бөек мәгърифәтченең тәүге сурәтен эшли.

25 ел элек (1995)

6-7 гыйнварда Татарстан Фәннәр академиясенең утырышлар залында Бөтентатар мәгариф хезмәткәрләренең икенче корылтае һәм «Телләр турындагы канунны тормышка ашыруның бүгенге мәсьәләләре» дип аталган фәнни-гамәли җыен үткәрелә.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. ЯНВАРЬ 2020

И останется в мире слово моё…: Наки Исанбет.

Историческое наследие: «Этруски – римские умельцы». С.Шамси; «Татарки на Балканской войне»; «Стамбульские воспоминания». М.Рахмат Паташева; «Газета «Тартыш», Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин; «Археологический дневник». М.Гусманов; «Вместе с народом». А.Гафиятов.

Татарский мир: «Вся правда жизни в моей настольной книге!». Ф.Гайнанова.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Религиозные праздники и памятные даты в 2020 году». А.Дубин.

Литературное наследие: «Хусаин Мирза». Ф.Бурнаш; «Татарская книга в эмиграции». Х.Миннегулов.

В глубине памяти: «Два министра». А.Файзрахманов; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязов; «Камал III». А.Зарипов.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JANUARY 2020

There will be left my word in the world…: Naki Isanbet.

Historic heritage: «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «The Tatar girls on the Balkan war»; «The Istanbulian memoirs» by M.Rakhmat Patasheva; «Tartysh» («The contest») newspaper»; «The archaeological diary» by M.Gusmanov; «All together with people» by A.Gafiyatov.

Tatar world: «My bechbook is a reflection of reality!» by F.Gaynanova.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov; «The religious events and remarkable dates in 2020» by A.Dubin.

Literary heritage: «Khusain Mirza» by F.Burnash; «The Tatar book is in the emigration» by Kh.Minnegulov.

From the deepest store of memory: «Two ministers» by A.Fayzrakhmanov; «Still keeping in the memory, still keeping!».

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov; «Kamal the 3rd» by A.Zaripov.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation’s life.

Еракка китеп кара...

ИКЕ КАЗАН

Кремль һәм архиерей йорты

Батурин урамы ягыннан Кремль күренеше

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Тәтеш татар мәктәбе укытучылары: беренче рәттә (сулда) – мәктәп директоры Исхак Мостафа улы Казаков, аның хатыны Нәфисә Казакова. 1909 ел

Гөләйза. Галим Хисамиев
Кем ул Казаков? Фарук Нәфиев
Себердәге Казан авылы тарихы. Наилә Вәлиева
Шәҗәрә – буыннар бәйләнеше. Клара Тукаева
Музыка белән язылган язмышлар. Мәгъсүм Гәрәев
Матбугат һәм туган тел. Рүзәл Юсупов
Беренче укытучыларым. Индус Таһиров

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»* журналына башкача язылу:**
- ***uslugi.tatarstan.ru*** сайты ярдәмендә
- редакциядә
- ***podpiska.pochta.ru*** сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.